

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

Раиф Мәрданов

# КИТАПЛАРДА МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЛАРЫ...

«МИЛЛИ КИТАП»

**ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ**

Раиф Мәрданов

# КИТАПЛАРДА МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЛАРЫ...

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2010

УДК 902/904 + 821.0
ББК 63.2 + 83.3 (2Рос=Тат)
М 90

М 90 **Мəрданов Р.Ф. Китапларда миллəт язмышлары...** / Раиф Мəрданов. – Казан: «Милли китап» нəшрияты, 2010. – 92 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 5 нче китап).

ISBN 978-5-88473-053-3

Бу китапка кульъязма истəлеклəрне эзлəү, туплау һəм өйрəнү эшенə, татар археографиясенең катлаулы мəсьəлəлəренə багышлап 1991–2004 елларда язылган мəкалəлəр тупланды.

ISBN 978-5-88473-053-3

УДК 902/904 + 821.0
ББК 63.2 + 83.3 (2Рос=Тат)

© Мəрданов Р.Ф., 2010
© «Милли китап» нəшрияты, 2010

# КЕРЕШ

Татарстан Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге – республикабызда татар кульъязма китапларын һәм истәлекләрен туплау һәм өйрәнү белән шөгыльләнә торган төп гыйльми үзәкләрнең берсе. Бүлек тарафыннан башкарылган эшләр һәм фәнни эзләнүләр «Татар археографиясе» сериясенең беренче китабында гомуми рәвештә тасвирланган иде*. Анда китапханәгә кульъязма мирасны туплауның барышы матбугатта даими рәвештә яктыртылып килгәнлеге әйтелеп, басылып чыккан мәкаләләрнең исемлеге бирелде.

Милли китапханә белгечләренең татар археографиясе өлкәсендә алып барган эшчәнлеге тулырак һәм эзлекле күзаллансын дигән максат белән, матбугатта чыккан мәкаләләрнең бер өлешен, җыентык итеп бастыруны зарур күрдек. Әлеге мәкаләләрдә, татар халкының китап тарихы белән бергә, милләтебезнең бай мәдәни үткәне һәм фаҗигале язмышы да чагыла.

Археографик эзләнүләргә багышланган мәкаләләрнең күпчелеге Казанда нәшер ителгән газета һәм журналларда дөнья күргән иде. Ләкин Татарстан районнары (Әгерҗе, Балтач, Кукмара, Саба) газеталарында, шулай ук күрше республика (Удмуртия, Башкортстан, Чуашстан) һәм өлкәләрдәге (Горький, Самара, Ульяновск һ.б.) татар газеталарында гына басылган мәкаләләр дә булды.

Китапларда милләт язмышы дигән сүзләрне кеше язмышлары дип тә аңларга ярый. Чөнки мәкаләләрдә кульъязма китапларны авыр заманнарда саклап кала алган, бүгенге көнгә кадәр ирештергән, шулай ук, өметсезлектән һәм золым куәте астында үзләре үк китапларны юкка чыгарырга мәҗбүр ителгән кешеләрнең язмышлары да сурәтләнә. Мәкаләләрдә кайбер кульъязма китап тупламна-

* Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. – Б. 4–7. – («Татар археографиясе» сериясе; 1 нче китап).

ры, шәхси китапханәләр турында да мәгълүматлар бирелде, шулай ук тарихи язмалардан өземтәләр, нәсел шәҗәрәләре һәм колофон язулары да бар. Фаҗигале язмышлар белән бергә китапханәбезгә кулъязма истәлекләрне ышанып тапшырган һәм эшебездә ярдәм иткән милләттәшләр турында да берникадәр мәгълүмат бирелде. Исемнәре телгә алынган кешеләрнең күбесе белән, шөкер, хәзергәчә аралашып торабыз. Алар һаман да кулъязма һәм иске басма китаплар туплауда булыша.

Китапка кертелгән мәкаләләрнең текстлары матбугатта чыккан вариантлары белән тәңгәл килми. Чөнки редакция хезмәткәрләре тарафыннан кыскартылган һәм төшереп калдырылган өлешләрен монда тулыландырып бирдек. Мәкалә исемнәре дә элек үзебез куйганча язылды. Югыйсә, кайбер редакцияләрдә мәкаләнең исемен матурлыйбыз дип, киресенчә, ямьсезләткән очраклар да булды. Мәсәлән, берсен «Тарих битләрен актарганда...» дип, уңышсыз үзгәрткәннәр иде. Тик илтифатсызлык һәм дорфалык төсмеренә ия булган «актару» сүзе тарихка, бигрәк тә борынгы кулъязмаларга карата бөтенләй ятышмый. Чөнки тарихи чыганаклар аеруча сак караш, кадер һәм хөрмәт белән эшләүне таләп итә.

Мәкаләләрдәге кайбер кабатланулар, шулай ук борынгы ташъязмалар (эпиграфик истәлекләр) турындагы өлешләре, мөмкин булганча, кыскартып бирелде. Кыскартылган урыннарны квадрат җәяләр эчендәге күп нокталар белән билгеләдек, берничәсендә аерым искәрттек.

Һәр мәкаләнең ахырында күрсәтелгән язылу вакыты матбугатта чыккан датасына туры килми. Һәр мәкалә, гадәттә, археографик сәфәрдән кайтуга ук, тупланган кулъязмалар белән танышкач һәм хатирә-тәэсирләр шаукымында язылды. Җыелган мирасның нәрсәдән гыйбарәт булуын, аның фәнни кыйммәтен кичектермичә халыкка белдерү бурычы таләп иткәнчә һәм кулъязмалар бирүчеләргә рәхмәт җиткерү өчен вакытында язу кирәк иде. Шунлыктан, мәкаләләрдәге фактлар һәм вакыйгалар, археографларның эш ысулларындагы кайбер үзенчәлекләр үз чорына хас. Төрле төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезнең матди һәм рухи яшәешенә карата әйтелгән сүзләребез дә шул дәвер тәэсиренә бәйле.

Мәкаләләр хронологик тәртиптә урнаштырылды һәм алар Татарстан Милли китапханәсенә кульъязма истәлекләрне туплау елъязмасы рәвешен алды. Ләкин язганнарыбыз безнең китапханәнең борынгы мирасны туплау һәм өйрәнүе белән генә чикләнми. Әйтик, бер мәкалә Казан дәүләт университетының 1986–1992 еллардагы археографик эзләнүләренә гомуми күзәтү һәм бәяләмә сыйфатында язылган.

Археографик тикшеренүләр буенча язылган мәкаләләрнең бөтенесе дә монда кертелмәде. Чөнки кайберләре бүтән җыентыкларда урын алган булса*, аерым табыш һәм тикшеренүләребез мөстәкыйль китаплар рәвешендә дөнья күрде**. Берничә мәкаләбезне, эчтәлекләренә күрә, киләчәктә шушы сериядә чыгару күздә тотылган бүтән җыентыклар өчен калдырдык.

Җыентыктагы мәкаләләрдә телгә алынган шәхесләр һәм географик атамаларның махсус күрсәткечләре төзелеп, китап ахырында бирелде.

Бу китапта тасвирланган вакыйгаларның тарихи-археографик әһәмияте җуелмау белән бергә, мәкаләләрдә шактый еллар элек күтәрелгән кайбер мәсьәләләр (мәсәлән, кадрлар хәзерләү) һаман да актуаль булып кала бирә.

---

* Мәсәлән: Мәрданов Р. Милләт дисәң, миләр сызлый...: мәкаләләр җыентыгы. – Казан: «Тамга» нәшрияты, 2006. – 152 б.

** Мәрҗани китапханәсе: фәнни-библиографик җыентык / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2004. – 122 б.; Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт. Р.Мәрданов. – Казан: «Җыен», 2006. – 704 б.; Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты», «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. – 88 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 1 нче китап); Түләк китабы: дастан / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. – 76 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 2 нче китап); «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульъязмаларына тасвирламалар / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2009. – 92 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 3 нче китап); Мөхәммәдьяр. «Нуры содур» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кульъязмалары / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2009. – 128 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 4 нче китап).

## КИТАПЛАРДА МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЛАРЫ...

Татарстан Җөмһүрияте Милли китапханәсенең Сирәк китаплар бүлеге үзенең фондын елдан-ел баета.

Бу бүлекнең эшчәнлеге хакында ел башында газета укучыларга үзләрендә сакланган борынгы китап һәм кульязмаларны җибәрүләрен үтенеп мөрәҗәгать иткән идем*. Әлеге мөрәҗәгать чит өлкәләрдә чыга торган татар газеталарында да басылды.

Нәтиҗәдә, илебезнең төрле почмакларыннан – Оренбург, Екатеринбург, Ульяновск, Чиләбе өлкәләреннән, хәтта ерак Камчаткадан да китапханәгә күп кенә борынгы китаплар, кульязмалар килде һәм һаман да килеп тора. Казан университеты галимнәре Марсель Бакиров, Җәүдәт Миңнуллин, Татарстан китап нәшрияты хезмәткәре Рөстәм Мәһдиев, тарих укытучысы Илһам Сабитов, Ютазы районының Бәйрәкә авылыннан Әнвәр ага Яхин, Гафифә апа Баязитова, Закирә апа Рәхимова, Туймазыдан Вакыйф ага Заһидуллин, Ульяновск өлкәсеннән Әминә апа Хәсәнова аеруча кызыклы китаплар бүләк иттеләр.

Халкыбызның рухи мирасын моңарчы саклап килгән фидакяр затларның кайберләренә аерым тукталыйк. Казан университеты доценты, филология фәннәре кандидаты Марсель Бакировның элек үк университет, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты китапханәләренә татар авылларында табылган борынгы татар китаплары һәм кульязмалары тапшырганын белә идем. Марсель абый Татарстан Милли китапханәсен дә шундый ук бүләге белән куандырды. Ул июль аенда тапшырган калын-калын 57 китапның 41 данәсе кульязма китаплар. Аларның күпчелеге XIX гасырның беренче чирегенә карый, арада 1707, 1779 елларда күчерелгәннәре дә бар. Китаплар эчтәлекләре ягыннан төрле: алар гарәп һәм фарсы телләре, фәлсәфә, мантыйк, әхлак, хисап, дин һ.б. мәсьәлә-

* Мәрданов Р. Тарих берәмтекләп җыела // Татарстан яшьләре. – 1991. – 8 гыйнв.

ләргә багышланган. Шулай ук төрле хикәятләр, шигъри әсәрләр, поэмалар, мөнәҗәтләр дә бар. Сакланышлары чагыштырмача яхшы хәлдә.

Бу байлык арасыннан бер кулъязма җыентык аеруча кызыклы. Вакытында аның белән гарәп теле белгече Зәйнәп Максудова танышкан һәм ул китапны XIII гасыр ядкәре дип билгеләгән. Шушы мәҗмугадагы язмаларның берсендә ук ату осталыгы буенча чик сакчылары өчен өйрәтмә-күрсәтмәләр бирелгән. Бу кулъязма фән өчен, үзенең борынгы булуы белән дә, эчтәлеге ягыннан да, һичшиксез, кызыклы табыш.

Бәйрәкә авылында яшәүче Әнвәр ага Яхин китапханәбезгә кырыктан артык басма һәм кулъязма китаплар, дәфтәрләр бүләк итте. Утызынчы елларда гарәп язуындагы китапларны җыеп яндыру, мәчетләрне җимерү һәм репрессияләр башлангач, Әнвәр аганың әтисе үзендәге китап һәм язмаларны зур сандыкка тутырып өенең идәне астына күмгән. Кызганычка каршы, аларның күбесе яраксыз хәлгә килгән, җуелган. Ә исән калганнарын Әнвәр ага Милли китапханәгә бүләк итеп бирде. Марсель Бакиров, Әнвәр Яхин һәм китаплар җибәргән башка милләттәшләребезгә чиксез рәхмәтебезне белдерәбез.

Эзләнүләрне һаман дәвам итәбез. Китапханәнең сирәк китаплар бүлегенә «Букинист» китап кибетләре аша да китаплар алдырыла. Шул рәвешчә, китапханәдә гарәп язуындагы шактый гына китаплар җыйнала. [...]

Тарихыбызны ихтирам иткән, рухи мирасыбыз язмышына битараф булмаган милләттәшләребез! Татарстан Җөмһүрияте Милли китапханәсе халыкта сакланып килә торган гарәп язуындагы борынгы кулъязмаларны, китапларны, фотосурәтләрне җыйнау, туплау һәм өйрәнүне дәвам итә. Шундый китапларыгыз булса, безгә юллавыгызны яки хәбәр итүегезне үтенәбез. Тарихыбызга битараф булмыйк! Халкыбызның рухи җәүһәрләрен саклап калыйк!

*1991 ел, декабрь.*

## РУХИ ҖӘҮҺӘРЛӘР ЭЗЕННӘН

Казан дәүләт университеты тарафыннан 1963 елдан башлап бүгенге көнгәчә ел саен археографик экспедицияләр оештыру (кульъязма мирасыбызны барлау, саклау һәм өйрәнү эше) дәвам итеп килә.

Университет археографлары элеккеге СССРның татарлар яшәгән бик күп төбәкләрен шушы максат белән йөреп, нәтиҗәле эш башкарганнан соң, 1986 елда тарихчы галим Миркасыйм Госманов җитәкчелегендә Горький (Түбән Новгород) өлкәсенең Сергач якларына юнәлделәр. Дөрес, моңарчы танылган археографлар М.Госманов һәм Альберт Фәтхи 1960 нчы елларда бу якларда булып, кызыклы гына табышларга да юлыкканнар.

Сергач ягы... Татар мәдәниятенә Хөсәен Фәезханов кебек галимнәр, Кави Нәҗми кебек язучылар, Рәшит Ваһапов, Рамил Курамшин, Хәйдәр Бигичев кебек сәнгать әһелләрен биргән як.

Анда барып төшүгә үк шунысы күңелгә хуш килде: һәр авыл мәчетле. Күккә ашкан мәчет манарасының ае җаннарга сихри рәхәтлек бирә. Айлы манараларны ерактан ук күреп рухланабыз. Чамалыйбыз: мәчетле авыл, димәк, иманлы! Монда тарихның тирән тамырлары белән үз бабаларының җирләренә бәйләнгән милләттәшләребез яши. Хакыйкатькә күз йомып булмый, Сергач якларында шундый күренешкә дә тап булдык: бай, төзек, мәчетле, зиннәтле сарай кебек йортлары булган, җиде йөзәр-меңәр хуҗалыклы татар авыллары күршесендәге шактый урыс авыллары беткән. Хуҗалары ташлап шәһәргә киткәнгә моңсуланып, каралып, ярымҗимерек берничә өй генә сагыш эчендә утыра, яисә капкасыз-коймасыз өй каршында бер-ике карчык кына күренә.

Экспедиция, гадәттә, җиде-сигез кешедән: университетның тарихчы галимнәре, фәнни хезмәткәрләре һәм студентлардан гыйбарәт була. Без, язма ядкәрләребезне барлаучылар, шушы авылларда әби-бабайлар, апа-абыйлар белән аралашып, борынгы кульъязмалар белән кызыксынабыз. Аларны җыябыз, кадерләп тартмаларга тутырабыз һәм Казан университетының фәнни китапханәсенә алып кайтып тапшырабыз. Кульъязмалар монда эшкәртү уза, шулай итеп ничә еллар файдасыз яткан китапларга «җан өреләә». Алар тарихи,

әдәби чыганак сыйфатында фәнни хәрәкәткә керә. Галимнәр өчен ышанычлы, бәһасез чыганак буларак кулланылып, милләтебез, тарихыбыз сәхифәләрен баетуга үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр.

Сергач якларында Казанның абруе искиткеч зур. Казан һәм Татарстан тормышы белән кызыксыну соңгы елларда аеруча көчәйде. Казан шәһәренә гыйльми, мәдәни, рухи кыйбла итеп карыйлар. Күп кенә гаиләләр Казанда чыга торган газета-журналлар алдыра, Казан радиосын яратып тыңлый. Монда татар җырын һәм моңын «үлеп» яраталар. Хәтта безнең Казаннан икәнлегебезне белгәч, бер елны, көчләп диярлек, концерт та куйдырта яздылар.

Һәр авылда, максатларыбызның изге булуын аңлап, безгә чын күңелдән булышучы, безнең белән йөреп ярдәмләшүче саф күңелле абыйлар була иде. Шундыйлардан Петряксы авылыннан Сәйяр ага Сабиров, Сафаҗайдан Барый абый Аллямов кебекләр бу яктагы авылларның тарихлары белән таныштырып, безгә бик күп файдалы мәгълүматлар бирделәр.

Һәр елгы сәфәрдән Казанга йөздән артык кульязма китап, авыл тарихлары, тарихи документлар, шәкерт дәфтәрләре һәм башка шундый истәлекләр алып кайттык. Алар арасында әдәби мирасыбыз җәүһәрләреннән «Кыйссаи Йосыф», «Җөмҗөмә солтан», «Кыйссаи Авык» кульязмалары, Габдеррәхим Утыз Имәни, Габделҗәббар Кандалый һ.б. шигырьләре, бәетләр, җырлар да бар. Һәр елда, уртача алганда, бишәр «Йосыф китабы», берәр «Җөмҗөмә солтан» әсәре табылды. Ягъни, җиде ел дәвамында Сергач ягыннан Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәренең 35–40 яңа кульязма варианты табылды дигән сүз.

Экспедиция вакытында башка характердагы кызыклы табышлар да очрый иде. Мәсәлән, кытайча һәм гарәпчә язылган кульязма, XVII йөздә Төркиядә язылган нәкышьле кульязма китап, хәзерге Болгария территориясендәге Тырново шәһәрендә язылган гарәп телендәге әсәр, беренче Бөтендөнья сугышы вакытындагы татар әсирләре тарафыннан чыгарылган «Татар иле» журналы нөсхәләре, Истанбул мәдрәсәсен тәмамлау турында шәһадәтнамә, соңгы заман хикмәтләреннән Әятулла Хөмәйни сурәте төшерелгән һәм аның сүзләре язылган өндәмә-листовка (1986 елда табылды) һ.б. Зур китапханәләргә, тартма-тартма гарәп язулы китапларга да юлыгырга

туры килде. Мәсәлән, Чүмбәли авылында яшәүче Зөһди Кәримевләрдә ата-бабаларыннан калган күп санлы кулъязма һәм басма китаплар сакланган. Алардагы яхшы хәлдәге, күн тышлыклы кулъязма китапларның гына саны да утызга якын иде. Бигрәк тә шунысы игътибарга лаек, әлеге кулъязмаларның егермегә якыны бер кеше тарафыннан күчереп язылган (бу әле безнең кулга эләккәне генә). Димәк, ул кеше бөтен гомерен китап күчереп язу эшенә багышлаган. Язу гына түгел, үзе үк карасын да әзерләгән, төпләгән һәм тышлаган да. Никадәр хезмәт, күпме тырышлык, ничаклы түземлек таләп итә торган эш!

Татар язма һәм басма китабы тарихы халкыбызның аянычлы язмышын чагылдыра. Утызынчы елларда татар китабына каршы оештырылган явызлыкны үз күзләре белән күргән агайлар һәм апалар яндырылган, юк ителгән китаплар хакында елый-елый, әрнеп сөйләделәр. Бу вәхшәт халкыбыз күңелендә төзәлмәслек авыр яра калдырган. Әйе, таш уала, хәтер кала, дип бик хаклы әйткәннәр. Хәзер, ул кара еллардан ярты гасыр вакыт кичкәч тә, андый вакыйгалар халык хәтерендә. Гарәп язулы китаплар дип авыз ачуга, күпләр шомлана, шөбһә белән сагаеп карый. Китапларны җыеп яндыручылардан курку сеңгән күңелләр, максат-ниятләребезне озаклап, тәфсилләп аңлаткач кына ачылып китә. Шуннан соң гына, дәһшәтләр аша үткән, утны-суны кичкән китап-язмалар киштәләрдән, чормалардан безнең кулларга күчә.

Әлбәттә, төрле кеше очрый. Гарәп язуын танучы олы яшьтәге «укымышлы»лар белән эш йөртү күпкә җиңел. Андыйлар белән ярты сүздән аңлашасың. Әмма яртылаш яңалиф (латин), яртылаш кириллица әлифбасы белән белем алган абый-апалар белән уртак тел табу шактый катлаулы. Алар гарәп язуындагы һәммә нәрсәне дини дип аңлый һәм ислам динен өстән-өстән генә, тышкы кабыгын гына белгән хәлдә, фанатикларча үҗәтләнә. Бу Сергач ягына гына түгел, татарлар яши торган бөтен төбәкләргә дә хас күренеш. Әлбәттә, абый-апалар үзләре гаепле дигән сүз түгел. Бу – халыкны тарихыннан аеру, томаналандыру, маңкортлаштыру, колга әйләндерү сәясәтенең бер нәтиҗәсе.

Заманында төрле яктан камилләшеп килгән, Тукайлары, Исхакыйлары, Ризаэтдин Фәхретдиннәре, Рәмиевләре, Акчуриннары,

Әхмәт байлары булган бай тарихлы татар милләте шул кадәрле җәберләнеп, шушындый кызганыч, мескен, надан хәлгә җиткерелгән. Утызынчы елларда тәрбияләнгән буын кешеләреннән кайберләренең «изге сүз» дип, ишек өстенә 1915 елда Казанда басылган «Һәндәсә» (Геометрия) дәреслеген яки Мәскәүдә гарәп телендә чыккан 1970 нче еллар газетасын кыстырып куюларын мескенлек һәм наданлык димичә, ни дисең?!

Сергач якларында җиде ел йөрү, күпме кешеләр белән очрашып-сөйләшүләр күрсәткәнчә, анда яшәүче төп, җирле халыкның шактый өлеше үз тарихын бик начар белә яисә бөтенләй белми дияргә дә мөмкин. Күпчелекнең аңында, бу җирләр борынгы урыс җирләре булган, безне монда Явыз Иван Казанны җимергәч көчләп күчереп утыртканнар, дигән ялгыш фикер өстенлек итә. Югарыда әйтелгәнчә, соңгы бер-ике елда Татарстан тормышы, референдум, бәйсезлек белән кызыксыну аеруча көчле. Шул ук вакытта, инде безне нишләтерләр, килмешәкләр, дип, Татарстаныгызга китегез, дип кумасламы, дигән борчылучылары да бар.

Быел Казан дәүләт университеты һәм Татарстан Милли китапханәсе тарафыннан Сергач ягына берләштерелгән археографик экспедиция оештырылды. Маклаково, Тукай, Ишавыл, Кочки-Пожарки авылларында йөреп, йөзләгән кульязма һәм басма китап тупланды. Шул исәптән дүрт данә кульязма «Йосыф китабы», бер «Җөмҗөмә солтан» дастаны, басмалардан Каюм Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдин, Габдулла Тукай, Фатих Кәрими, Галимҗан Ибраһимов, Зариф Бәшири һәм башкаларның әсәрләре бар иде. Шулай итеп, 1992 елда археографик максатларда Түбән Новгород өлкәсендәге татар авылларының соңгыларын йөреп чыктык.

Замана катлаулылыгы белән бергә, археографик экспедицияне оештыру елдан-ел кыенлаша бара. Финанс, транспорт, бензин мәсьәләләре аеруча авырлашты. Бу уңайдан, республикабыз министрлыклары фәнни максатлардагы бу төр чараларга тагын да җитдирәк игътибар бирерләр һәм төрле яклап ярдәм күрсәтерләр дип ышанабыз. Шулай ук, хәзерге чорда эшләп килүче төрле фонд-җәмгыятьләр дә бу мәсьәләдә битараф булмаслар дип уйлыйбыз.

*1992 ел, 3 сентябрь.*

# ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНДӘ ТАТАР КУЛЪЯЗМА ҺӘМ БАСМА КИТАПЛАРЫН ЭЗЛӘҮ, ТУПЛАУ ҺӘМ ӨЙРӘНҮ ЭШЕНЕҢ ТОРЫШЫ*

1992 елның февралендә Мәскәү шәһәрендә Маркс, Энгельс, Ленин, КПСС китаплары яндырылу хакында мәгълүм булды. Бу факт телевидениедән күрсәтелде, газеталарда да хәбәр ителде. Газеталарда бирелгән фоторәсемдә исә, янып ятучы китаплар арасында татар шагыйре М.Җәлилнең дә китабы бар иде. XX гасыр ахырында бу нинди вәхшилек тагын? Бу нинди кыргый демократия? Тагын татарның китабын яндыралар. Татар халкында иң изге нәрсәләрдән саналган китапка тагын кизәнәләр.

Татар китабы кебек җәбер-золымны күргән китап дөньяның тагын кайсы халкында бар икән? Бу сорауга җавап бирүе авыр. Явыз Иван заманыннан башлап Русия хөкемдарларының мәкерле, кара сәясәте аркасында татар китабы гасырлар дәвамында яндырылу, кимсетелүләргә дучар ителде. Әмма бу фаҗигаләр чылбырының иң зурысы, куркынычы, совет власте чорында 1920-30 нчы елларда булды. Ул куркынычлы вакыйгалар әле дә халык хәтерендә саклана.

Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм Сирәк китаплар бүлеге үзенең фондын баету юнәлешендә актив эш алып бара. Борынгы китап мирасыбызны барлап туплау буенча көндәлек матбугат аша милләттәшләребезгә мөрәҗәгать итүләребез дә җавапсыз калмады. Татарстан авылларына, җөмһүриятебездән читтә яшәүче татарлар арасына археографик командировкалар, экспедицияләр оештырыла.

Казан университеты доценты Марсель Бакиров бүләк иткән кулъязма китаплар күп булуга нигезләнеп, гыйнвар аеннан китапханәнең сирәк китаплар бүлегенең вазифалары киңәйтелде, исеме дә «Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге» дип үзгәртелде. Татарстанның төп китапханәсендә мондый бүлек, һичшиксез, булырга тиеш иде һәм ул оештырылды. Эзләнүләребез нәтиҗәсендә китаплар табыла тора, фондыбыздагы борынгы китаплар саны арт-

* Татар басма китабының 270 еллыгына багышлап Казанда уздырылган «Татар китабының үткәне һәм бүгенгесе» дип аталган фәнни-гамәли конференциядә 1992 елның 21 декабрендә ясалган докладтан кыскартып алынды.

каннан арта. Бүгенге көндә безнең китапханәдә 300 гә якын кулъязма китап исәпләнә. Бу саннан тыш, илледән артык документ һәм фотосурәтләр бар. Кызыклы фотолардан Г.Тукайның Ф.Әмирхан, Вафа Бәхтияров һ.б. белән 1908 елда «Әл-Ислах» газетасы идарәсендә төшерелгән оригинал нөсхәсен, татар халкының күренекле шәхесләреннән тагын берсе – Камил Мотыйгыйның җәмәгате белән төшкән оригинал фотоларын да күптән түгел китапханәгә сатып алдык.

Гыйнвар аенда коллегабыз, (безнең кебек яшь буынның остазларыннан берсе) китапчы галим Альберт Фәтхи вакытсыз дөнья куйды. Мәрхүмнең авыр туфрагы җиңел булсын. Ул бөтен гомерен татар китабына, аны саклау һәм өйрәнүгә багышлаган, милләтебезнең сирәк шәхесләреннән берсе иде. Альберт абыйның вафатыннан соң, аның үз өендә сакланган гарәп язуындагы ике йөздән артык басма китапны туганнарыннан Татарстан Милли китапханәсе сатып алды; каберенә чардуган эшләттек. Бу китаплар Милли китапханәдә Альберт Фәтхинең якты истәлеге булып сакланачак.

Быелгы җәйдә Татарстан Милли китапханәсе, беренче тапкыр буларак, Казан дәүләт университеты белән берлектә, Түбән Новгород өлкәсенә археографик экспедиция оештырды. Нәтиҗәдә, йөзләгән кулъязма һәм басма китаплар табып алып кайттык.

Чыгышымның башында татарларда китапның борынгыдан ук иң изге, иң кадерле нәрсә булып саналуын әйткән идем. Өстәмә рәвешендә шунысын да искәртергә кирәк, гыйлемгә, укуга (шул исәптән китапка) югары дәрәҗәдәге мөнәсәбәт һәм таләп ислам диненең нигезенә үк салынган. Татарларның милли хасиятләре ислам өйрәтмәләре белән синтезлашып, халкыбызны аңлы-мәгълүматлы, мәгърифәтле иткән. Татарларның, кая гына барып чыксалар да, мәчет төзү, мәктәп ачу, матбагачылык хәстәрләрен беренче чиратта күрергә тырышулары да моны раслый. Ислам динендә китапны, гыйлемне олуглаган күпсанлы хәдисләрнең дә берсен искә төшереп үтәсем килә. «Мән әхрәка мусхафән шәрифән, фәкәиннәма катәлә сәбгыйнә нәбиййән». Мәгънәсе болай: «Әгәр бер адәм Коръән битен ертса, ул кеше җитмеш пәйгамбәрне үтерүчегә тиңдер». Ислам каршында китапның никадәр хөрмәт ителгәнен шушыннан да чамаларга мөмкин.

Безнең бүлекнең бүгенге көнгә эшчәнлеге югарыда саналганнардан гыйбарәт. Әлбәттә, безне борчыган мәсьәләләр дә юк түгел. Мәсәлән, белгечләр мәсьәләсе. Борынгы кульязма һәм басма татар китаплары белән эшләү өчен гарәп язуын яхшы үзләштергән, хәзерлекле кадрлар кирәк. Андый белгечләрне әлегә Мәдәният һәм сәнгать институты хәзерләми. Ә университет тәмамлаган гарәп телен һәм язуын белүчеләрнең китапханә белеме буенча мәгълүматлары юк. Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Безне канәгатьләндерерлек кадрлар булган очракта да, алар, мәдәният хезмәткәрләренә иң түбән хезмәт хакы түләнгән хәзерге катлаулы заманда, мондый эшкә килергә җөрьәт итәрләрме? Китапханәләргә генә түгел, гомумән, мәдәнияткә мондый караш яшәп килгәндә, булган кадрларыбыздан да колак какмабызмы? Бу мәсьәләләр бик җитди һәм кичектермичә хәл кылуны таләп итәләр.

*1992 ел, 19 декабрь.*

## «КОНТРРЕВОЛЮЦИОНЕР» МУЛЛА ЯЗМАЛАРЫ

Үткән елда Татарстанда беренче басма татар китабының 270 еллыгы билгеләп үтелде. Җөмһүриятебездән читтәге татар төбәкләрендә дә бу тарихи юбилейга багышланган тантаналар, кичәләр булып узды. Шундый тантана октябрь аенда Екатеринбург каласында да оештырылган иде. Анда Казаннан галимнәр, әдәбият-сәнгать әһелләре дә катнашты. Татарстан Милли китапханәсенең күчмә китап күргәзмәсен оештыручы буларак анда миңа да катнашу насыйп булды. Кичәгә килгән күп кенә милләттәшләребездән мин гарәп язуындагы басма һәм кульязма китаплар турында кызыксынып сораштым. Тантанага Каменск-Уральск шәһәреннән килгән Әнисә ханым бабасының репрессияләнгән булуын һәм аның шул хактагы язмалары барлыгын әйтте.

Казанга кайткач, озак та үтмәде, китапханәбезгә Әнисә ханымнан бандероль килеп төште. Анда гарәп шрифты белән язган истәлекләрнең ксерокүчермәсе иде. Авторы – Уфа губернасы Бөре өязе (хәзерге Башкортстанның Илеш районында) Йонлы авылында 1876 елда туган Мөхәммәтгали Шәрипов. Ул дини гыйлемнән башка, агрономик белемгә дә ия булып, бакчачылык һәм умартачылык

белән яратып шөгыльләнгән. Йонлы авылы имамы Мөхәммәтгали хәзрәтнең Октябрь (1917) революциясеннән соңгы язмышы меңләгән башка татар муллалары, укымышлы затларыныкына бик охшаш. Күп мәртәбә кулга алынулар, төрмәләр, лагерьлар... һәм, ниһаять, ачлык, кыйналу, авыру кебек сәбәпләрдән лагерьда һәлак булу.

Аны беренче тапкыр 1919 елның декабрендә, хөкүмәткә тапшырмыйча икмәк яшереп калуда гаепләп, кулга алалар. Аннары 1920 елның маенда сәнәкчеләр күтәрелешендә катнашуда гаепләнеп, тагын кулга алына. Азат ителә. 1921 елда февральдә тагын арест. Тагын җибәрәләр. Шул ук елның октябрендә яңадан кулга алына. Бу юлы иптәшләреннән дүртесе атарга хөкем ителә. Ә калган дүртесе (шул исәптән М.Шәрипов) биш елга, башкалары өчәр елга Уфа контрреволюцион лагерена ябыла.

Мөхәммәтгали мулла мең үлемне җиңеп, исән кала, биш елын тутырып авылына кайта. Әмма берничә елдан, кулак дип сөрүләр башлангач, ике кияве белән Архангельск якларына озатыла. Аннан инде кире кайтмый...

Ә кулъязмасына килгәндә, Мөхәммәтгали ага аны Уфа лагереннан кайтканнан соң, 1927-28 елларда язган булса кирәк. Автор анда 1919 елда кулга алынуыннан башлап Уфа лагерена ябылуына кадәрге вакыт эчендә күргәннәрен һәм уй-кичерешләрен теркәп барган. Иң аянычы шул: язманың соңгы битләре сакланмаган.

Ул чор, вакыйгалар турында тарихи хезмәтләр үтә берьяклы, «кызыл» һәм томанлы иделәр. Шулай да кулъязмада тасвирланган чор турында, аны яңача бәяләүдә тарих фәннәре кандидаты Л.Якубованың «Татарстан» журналындагы мәкаләсе («Кулацкие мятежи или крестьянская война?» – 1992, № 7-8) игътибарга лаек. М.Шәрипов кулъязмасы белән танышу да бу мәсьәләдәге «кызыл томан»ны берникадәр таратуга ярдәм итә.

Кулъязмада телгә алынган авылларның күпчелеге хәзерге Башкортстанның татарлар яши торган төньяк-көнбатыш районнарында. Кулъязма белән танышу шул төбәктә яшәүчеләр өчен аеруча кызыклы булыр. Мөхәммәтгали хәзрәт язмаларында, югарыда әйтелгәнчә, хәвефле вакыйгалар тасвирлана. Совет хезмәткәрләре арасындагы ришвәтчелек (авыр ачлык еллары булуга карамастан, ка-

бат-кабат һәм күп күләмдә икмәк, акча таләп итүләр), совет зинданнарына укымышлы муллаларның, хәтта 70–80 яшьтәге имамнарның да ябылу күренешләре, тоткыннарның төрле авырулардан чебен урынына кырылуы һ.б. Әлбәттә, кулъязмада тасвирланган хәлләр, «экспериментлар иле» булган Русиядәге хисапсыз фаҗигаләрнең, большевиклар тудырган дәһшәтләр чылбырының бер буыны гына. Язманың төп геройлары, ягъни совет хезмәткәрләре, кулаклары, муллалары, сәнәкчеләр кулыннан шәһид киткәннәре, контрлары – барчасы утопик идеология заманының корбаннары.

Кулъязма М.Шәриповның Уфадагы ирләр монастыренда урнашкан контрреволюцион лагерьга илтеп ябылганлыгын сурәтләгән урында өзелеп кала. Аннан соңгы битләре, кызганычка каршы, җуелган. Хәзрәтнең бу язмасы балалары, туганнары арасында дистә еллар кулдан-кулга күчеп, 1991 елда авторның оныгы Әнисә ханым кулына кергән.

Репрессия корбаны Мөхәммәтгали Шәрипов тарафыннан язып калдырылган бу материал тарихчылар өчен дә кызыклы булыр дип өметләнәбез. Ходай боерса, үз татар киностудияләребезнең эше җайланып, тарихи-документаль фильмнар иҗат иткәндә дә бу истәлекне уңышлы файдаланырга мөмкин булыр иде.

Ә кулъязманың төп нөсхәсен, Алла боерып, дөньялар имин булса, Әнисә ханым быел үзе Казанга килеп Татарстан Милли китапханәсенә тапшырырга җыена*. Ул да совет чынбарлыгының ачысын аз татымаган. «Яшьли ятим, 1942 елдан тол калган кулак кызы – әниемнең колхоздагы тормышы икенче китап, ә минем язмыш – өченче бер тарих. Бабабыз рухы, аның геннары бездә яши, ачы язмыш безне ничек кенә сынаса да, кеше булып калырга үзебездә көч таба алдык», – дип тәмамлый ул үзенең бер хатын.

*1993 ел, 24 март.*

---

* Әнисә ханым Нәбиева кулъязманың төп нөсхәсен Казанга алып килеп тапшырды. Бу турыда карагыз: Равил Вәли. «Контр мулла» көндәлеге // Шәһри Казан. – 1996. – 16 апрель.

М.Шәрипов истәлекләренең безнең тарафтан әзерләнеп «Мирас» журналында (1996, №№ 1–6) басылган текстын мулланың нәсел дәвамчылары аерым китапчык итеп бастырдылар (Шәрипов М. Гүрләргә керде безнең башлар: «Контрреволюционер мулла» язмалары. – Нефтекамск, 2008. – 78 б.)

## СЕРЛЕ КИТАП, КУЛЪЯЗМАЛАР...

Соңгы елларда татар халкының тарихын өйрәнү, мәдәниятен торгызу буенча күп кенә эшләр башкарылды. Мәсәлән, Татарстан Фәннәр академиясе, Казан милли-мәдәни үзәге оештырылды, Татар энциклопедиясен төзү эше башланды, Республика Үзәк китапханәсенең статусы үзгәртелде. Татарстан Милли китапханәсе белән якыннанрак танышу өчен республикабыздагы төп китап хәзинәлегенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Раиф Мәрданов белән очраштык.

**– Раиф әфәнде, китапханәнең исеме белән җисеме арасындагы бәйләнеш нидән гыйбарәт?**

– Мәгълүм булганча, В.И.Ленин исемендәге Республика фәнни китапханәсенә 1991 елның ноябрендә Милли китапханә статусы бирелде. Бу коры исем алыштыру гына түгел, ә китапханә эшчәнлегенең офыкларын, ягъни бурычлары белән вазифаларын киңәйтә торган әһәмиятле вакыйга.

Татарстан Милли китапханәсе исеме белән яши башлаганнан соң ике ел ярым вакыт үтте. Шушы вакыт эчендә китапханәдә күзгә күренерлек гамәлләр башкарылды. Китапханәбез эшчәнлегенең төп максатларыннан берсе – татар халкының тарихы, мәдәнияте, әдәбияты һәм хәзерге Татарстан Республикасының тормышына багышланган хезмәтләр һәм информация туплау. Әлеге эш элеккеге СССР территориясе белән генә чикләнми. Шуларны күздә тотып, соңгы вакытта чит илләр белән даими хезмәттәшлек итү, аралашу максаты белән китапханәдә Халыкара китап алмашу бүлеге оештырылды. Бүлек үзенең беренче адымнарын уңышлы гына башлап җибәрде. Бу өлкәдә, әлбәттә, Америка, Англия, Канада, Төркия кебек илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең ярдәме дә зур булды. Кыскасы, Татарстан Милли китапханәсе дөнья аренасына чыга дигән сүз. Ул, дөньяның эре китапханәләре белән хезмәттәшлек итеп, китаплар һәм мәгълүмат-информация алмашып торачак. Китапханәне заманча җиһазлау мәсьәләсе дә уңышлы хәл ителде: компьютерлаштыру һәм автоматлаштыру буенча махсус бүлек бар. Һәр бүлекнең эше, мөмкин булганча, компьютер системасына кертелә.

Гомумән алганда, китапханәнең яңа статусы таләпләренә җавап бирерлек төрле бүлекләр оештырыла, яңача эш формалары гамәлгә ашырыла.

**– Китапханәдәге Сез сөйләп үткән яңалыклар, уңышлар нәрсәгә бәйле? Мондый болгавыр, матди кыенлыклар кичерә торган заманда боларга ничек ирешелә?**

– Соравыгыз бик урынлы. Беренче чиратта, югарыда санап үтелгән эшләр китапханә директоры Р.Вәлиевнең иҗтиһады, фидакярлеге, оештыру сәләте һәм коллектив белән идарә итү ысулларының матур бер нәтиҗәсе.

**– Исеменнән үк күренгәнчә, Сез җитәкли торган бүлек китапханәнең иң кызыклыларыннан берсе булырга тиеш. Аның тарихы белән дә таныштырсагыз иде?**

– Моңарчы эшләп килгән сирәк китаплар секторы 1992 елның гыйнварыннан Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге дип үзгәртелде. Аңлашылганча, эш планы, максат-бурычлар да киңәйтелде.

Китапханәдә 1917 елга кадәр басылган рус телендәге китаплар бихисап. Гарәп язуындагы татар, гарәп, төрек, фарсы телләрендә 1806–1929 еллар арасында басылып чыккан китаплар да шактый. Аларны билгеле бер системага салуда, гыйльми эшкәртүдә китапханәнең баш консультанты, китапчы галим, академик Әбрар ага Кәримуллинның ярдәме бик зур. Ул безнең бүлек тарафыннан эшләнә торган Татар басма китабының (1917 елга кадәр) тулы каталогын төзүне башлап җибәрде һәм җитәкчелек итә.

Татар һәм Көнчыгыш кулъязмаларын җыйнау һәм өйрәнү Казан дәүләт университетында үткән гасырда ук башланган һәм бүгенге көндә дә дәвам итә. Казанда тагын Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты бу юнәлештә актив эш алып бара. Шулай ук Татарстан Дәүләт музеенда да кулъязмалар саклана. Татарстан Җөмһүриятендә кулъязма мирас шушы оешмаларда саклана һәм өйрәнелә. Бу өч оешма галимнәренең эзләнүләре, тырышлыгы нәтиҗәсендә гарәп язуындагы дистә меңләгән кулъязма тарихи хезмәтләр, әдәби ядкәрләр авыр заманнарда да сакланып калды. Алар фәнебезне үстерүдә, татар халкының уртак олуг мирасын соңгы буыннарга җиткерүдә чагыштыргысыз зур өлеш керттеләр.

Төрле җирләрдә сибелеп яшәүче милләттәшләребездә каурый каләм белән кулдан язылган китаплар, шәкерт дәфтәрләренең һәм башка шундый язмаларның һаман да барлыгын исәпкә алып, Татарстан Милли китапханәсендә дә мондый бүлек ачылды һәм кульъязмалар туплау, өйрәнү эше башланды.

**– Ике ел эчендә ничаклы туплададыгыз һәм аларның язмышы ничек?**

– Бүгенге көндә безнең китапханәдә җиде йөздән артык берәмлек татар, төрек, гарәп һәм фарсы телләрендәге борынгы кульъязмалар бар. Шулай ук татар тарихына бәйле документлар, фоторәсемнәр дә саклана. Бүлеккә кергән һәр кульъязма китап, һәр язма бит яхшылап чистартыла, һәрберсе пөхтәләп кәгазьгә төрелеп, аерым папкаларга салына, һәр кульъязма берәмлек кемнән, кайчан алынганлыгы теркәлгән хәлдә, аерым номер-шифр белән саклана. Кызыксынучыларга, галимнәргә китапханәгә килеп алар белән якыннан танышу мөмкинлеге тудырылган.

**– Сер булмаса, үзегезнең эш ысулларыгыз белән укучыларны да таныштырсагыз иде. Мондый әһәмиятле чыганаклар нинди юллар белән туплана?**

– Ике ел рәттән, университет белән берлектә, Татарстаннан читтәге өлкәләргә язма мирасыбызны туплау һәм өйрәнү максатыннан, археографик экспедицияләр оештырылды. Аерым адреслар белән Татарстан авылларына һәм аннан читтәге төбәкләргә махсус командировкалар да яхшы гына нәтиҗәләр бирә. 1993 елның ноябрь аенда Киров өлкәсенең көньяк һәм Татарстанның Кукмара районнарына шундый сәфәр ясалган иде. Уразай авылында яшәүче Гариповлар гаиләсе төрле эчтәлектәге егермедән артык кульъязма китап тапшырды. Мәмәшир авылыннан Һибәтулла Салихов-Каргалыйның, Әбелмәних Каргалый шигырьләре тупланган кульъязма, төрле хикәятләрне үз эченә алган, халык медицинасына караган һәм башка материаллар табылды. Төрле өлкәләрдән дә кызыклы гына кульъязма һәм басма китаплар алдык. Казан шәһәрендә, һәм, гомумән, Татарстанда яшәүче милләттәшләребездән үз куллары белән китапханәгә китереп тапшыручылар да аз түгел. Безнең эшчәнлегебезне аңлап, авыр заманнарда да әти-бабаларыннан сакланып калган иске язмаларны, китапларны китапханәбезгә тапшыру-

чыларга, бу эштә ярдәм итүчеләргә чын күңелдән рәхмәтебезне белдерәсе килә.

**– Әдәбият һәм тарих фәненә яңалык кертердәй материалларга юлыкканыгыз булдымы? Андыйлар булса – нәрсәләр? Эчтәлек ягыннан алар нинди характерда?**

– Һәр кулъязма китап һәм дәфтәр кызыклы, үзенчәлекле, кабатланмас. Һәр ун кулъязманың берсе кечкенә генә булса да яңалык бирсә – бу инде табыш дигән сүз.

Китапханәбездәге кулъязмаларның хисабы әлегә зур булмаса да, аеруча игътибарга лаеклылары бар, дияргә ярый. Күпчелеге XIX гасырда күчерелгән нөсхәләр булса да, арада XVI, XVII гасыр язмалары да бар. Эчтәлек җәһәтенә килгәндә, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре, Һибәтулла Каргалый, Габделҗәббар Кандалый кебек әдипләрнең шигырьләре тупланган җыентыклар бар. Җыр, бәет, шигырьләр язылган шәкерт дәфтәрләре дә табылып, фондка өстәлеп тора.

Ижау шәһәреннән Мәсгут ага Гаратуев кызыклы гына язмалар җибәргән иде. Алар XX йөз башында хәзерге Әгерҗе районының Иж-Бубый авылында туып үскән Габдулла Сибгатуллин-Бубыйның 1915–1916 елларда иҗат итеп, замана болганчыклыгы һәм авторының яшьли үлеме аркасында вакытында матбугатта дөнья күрми калган әсәрләренең кулъязмалары булып чыкты. Ул әсәрләрне, хәзерге татар язуына күчереп, Татарстан китап нәшриятына тапшырдык. Димәк, XX йөз башы әдәбияты тарихына тагын бер исем өстәләчәк. Ә икенче бер материал – 1920 нче елларда репрессияләнгән татар мулласының язмалары. Авыр хәлләргә тарыган мулла агай, башыннан кичергәннәрен тәфсилләп, кәгазьгә теркәп барган. Бу материалны безгә Свердловск өлкәсендә яшәүче Әнисә ханым тапшырган иде. Анысын да матбугатка – «Мирас» журналына әзерләп бирдек. Америкада яшәүче милләттәшләребез Равил Сәлиәхмәт безнең китапханәгә Кытайдагы татарларның үткән тормышына кагылышлы һәм хәзерге вакытта чит илләрдәге матбугат органнарында Татарстанның бәйсезлеккә омтылышы хакындагы җитди материаллар тапшырды.

Яңарак кына табылган кулъязма турында бер-ике сүз. Монысы үткән гасырларның берсендә яшәп иҗат иткән, моңарчы исеме

мәгълүм татар шагыйренең хәзергәчә билгеле булмаган күләмле генә әсәре. Бу да әдәбият тарихына саллы гына яңалык булып өстәлергә тора. Авторын һәм әсәрен әлегә атамыйча торуны кирәк саныйм. Чөнки әле җентекләп тикшерәсе, өйрәнәсе бар*.

– **Бәетләр язылган дәфтәрләр турында да әйтеп үтсәгез иде.**

– Әйе, андый дәфтәрләр бар. Бәетләр теркәлгән дәфтәрләрнең ике кеше тарафыннан тапшырылганнары хакында әйтми калу гөнаһка тиң булыр иде. Тапшыручылар икесе да Апас районының Аю-Көйдергән авылында туып үскәннәр. Берсе – Зыятдинов Фариз абый, авылда яши, пенсиядәге укытучы. Икенчесе – гасыр чордашы, өлкән яшьтәге педагог, Яшел Үзән шәһәрендә озак еллар укытучы булып эшләгән, татар теле белеме буенча дәреслекләр, методик ярдәмлекләр авторы Шәриф ага Сайкин. Бу ике мөхтәрәм зат тапшырган XIX йөз ахыры – XX гасыр башында язылган кульязмалар, дәфтәрләрдә нинди генә бәетләр юк: «Шәһри Болгар бәете», төрек, япон һәм герман сугышлары бәете, Шамил бәетләре, Хан кызы, «Сак-Сок», «Нәүрүз» һәм башкалар. Репертуарның байлыгына, бәетләрнең төрлелегенә сокланмыйча мөмкин түгел. Берничә генә дәфтәрчектә алтмыштан артык аерым бәет теркәлгән! Бу археограф галим, академик Миркасыйм Госмановның «Тау ягы – фольклор әсәрләренә иң бай төбәк» дигән фикерен куәтли торган ачык бер мисал. Әлеге бәетләр дә матбугатта аерым-аерым дөнья күрәчәкләр. Гомумән, китапханәгә килеп кергән язма истәлекләргә яңа сулыш өрелә. Алар монда файдасыз, кирәксез булып ятмаячаклар. Хәрәкәттә – бәрәкәт дигәннәр борынгылар. Фондыбызга туплана торган кульязма мирас фәнни хәрәкәткә керәчәк, матбугатта басылып, киң катлау укучылар да алар белән танышачак. Ягъни, безнең бурыч – халыкка хезмәт итү. Халык үз байлыгын белергә, аннан файда күрергә тиеш. Ниһаять, китап укылыр өчен языла бит. Аны сандыкка бикләп яки кеше күзеннән яшереп яткыру мәгънәсезлек. Язма һәм басма сүз укылырга тиеш. Аңлы, мәгърифәтле милләтнең генә киләчәге ышанычлы, бүгенгесе камил була ала.

* Мәүла Колый поэмалары күздә тотыла.

**– Ә сезнең матбугаттан тыш укучылар белән аралашуның башка формалары бармы?**

Безнең китапханәдә һәр елны, елга ике мәртәбә яз һәм көз айларында, гарәп язуын өйрәтү курслары оештырыла. Укырга теләк белдерүчеләр булып тора. Алар дәресләргә бик яратып йөриләр. Кыска гына вакыт эчендә гарәп язуында укырга һәм язарга өйрәнеп китәләр. Соңгы елларда бу дәресләрне яхшы хәзерлекле хезмәткәребез Ирек Һадиев алып бара. Безнең курсларда укыган кешеләр, соңыннан китапханәдән, төгәлрәге, безнең бүлектән, гарәп язуындагы җаннары теләгән китапны алып укыйлар. Шуңа игътибар итәргә кирәк: Татарстан Милли китапханәсе гарәп язулы китапларны укучыларга өйләренә бирә торган республикадагы бердәнбер китапханә! Кызганыч, моны күпләр белеп бетерми. Шулай ук безнең бүлекнең эше белән якыннанрак танышырга теләүчеләр булса, 3 июньдә китапханәбезгә чакырабыз. Бу көнне Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең эшчәнлегенә багышланган зур күргәзмә һәм кичә була. [...]

**– Әле халык кулында билгесез хәлдә ята торган кулъязмалар күптер дип уйлыйсызмы? Фондыгызга тагын да кызыклы, әһәмиятлеләре өстәлергә мөмкинме?**

– Андыйлар күп булмаса да, әле шактый дип уйлыйм. Шаккатыргыч яңа табышлар булмас инде дип өзеп әйтергә дә һич ярамый. Тик чормаларда, чоланнарда ятып, юкка чыгып бетмәсеннәр иде дигән борчуыбыз гына тынгы бирми. Һәрхәлдә, милли тарихыбызга битараф булмаган милләттәшләребез безнең белән элемтәгә керерләр, уртак мирасыбызны саклап калуда ярдәм күрсәтерләр дигән ышанычта калабыз.

Әңгәмәдәш – Энҗе Гәрәева,
КДУ студенты.

*Татарстан хәбәрләре. – 1994. – 13 май.*

## ГАСЫРЛАР САГЫШЫ САРЫЛГАН...

Татарстан Милли китапханәсе хезмәткәрләре фәнни археографик максатлар белән 24–25 август көннәрендә Саба районына гыйльми сәфәр ясады.

Беренче чиратта, «археография» дип атала торган, ягъни тарих фәненең күпләр өчен аз таныш булган тармагы хакында да мәгълүмат бирү урынлы булыр.

Нәрсә ул археография һәм ул ни белән шөгыльләнә? Археография – тарих фәненең борынгы язма чыганакларны (кульъязма китап, дәфтәр, төрле документлар һәм башкалар) барлау, туплау, өйрәнү һәм саклауны эченә алган бер тармагы.

Татар халкы күп гасырлар элек үк язуга, китап культурасына ия, мәдәни тарихы бай булган милләт. Бабаларыбызның Бөек Болгар, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Себер һәм Кырым ханлыгы кебек шанлы-шәүкәтле дәүләтләре чорларында ук дини, гыйльми, әдәби эчтәлектәге күпсанлы кульъязма китаплардан тупланган бай китапханәләре булган. Шул дәверләрдәге төрле фаҗигаләр, янгыннар һәм соңгы гасырлардагы Россия хөкүмәте тарафыннан татар халкына карата булган геноцид сәясәте аркасында миллионнарча язма китапларның аз өлеше генә безнең көннәргә хәтле килеп ирешкән.

Мәгълүм булганча, беренче басма татар китабы 1722 елда гына дөньяга чыга. Ә аңарчы (хәтта аннан соң да, XX гасыр башына кадәр диярлек) әдипләребезнең иҗат әсәрләре, галимнәребезнең хезмәтләре күп гасырлар дәвамында кульъязма хәлендә таралган һәм буыннан-буынга тапшырылган. Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф, Утыз Имәни, Габденнасыйр Курсави, Габделҗәббар Кандалый һ.б. бик күп күренекле шәхесләребезнең хәзерге заманда чыккан җыентык-китаплары гарәп язулы борынгы кульъязмалардан чүпләп, берәмләп-берәмләп җыелып туплап чыгарылган хезмәтләр алар.

Тагын шунысы да бар. Кульъязма китап, гомумән, кульъязма шактый серле, нечкәлекләргә ия булган үзенчәлекле нәрсә. Гарәп язуын таныган, басма китапларны гөрләтеп укый белүчеләрнең күбесе кульъязманы укый алмый, һәм бу гаҗәп тә түгел. Кульъязма текстларны укыр өчен махсус хәзерлек һәм тәҗрибә таләп итешә. Шуңа күрә андый язмаларның тузан җыеп, файдасыз ятуына, череп, ту-

зып юкка чыгуына караганда, галимнәр кулына эләгүе күпкә хәерлерәк.

Без Саба районының Байлар Сабасы, Сабабаш, Татар Икшермәсе, Иске Икшермә, Югары Шытсу авылларында булдык. Ике көн эчендә барлыгы 33 берәмлек кульязма һәм 37 басма китап тупланды. Ике көндә сыйфат ягыннан да уртача саналган мондый истәлекләрнең туплануы, башка төбәкләр белән чагыштырганда, зур хәзинә.

Саба ягына барып төшүгә үк безне халыкның аеруча мөлаемлыгы, ачык күңеллелеге, ярдәмчел һәм кунакчыл булуы таң калдырган иде. Шул хәтле китаплар да туплангач, куанычыбызның чиге булмады.

Татарстан Милли китапханәсенә бирелгән кульязмалар һәм китаплар, аларны озак еллар буе саклаучылар белән дә таныштырып үтәсе килә. Саба якларына барып чыгуыбызга сәбәпче булган кеше – Иске Икшермә авылында яшәүче Хатыйпова Рәшидә ханым Хатыйп кызы булды. Чөнки аның кулында гарәп язуындагы шактый язмалар булуы безгә Казанда ук билгеле иде. Шуңа күрә сәфәребезне аннан башладык.

Рәшидә ханымның әтисе Хатыйп Закиров (тумышы белән Иске Мичән авылыннан) яшьли ятим калган, Сатышның Габдрахман хәзрәт тәрбиясендә үскән. Ул Югары Шытсу авылында 1918 елдан 1928 елга кадәр имам булып торган. 1931 елда кулга алынып, 1934 елда ватанына кайткан һәм 1946 елда вафат булган. Аның кызы Рәшидә ханым исә озак еллар (Татарстанда, Себердә) математика укытучысы булып эшләгән. Әтисеннән калган изге мирасны яхшылап саклаган. Рәшидә ханым Хатыйпова Татарстан Милли китапханәсенә барлыгы унбер кульязма (китаплар һ.б. төрле тарихи язмалар) һәм 18 басма китап бүләк итеп тапшырды. Гарәп һәм татар телендәге бу кульязмаларның күпчелеге XIX гасыр уртасында күчереп язылган. Иң әүвәлгеләре XVIII йөз ахырына карый. Эчтәлекләре буенча дини хикәятләр, хәдисләр, төрек язучысы Мөхәммәт Чәләбинең күләмле шигъри «Мөхәммәдия» әсәре, мантыйк буенча шәкерт конспекты, мөнәҗәтләр, ислам тарихы буенча язмалар һ.б. Язмаларның фәкать берсендә – XVIII гасыр ахырына караган ислам дине тарихын тасвирлаган кульязмада гына күчереп язучысының

иссеме күрсәтелгән. Ул – Шытсу авылыннан Яхъя улы Сөнгатулла. Ә басма китапларның күпчелеге үткән гасырда Мисырда һәм Төркиядә басылган. Алар, нигездә, шәригать кануннары, Коръән тәфсире, тел белеме кагыйдәләре буенча һәм барысы да диярлек гарәп телендә.

Икенче бай китап тупламын безгә Байлар Сабасында яшәүче Равил әфәнде Гәрәев тапшырды. Ул безгә тугыз кульязма берәмлек һәм унике басма китап бирде. Кульязмалар төрле эчтәлектә: 1918–1920 елларда Г.Тукай һәм башка шагыйрьләрнең күпсанлы шигырьләре, җырлар теркәлгән ике дәфтәр, гарәп теле грамматикасы (XIX гасыр башында язылган), шигъри әсәр һәм дин нигезләре буенча язмалар (XIX гасыр башы) һәм башкалар. Иң борынгысы 1794 елда күчерелгән гарәп телендәге «Шәригател-ислам» кульязмасы. Басма китаплар арасында мәгълүм татар галимнәреннән Газиз Гобәйдуллинның «Диннәр тарихы» (1918), Г.Ибраһимовның «Татар нәхүе» (1917), Ризаэтдин Фәхретдиннең мәшһүр Шәрык философы Әбүл-Галә Әл-Мәгарри турындагы китабы (1908), Фатыйх Кәриминең география буенча хезмәте (1904) һәм башка кызыклы китаплар бар.

Сабабаш авылында яшәүче Равил ага Исмәгыйлевләр гаиләсендә дә күп санда кульязма китаплар күреп бик шатланышкан идек. Әмма аларны кулга алып, битләрен ачып карагач, кәефебез кырылды. Чөнки ул китапларга кәгазь чире эләккән. Ә ул бик яман нәрсә. Ягъни, кәгазь битләре әкренләп бозылып, череп, таркалып баралар. Кичектермичә, белгечләр тарафыннан химик санитария эшкәртүе үткәрелмәгәндә фән өчен кыйммәтле булган әлеге язмалар бозылып, файдасыз бер чүп өеменә әверелергә мөмкин. Бу тупламадагы кульязмалар барысы да гарәп һәм фарсы телләрендә. Эчтәлекләре ягыннан фән өчен күптәннән мәгълүм әсәрләр һәм хезмәтләр. Аларның фәнни кыйммәте исә башкада: төрле калынлыктагы егермегә якын кульязма китапның күпчелеге бер кеше – Сәлимҗан угылы Ибраһим кулы белән язылган. Мәсәлән, безнең кулга кергән шундый бер китапның ахырында мондый мәгълүмат бирелгән: «1255 елның (милади белән 1839 ел – *Р.М.*) зөлхиҗҗә аенда Казан вилаяте, Җөри юлының Кече Сөн карьясендә мелла Садыйк улы дамелла Фәхретдин әл-Бөрсети мәдрәсәсендә... Сәлимҗан улы Ибраһим әл-Морзавый кулы белән язылды». Менә шул, бер кеше та-

рафыннан күчерелүләре ягыннан бу кульязмалар фәнни игътибарга лаеклы һәм мондый аерым коллекцияләрнең гыйльми оешмаларда сакланган очракта гына файда китерәчәге көн кебек ачык. Ә шәхси кулларда алар тиешле тәрбия, игътибар күрә алмаячак һәм галимнәр өчен дә билгесез хәлдә калып, юкка чыгачак.

Равил ага Исмәгыйлевләр шул кульязмаларның бер өлешен безгә тапшырдылар. Болар: XVIII гасыр ахырында күчерелгән әхлак буенча хезмәт, XIX гасыр башында язылган «Мирсәед шәриф» китабы (ислам кануннары буенча мирас бүлү мәсьәләләренә багышланган, мөселман татар мәдрәсәләрендә күп гасырлар дәвамында хисап буенча дәреслек булып кулланылган), гарәп теле буенча 1840 елда язылган дәресләр. Иң борынгысы исә 1710 елда күчерелгән «Мөхтәсарел-викайә фи мәсаилел-һидайә» исемле шәригать буенча фундаменталь хезмәт.

Татар Икшермәсе авылыннан Марат абый Нургалиев XVIII йөз ахыры – XIX гасыр башында язылган хикәятләр, дини әсәрләр теркәлгән кызыклы җыентыклар бирде. Шул ук авылдан Бибимәрфуга апа Нуретдинова, Рокыя апа Солтанова, Югары Шытсу авылыннан Муллагаян Гыйззәтуллиннар да безгә кульязма һәм басма китаплар тапшырды. Байлар Сабасыннан Рөстәм Әхмәт улы Галиев, Һаҗәр ханым Гатауллина да шактый кызыклы басма әсәрләр белән шатландырды.

Бабай-әбиләрдән мирас булып калган шушындый зур рухи байлыкны озак еллар саклап килгән һәм җөмһүриятебезнең гыйльми оешмаларыннан берсе булган Татарстан Милли китапханәсенә тапшыручы һәркемгә китапханә идарәсе исеменнән олуг рәхмәтебезне белдерәбез.

Безнең бу сәфәрне оештыруда зур булышлык күрсәткән, безнең белән бергә авылларга чыгып һәм Байлар Сабасының үзендә дә өйдән-өйгә озатып йөргән Саба районы китапханәсе директоры Илдар әфәнде Яхинга (үл үзе дә гарәп язулы китаплар бүләк итте), китапханә директоры урынбасары, безнең белән күптәннән хезмәттәшлек итеп килүче Римма ханым Миңнебаевага, музей җитәкчесе Рәисә ханым Сираҗиеваларга аеруча зур рәхмәтебезне юллыйбыз.

Безгә Казанчы Бигәнәй авылы зиратының ишаннар каберлегендә дә булырга туры килде. [...]

Югарыда язылганнарга нигезләнеп, Саба яклары кызыклы тарихи истәлекләргә ифрат бай дип әйтә алабыз. Мирасыбызга тагын да игътибарлырак һәм сакчылрак мөнәсәбәт булганда, Саба ягы алга таба да тарихыбызга, фәнебезгә күп яңалыклар өстәргә мөмкин. Бу эшкә Саба районы халкы тагын да ярдәм итәр дип уйлыйбыз. Гарәп язуындагы борынгы язмалары, китаплары булган милләттәшләребезнең безгә яисә Саба районы китапханәсенә хәбәр бирүләрен үтенәбез.

*1994 ел, 26 октябрь.*

## ИЖАУ МӘЧЕТЕНДӘГЕ ТАРИХИ МАТЕРИАЛЛАР

Үткән, ягъни 1993 елның декабрь аенда милләттәшләребездә сакланып калган гарәп язулы борынгы кульязма истәлекләр һәм басма китаплар белән танышу өчен Ижауга барган идек.

Иң беренче эш итеп мәчеткә юл тоттык. Анда Габдулла хәзрәт һәм мәчет картлары безне бик җылы каршы алды. Максатыбызны аңлаткач, Ижау мәчетендә дә әүвәлге язмалар һәм тузган китаплар барлыгы ачыкланды. Алар арасында электән үк сакланып килгәннәре дә, соңгы берничә дистә ел дәвамында үзләре гарәп язуын танымаучылар тарафыннан яки бик тузып, таушалып беткәнгә күрә китерелгәннәре дә бар иде.

Күп санлы төенчекләрне сүтеп, һәр кәгазьне кулга тотып карагач, фән өчен кызыклы һәм татар тарихына кагылышлы гарәп язулы кульязма китаплар һәм кайбер документларны аерып алдык. Мәчет идарәсенең ризалыгы белән бу материаллар Татарстан Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә алынды. Китапханәбезнең бу бүлеге нәкъ менә тарихи һәм әдәби ядкәрләрне барлау, аларны өйрәнү, саклау һәм җәмәгатьчелекне шундый материаллар белән таныштыру эшен башкара.

Ижау мәчетеннән барлыгы җиде берәмлек кульязма алдык. Аларның дүртесе татар мәдрәсәләрендә файдаланылган кульязма китаплар: XIX гасыр урталарында күчерелеп язылган «Гакаид», «Фикъһ» (1866 елгы), фәлсәфә буенча гарәп телендәге хезмәт (1869 ел), XIX гасырның беренче яртысында күчерелгән гарәп теле син-

таксисы китабы. Шулай ук татар телендә XIX гасырның икенче яртысында язылган медицина буенча әсәрнең аерым битләре, күренекле татар шагыйрьләреннән Габделҗәббар Кандалыйның «Мөнәҗәт»е (1899 елда күчерелгән), Гали Чокрыйның XIX гасыр ахырында күчерелгән бер шигыре.

Басма китаплар барлыгы егерме данә булды. Эчтәлекләре ягыннан алар төрле: әдәби, дини, гарәп теле буенча һ.б. Иң искесе 1841 елда Казанда басылган «Кыйссаи Сәйфелмөлек» китабы. Шулай ук 1845, 1859 елларда басылган китаплар да бар.

Ижау мәчете тарихына караган документаль материаллар аерым бер төркем. Бер өлеше мәчет имамнары тарафыннан язылган 1844, 1845 еллардагы һәм совет чорындагы мәхәллә метрикәләре. Ижау мәчетенең метрикә дәфтәрләре 1844 елда языла башлаган. Анысының берничә бите генә сакланган. 1844 елда Иж заводында эшләгән мөселман татарларның унбиш баласы дөньяга килгән. Барысының да аталары заводта мастеровойлар, фәкать берсе генә заводта хезмәт иткән унтер-офицер булган. 1845 елда да унбиш бала туган. Ул елда өч никах теркәлгән. Никахлашучыларның берсе – хәзерге Әгерҗе районының Наҗар авылы мулласы Габделгаффар Җармөхәммәд угылы Иж заводы мастеровоеның кызын кияүгә алган. Икенче өйләнүче Әгерҗенең Әхмәди Габдеррәхим улы булган. Ул елларда Ижда имам булып Хәбибулла Нигъмәтулла улы торган.

Метрикә дәфтәрләренең башкалары 1921, 1922, 1938–1940 елларда язылган. Шуны искәртик, бу елларда туган, үзләренең туу көннәрен ачыклыйсы килүчеләр булса, безнең китапханәгә мөрәҗәгать итә алалар.

Бу тарихи документларда теркәлгән туучы, вафат булучы һәм никахлашучылар турындагы мәгълүматларда кемнең кайсы як кешесе булганлыгы язып барылган. Метрикә язмаларыннан күренүенчә, Ижау татарларын, нигездә, Сарапул, Алабуга, Минзәлә һәм Чистай өязләреннән күчеп килүчеләр тәшкил иткән. Аларның күпчелеге хәзерге Әгерҗе районы (Әгерҗе, Бубый, Көчек, Тирсә, Наҗар, Сокман, Кырынды, Төрдәле, Салагыш һ.б.) авылларыннан.

Минзәлә өязенең Пучы, Байсар, Адай, Аккүз, Биклән, Шыгай, Малтабар, Куян авылларыннан, Чистай өязенең Акъяр һәм Каргалы авылыннан килеп төпләнүчеләр дә күп булган.

Болардан тыш Казан губернасының Казан, Лаеш, Тәтеш, Зөя, Мамадыш, Чабаксар, Вятка губернасының Малмыж өязендәге авыллардан заводка эшкә килеп, төпләнеп калучылар да булган. Тик болары азчылыкны тәшкил иткәннәр.

Мәчетнең совет заманындагы катлаулы язмышын чагылдырган документлар да күп сакланган. Бигрәк тә 1930 нчы елларда властьларның мәчетне җимертергә һәм яптырырга тырышуы, халыкның зур кыенлыклар белән саклап калуы тарихи документлардан ачык күренә. 1936–1938 нче елларда мәчет идарәсе тарафыннан язылган дин тотучылар исемлегеннән күренүенчә, ул вакытта шәһәрдәге иман әһелләре җиде йөзләп кеше булган.

Хәзер Ижауда яңа мәчет бинасы төзелә. Бу мәчетне һәм Ижауда яшәүче барлык мөселман милләттәшләребезне әүвәлдәгедәй бәлакազалардан, мәшәкатьләрдән Ходай үзе сакласын иде.

*1994 ел, 4 декабрь.*

## СИРӘК КУЛЪЯЗМАЛАР ИШӘЯ

Борынгы китаплар фондын баету буенча Татарстан Милли китапханәсе үзенең күптөрле эзләнүләрен дәвам итеп килә. Китапханә хезмәткәрләренең соңгы вакытта юлыккан кайбер кызыклы табышлары белән газета укучыларны да таныштырмакчы булабыз. Күптән түгел генә (февраль аенда) Шиһабетдин Мәрҗани нәселе варисларыннан Суфия ханым һәм Мәхмүт ага Мостафиннар безгә бабалары Габдулла Апанаевтан калган китапларны тапшырдылар. Габдулла Апанаев (1862–1919) – үз чорының күренекле җәмәгать эшлеклесе, Казанның мәшһүр милләтпәрвәр муллаларыннан берсе, мөхәррир һәм нашир. Җәмәгате исә – Шиһабетдин Мәрҗанинең кызы Хауа (1870–1945). Габдулла хәзрәт Апанаевның төрле янгын-афәтләрдән исән калган бай китапханәсенең бер өлеше озак еллар буена оныклары Мостафиннар кулында сакланган. Китапларның һәрберсенә хуҗасы тарафыннан «Г.Апанаев милке» дип язылган. Кыйммәтле җиде берәмлек кулъязма, шулай ук Казанда, Төркиядә, Мисырда, Һиндстанда басылган утыз басма китап Милли китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә үз урыннарын алды. Басма китап-

ларның берничәсендә Ш.Мәрҗани кызы Хауаның автографлары, ә арада Мәрҗанинең үз кулы белән язылганы һәм шәхси мөһере сугылганы да бар. Әлеге китаплар арасында Мәрҗани әсәрләре дә бар. Кулъязма китапларны Мәхмүт ага берничә ел элек академик Әбрар Кәримуллинга биргән булган, ә Әбрар ага аларны Милли китапханәгә тапшырды. Әйтергә кирәк, кулъязмалар шактый борынгы (1687, 1690 һ.б. елларныкы) булсалар да, яхшы сакланган.

Казан шәһәренең 1 нче татар гимназиясен (элекке 35 нче мәктәп) белмәүчеләр бик сирәктер. Татарстан Милли китапханәсе гимназия җитәкчелеге (хәзерге директоры Фәния Мифтахова) белән тыгыз элемтә урнаштырды. Бу мәктәп-гимназиядә инде утыз елга якын гаҗәеп бер музей эшләп килә. Нинди генә экспонатлар юк анда: мамонт һәм бизон сөякләре дисеңме, борынгы болгар сугышчысының очлымы, Болгар шәһәрлегеннән табылган көнкүреш һәм сугыш кораллары дисеңме, Казан шәһәрендәге Татар бистәсенең үткән тормышын төрле яктан чагылдыручы әйберләр, стенд һәм альбомнар, борынгы кулъязма һәм басма китаплар... Озак еллар музейның җитәкчесе булып эшләүче тәҗрибәле укытучы Гөлчирә ханым Шәмсетдинованың һәр экспонат хакында, Татар бистәсенең тарихы турында сәгатьләр буена сөйләрлек мәгълүматы бар. Балаларда милли үзаң тәрбияләүдә гимназиянең үзендә шундый бай музей булуы, һичшиксез, зур горурлык. Гомумән, Беренче гимназиянең эш тәҗрибәсе, педагогик традицияләре, шулай ук андагы музей эшчәнлеге әтрафлы махсус бер мәкалә язачак татар журналистын көтә.

Безнең исә бу хакта сүз башлауның сәбәбе – гимназия һәм музей җитәкчеләренең, татар кулъязмаларының тарихи әһәмиятен аңлап, аларны Татарстан Милли китапханәсенә тапшыруларында.

Гимназия музеennan килгән кызыклы кулъязмалар арасында сәүдә эшләренә кагылышлылары, аерым алганда, 1765–1767 елларда теркәлгән татарча хосусый актлар һәм «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе» аеруча игътибарга лаеклы язма истәлекләрдән санала. 1751 елда Һиндстанга сәфәр кылган Исмәгыйль Бикмөхәммәт угылы сәяхәтнамәсенең моңа кадәр фәнгә тугыз язма нөсхәсе мәгълүм иде. Милли китапханәгә тапшырылган нөсхә дә шактый тулы (ахырындагы ике бите генә югалган) һәм яхшы хәлдә сакланган. Күчерелү вакыты – XIX гасырның беренче чиреге.

Халкыбызның аңы, хәтере, тарихы теркәлгән язма һәм басма китапларның тарихи әһәмиятләрен тирәнтен аңлаган милләттәшләребезгә олы рәхмәтебезне белдерәбез. Мондый кадерле ядкәрләрнең турыдан-туры шул юнәлештә эш алып баручы гыйльми оешмаларда саклануы күптармаклы фән дөньясы һәм киләчәгебез өчен дә күпкә отышлы.

*1995 ел, 1 март.*

## КУКМАРА ТӨБӘГЕ ТАРИХЫННАН КАЙБЕР СӘХИФӘЛӘР

Быелның 11–14 июнь көннәрендә Кукмара районының Мәчкәрә, Төркәш, Яңа Чәбия, Киндеркүл һәм Манзарас авылларында булган идек. Шушы авыллардан барлыгы 65 берәмлек кулъязма һәм 28 басма китап тупланды. Берничә көн эчендә бер кеше тарафыннан шул хәтле язма истәлекләр туплануы археографик тәҗрибә күзлегеннән караганда зур табыш санала. Шулай ук бу факт Казан арты төбәгенең әүвәлдә никадәр гыйлемле, никадәр мәдәниятле булганлыгын раслый. Югыйсә, татар китабының күпмесе урыс хакимлеге дәверендә юкка чыгарылган, яндырылган. Ә совет чорында гыйльми оешма вәкилләре күпмесен Казан каласына ташыган. Тик шулай да, язма ядкәрләр, әлхәмделилләһи, һаман да бар, әле дә табылып торалар. Татар тарихында каһәр суккан колониаль дәвер, утызынчы еллар золымы кебек кара сәхифәләр булмаса, биниһая бай китапчылык һәм гыйлем дөньясына ия булыр идек.

Кукмара районы авылларында безнең тарафтан моңарчы да шактый гына кулъязма китаплар, истәлекләр җыйналган иде. Мәсәлән, 1990 елда Кәчемир авылында яшәүче Бариев Гали ага, Әхмәтҗанов Әхмәтша абзый, Зөфәр абый, Хаҗиева Мәймүнә әби һ.б. фән өчен кызыклы булган күп кенә язма һәм басма китаплар тапшырган иделәр. Хәзерге вакытта ул китаплар Казан университеты фәнни китапханәсендәге, Татарстан Милли китапханәсендәге Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлекләрендә саклананалар.

Шулай ук 1993 елның ноябрендә китапханәбезнең фәнни хезмәткәре Ирек Һадиев белән Мәмәшир, Уразай, Зур Сәрдек авылларында булып шактый гына китаплар туплап кайткан идек. Алар

арасында Һибәтулла Каргалый, Әбелмәних Каргалый кебек, XIX гасырда яшәгән мәшһүр татар шагыйрьләренең шигырьләре язылган җыентыклар, төрле хикәятләр, халык медицинасына караган кызыклы кульязмалар бар иде. Уразай авылында Гариповлардан кызыклы кульязмалар алган идек.

Ә быелгы археографик сәфәребезгә Казанда яшәүче, элекке очучы Нуриев Әюп абый белән сөйләшүебез сәбәпче булды.

Яз көннәренең берсендә Әюп абый китапханәбезгә күп кенә гарәби язулы китаплар күтәреп килде. Фән өчен тарихи кыйммәте, әһәмияте бардыр дип туган авылы Төркәштән алып килгән ул аларны безгә. Әюп абый кебекләргә күпме рәхмәтләр укысаң да аз булыр кебек.

Идел буе төрки-татар әдибе Хөсам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастанының кульязма күчермәләре сирәк очрый. Төркәштән Әюп абый алып килгән язмалар арасында әлеге дастанның XIX гасыр уртасында күчерелгән кульязмасы булу әдәбият тарихы өчен кыйммәтле табыш. Шул ук тупламдагы «Авык кыйссасы», «Нәүрүз бәете» дә шул җөмләдән.

Ә.Нуриев барлыгы 19 берәмлек кульязма алып килде. Алар янына Төркәштә без тапкан китапларны да өстәсәк, шушы авылдан гына барлыгы 41 берәмлек борынгы кульязма табып алынды һәм Милли китапханә фондына саклауга тапшырылды.

Төркәш авылында кульязма һәм иске басма китапларны, нигездә, Касыйм бабай Габделкави улыннан, Бакыев Галим, Гатауллин Мохтарулла, Рәкыйпов Әмирхан, Талипов Хәбибулла агалардан, Яппарова Рабига апалардан алдык. Кульязмалар тематик яктан күптөрле: XVIII гасырда күчереп язылган хикәятләр, шигырьләр, бәет-мөнәҗәтләр, медицина һәм төш юрау буенча язмалар һ.б. Төркәш авылында безнең эшебезгә Үзбәк абый Нуриев һәм Хаҗиб әфәнде Гыйльманов бик теләп һәм тирәнтен аңлап ярдәмләштеләр. Х.Гыйльманов биргән кульязма битләр аеруча игътибарга лаек. Ул – Төркәш авылы тарихы. Бу тарих 1939 елда шул авылның Гобәйдулла Рәхмәтулла улы атлы укымышлы карты тарафыннан язылган булган. Кызганычка каршы, безнең кулга авыл тарихының ике бите генә эләкте. Калганы, күпчелек өлеше, әлегә табылмады. Гобәйдулла карт Төркәш тарихын өлкәннәрнең истәлекләренә нигезлә-

неп язган булган. Авылны нигезләүчеләр көчләп чукындырудан качып, XVIII гасырның беренче яртысында Казан ягыннан күчеп утырганнар дип яза ул. Мондый язма авыл тарихларының табылуы һәм фәнни хәрәкәткә керүе аерым авыл яки төбәк тарихы белән беррәттән, гомумтатар тарихы өчен дә әһәмиятле.

Кукмара районы халкына шактый мәгълүм шәхес – Мәчкәрә авылында яшәүче Вакыйф ага Зәйнуллиннан май ае ахырында китапханәбезгә хат килеп төште. Вакыйф абый үзендә борынгы кулъязма китаплар барлыгын, зиратта борынгы кабер ташлары да күплеген әйтеп, безне чакырган иде. Шул рәвешчә, Кукмарага сәфәребезне Мәчкәрәдән килгән хат та тизләтте.

Вакыйф абый биргән 9 кулъязма китапның иң борынгысы XVII гасырның соңгы чирегендә язылган дини мәҗмуга. Шулай ук XVIII гасырда күчерелгән китаплар да берничә. Гомумән, В.Зәйнуллин тапшырган китаплар башка авыллардагы табышлардан борынгы булулары белән аерылып тора. Хәтта басма китапларның да берсе, Аллаһыяр Суфыйның «Сөбател-гаҗизин» исемле шигъри әсәре шактый иске – 1820 елгы Казан басмасы булып чыкты. Вакыйф ага әйтүенчә, бу китаплар Мәчкәрә мәдрәсәсе китапханәсеннән калганнар.

Тарихлары белән Мәчкәрәгә бәйле булган башка китаплар хакында да бу урында мәгълүмат биреп китәсе килә. Танылган академик Әбрар ага Кәримуллин үзендә саклана торган борынгы кулъязма китапларны шушы елның башында безгә бүләк итеп бирде. Алар исә үз вакытында Әбрар агага Казанның мәшһүр муллаларыннан берсе, мөхәррир һәм нашир Габдулла Апанаев оныклары тарафыннан тапшырылган булганнар.

Әбрар ага биргән «Шифаи шәриф» дип аталган XVII йөз ахырында күчереп язылган бер кулъязмада татарча һәм урысча мөһерләр сугылган. Татарчасы: «Хәсән бине Мостафа әл-Мәчкәрәви», русчасы «Малмыжский купец Хасан Мустафин-Утямышев» диелгән. Ә гарәп теле синтаксисы буенча 1690 елда күчерелгән икенче кулъязмада, «Муса бине Габдулла» дигән мөһер бар. Бу зат та Мәчкәрә Үтәмешевләреннән. Шунысы кызык, нәкъ шундый ук мөһер Вакыйф абыйдан алынган китапларда да очрый. Югарыда телгә алынган Габдулла Апанаевның җәмәгате Шиһабетдин Мәрҗани-

нең кызы Хауа булган. Димәк ки, Ә.Кәримуллин тапшырган әлеге мөһерле кулъязмалар Ш.Мәрҗанинең үзе тарафыннан Мәчкәрә Үтәмешевләреннән алынып, аннары кызы Хауа кулына кергән булуы да бик ихтимал.

Сәфәребезнең төп максаты борынгы кулъязма истәлекләр белән танышу, аларны барлау һәм туплау булса да, ташъязма истәлекләргә дә игътибарсыз булмадык. Мәчкәрә зиратында сакланып калган чыдам һәм затлы ташлардан эшләнгән каберташ язмалары да авылның борынгыдан бай һәм мәгърифәтле булуын тулаем чагылдыра. [...][*]

Мәчкәрә һәм Манзарас зиратларындагы кабер ташларыннан язып алынган мәгълүматлар һәм берничә кулъязма китап Кукмара районы музеена тапшырылды.

Манзарастан шулай ук әһәмиятле кулъязмалар табылды. Кукмара гимназиясендә гарәп теле укытучысы, Манзараста яшәүче Фаяз ага Сафин биргән кулъязмалар арасында әүвәлге татар-урыс бәрелешләрен тасвирлаган бер тарихи хикәятнең өзеге дә бар. XVIII гасырда язылган бу кулъязманың, кызганычка каршы, бер бите генә сакланып калган. Шулай да факт буларак, фән өчен анысы да игътибарга лаек. Шул ук авылның Гөлнур ханым Шакировалардан алынган кулъязмалар арасында XVII гасырда иҗат ителгән, аеруча сирәк очрый торган кулъязма әсәрләрнең берсе – «Аксак Тимер дастаны»ның XVIII гасыр күчермәсе килеп чыгу да зур табыш.

Ә менә Киндеркүл авылында яшәүче Хәбибрахманова Фәүзия апаларда бабалары Хәбибрахман Габдулла улының Кәчемир мәдрәсәсендә белем алганда тарих һәм дин сабагы буенча 1892–1893 елларда язган дәфтәрләре сакланган. Кәчемир мәдрәсәсенең җитәкчесе Габдулла хәзрәт Таҗетдинов 1889 елдан Кәчемирдә имамлык вазифасын үтәгән, XX гасыр башында чыккан татар газета һәм журналларында мәкаләләре басылган мәгълүм шәхес. Киндеркүл авылының Габдеррәүф ага Әхмәдиев тапшырган язмалар арасында 1930 нчы елларда репрессияләнгән татар мулласының шигъри юллар белән язылган зарлы-сагышлы хаты да бар.

Яңа Чәбия авылында Кавиев Рәкыйп, Ибраһимов Илгизәр һәм Хәләмгөл әби Шәрифуллиналардан алынган кулъязма хикәятләр,

---

[*] Бу урында Мәчкәрә һәм Манзарас авыллары зиратларындагы борынгы ташлар турында язылган иде.

шигъри җыентыклар, бәетләр дә шулай ук кызыклы һәм рухи истәлекләребез хәзинәсен баеталар.

Кукмара районының берничә генә авылында шул хәтле бай тарихи материал туплануы бик куанычлы хәл, әлбәттә. Алла боерса, эшебезне туктатмыйча, киләчәктә дә дәвам итәчәкбез һәм район халкын газета битләре аша эзләнүләрнең нәтиҗәләре белән даими таныштырып барырга уйлыйбыз. Кукмара районының башка авыллары да ачык йөз һәм киң күңел белән каршы алачакларына ышанабыз. Һәр авылның да үз Вакыйфлары* һәм Әюпләре, үз Үзбәкләре һәм Фаязлары, үз Хаҗиблары бардыр. Алар безгә, һичшиксез, ярдәм кулы сузар дип өметләнәбез.

*1995 ел, 29 август.*

## КҮМЕЛГӘН КИТАПЛАР

Татар китабы тарихы никадәр мактанычлы булса да, аның аянычлы яклары шулкадәр үк күп. Татар китабы гасырлар дәвамында күпме җәбер-михнәтләргә, яндыруларга дучар ителгән. Ә совет чорында гарәп язулы китапны яндырып кына калмыйча, аны җиргә дә күмәләр. Дистә еллар буе йөзәрләгән, меңәрләгән китапны капчыкка, сандык һәм тартмаларга тутырып күмәләр. Бу хәл соңгы елларда да кимеми, хәзерге вакытта да дәвам итә.

Мәсәлән, Кукмара районы авылларының берсендә яшәгән укымышлы картлардан берсе, гарәп язуын танып укый белүче булмаганга, аптыраганнан, «кем кулына эләгәсен белгән юк, мәсхәрә кылырлар» дип, вафаты алдыннан бер авылдашына әйтеп дүрт-биш ел элек китапларын зиратка күмдергән. Әлбәттә, аңа үзенең яшьтәш, фикердәш, иман вә гыйлем чыганагы булган китапларыннан аерылу бик авыр булгандыр. Китаплар җир куенына тапшырылгач, бабай озак яшәми, дөнья куя.

Картның гозерен үтәгән агайны июнь аенда күреп сөйләшеп, китапларның күп булуын, аларны зур калай ләгән эченә тутырып, өсте-

---

* Бу мәкалә чыкканнан соң Кукмара район газетасында Вакыйф абыйның кайтавазы басылды (Борынгы китаплар булса... // Хезмәт даны. – 1995. – 9 декабрь). Ул анда яңадан кульязмалар табып безгә җибәргәнлеген дә язды.

нә целлофан белән каплап күмгәнлеген ачыклаган идем. Аеруча кызыксынучылар шул вакытта ук «әйдә, казып карыйк, бәлки сакланганнардыр» дип җилкенгәннәр иде. Әмма мондый хәлләр татарлар яши торган һәр төбәктәге авылларның шактыенда кабатланганлыктан, җиргә әләккән китапларның аянычлы язмышы безгә яхшы таныш. Җир куенына кергән кәгазь һәм китаплар берничә ай эчендә файдаланып булмаслык, юеш, тоташтан дымлы бер массага әйләнгәнлеген күп күргәнгә, бу эшне ул чагында кирәксез санадык. Ләкин шул ук хәбәр Кукмара район газетасы һәм «Мәдәни җомга» газетасы хезмәткәрләре аша октябрь аенда яңадан үзебезгә килеп иреште. Дөрес, информация бераз үзгәргән иде: имеш, китаплар целлофан капчыкка тутырылган һәм аларның күмелүләренә ике-өч ел үткән. Авыл кешеләре шуны казып алмакчы булалар икән дигән хәбәр килгәч, анда барып катнашырга һәм фотога төшереп, гыйбрәт өчен халыкка җиткерергә кирәк дип хәл иттек. Бу фактны киң җәмәгатьчелеккә җиткерергә карар кылып, 10 ноябрьдә юлга чыктык.

...Тирән чокырдан ләгәнне җир өстенә чыгарганда, анда катнашкан кайбер журналистлар көткән сенсация, әлбәттә, чыкмады. Югарыда әйтелгәнчә, дымланып, коргаксып, бер-беренә ябышып беткән китаплар иде. Карап торырга тулы хәлендәге кырыклап басма китап булганлыгы ачыкланды. Алар арасында Коръән, Коръән тәфсире (Ногмани), Зыяэтдин Камалиның «Фәлсәфәи игътикадия» әсәре, күп кенә Истанбул һәм Мисыр басмалары булган. Аларны шул ук чокырга яңадан күммичә чара юк иде.

Юеш, тоташ соры китап калдыкларына текәлеп сүз әйтә алмыйча торганда, минемчә, һәркемне бер төрле тәэсирләр биләде. Мескен татар халкының аңы, тарихы, әдәбияты, мәдәнияте, даны-шәүкәте – һәммәсе әлеге ләгән эчендә ятадыр, татар халкы үзе дә шул ләгәнгә салып җиргә күмелгән китаплардай, балчык белән аралашып, тимер күлмәк-савыт эчендә коргаксып беткәндер кебек тоела иде...

Моңарчы күпме мирасыбыз юк ителгән, моннан соң да аң һәм иман, гыйлем чыганагы булган китапларны күмүләрдән, яндырудан саклыйсы иде. Җан иясен тереләй җиргә күмүгә яки тереләй утка салуга тиң булган бу вәхшәттән туктатасы иде бит халыкны. Әйткәнебезчә, мондый фактлар һәр төбәктә, һәр авылда диярлек очрый.

Гарәп язуыннан аерылган төп масса, гаҗизлектән, иске басма һәм кулъязма китапларны мәчетләргә дә илтеп куючан. Ә мәчетләр исә аларны шулай ук йә яндыра, яки күмә. Мәсәлән (авыллардагы хәлләрне әйткән дә юк), Россия башкаласы Мәскәүдәге җамигъ мәчеттә бу эш бүген дә шулай дәвам итеп килә. Киң таралган әлеге күренеш татар археографиясенең аеруча борчулы мәсьәләләреннән берсе булу белән бергә, милләтебез фаҗигасе дә.

*1995 ел, 16 ноябрь.*

## БОРЫНГЫ ЯЗМАЛАР НИ СӨЙЛИ?

Безнең китапханә хезмәткәрләре тарафыннан җөмһүриятебез районнарына, шулай ук күрше республикаларга даими рәвештә археографик экспедицияләр һәм сәфәрләр оештырыла.

Күптән түгел, ягъни 1995 елның декабрендә һәм 1996 елның гыйнвар, февраль айларында без Балтач районының кайбер авылларында булдык. Әлеге язмабызда сәфәрләребезнең нәтиҗәләре белән таныштырмакчы булабыз. [...]

Бу юлларның авторы 1980 нче еллар уртасында, студент чагында эшкә җибәрелгәч, Сасна авылыннан кулъязма истәлекләр җыйнап Казан университетының гыйльми китапханәсенә тапшырган иде. Ул вакытта Саснада муллалык вазифаларын үтәүче Шамил бабай Шакиров һәм ул чактагы мәктәп укучысы, хәзерге аспирант Гамил Гыйбадуллин бик зур ярдәм күрсәттеләр.

Бөрбаш авылы мәчетендә борынгы китаплар тупланганлыгын ишетеп, үткән елның 19 декабрендә авылның имам-хатыйбы мөхтәрәм Җәлил хәзрәт Фазлыев янына юл алдык. Чынлап та, мәчеттә китаплар шактый иде. Андагы китап байлыгы арасыннан без фәнни, тарихи әһәмияткә ия булган кулъязма китапларны һәм иске басма китапларны сайлап алдык. Бөрбаш мәчетеннән Татарстан Милли китапханәсенә барлыгы 31 кулъязма берәмлек һәм 13 басма китап алынды. Алар эчтәлекләре ягыннан ислам шәригате, диниәхлакый, әдәби һәм гарәп теле буенча язылган китаплар. Кулъязмаларның иң борынгысы 1792 елда күчерелгән әхлак-әдәп буенча китап. Шәригать кануннары, ягъни мөселман юриспруденциясе буен-

ча «Шәрхел-викаййә» китабы 1798 елда күчереп язылган. Арада Җәлалетдин Руми, Аллаһыяр Суфый, Фәридетдин Гаттар кебек күренекле Шәрык әдипләренең шигъри әсәрләре күчермәләре дә бар. Аларның кайберләре XIX гасыр башында язылган булып, төшкән битләре 1891–1902 еллар арасында Мөхәммәтгариф мулла Мөхәммәди угылы һәм Бибифатыйма мулла Мөхәммәди кызы тарафыннан өстәп язылып тулыландырылган. Шул ук Мөхәммәтгариф Мөхәммәди улы Сәидев әл-Бөрбаши әл-Мәмсәви кулы белән 1878–1881 елларда гарәп теле дәресләре, тәҗвид, хәдисләр һ.б. язылган кулъязма җыентык та бар.

Татар кулъязма китапларын иске кулъязма битләреннән ябыштырып эшләнгән катыргы белән тышлау гадәте булган. Җәлил хәзрәттән алынган бер кулъязма китап тышлыгындагы шундый битләрне махсус ысул һәм чаралар ярдәмендә җебетеп бер-береннән аерган идек. Ул битләрдә кызыклы гына хатлар язылган булып чыкты. Китап тышлыклары өчен кәгазь кытлыгыннан, кыйммәтлегеннән төрле гариза һ.б. шундый хосусый актлар, документлар, хатлар, искергән кулъязма битләре кебек, вазифалары үтәлгән дип саналган кәгазьләр бик еш файдаланылганы татар археографиясендә мәгълүм. Хатлар барлыгы 22 данә булып, һәммәсе дә бер кешегә – Курса авылы имамы Хәсән бине Хәмиткә адреслап, 1850–1855 елларда язылганнар. Хәсән бине Хәмит әл-Мөслими (1812–1872) Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» (Казан, 1989, 336–337 бб.) китабында да телгә алынган билгеле шәхес. Ш.Мәрҗани аның мәгърифәтче галим, философ Габденнасыйр Курсавиның бертуган агасы Габделхаликъ ишанның кияве булганлыгы турында да яза.

Басма китаплар арасында Ш.Мәрҗанинең өч китабы булу аеруча игътибарга лаек. Мәгърифәтче әдип, фольклорчы галим Таиб Яхинның автографы теркәлгән «Тәүзих» китабы шулай ук фән өчен кыйммәтле табышлардан.

Быел 26 гыйнварда Балтач районы үзәгендә Татарстан Милли китапханәсенә багышланган тантана югары дәрәҗәдә оештырылып, бик матур бәйрәм рәвешендә үткәрелде. Әлеге тантанага да Җәлил хәзрәт борынгы кулъязмалар күтәреп килгән иде һәм ул аларны (4 берәмлек) бүләк итеп бирде. Бик матурлап бизәлгән күн

тышлыклы шәригать хөкемнәре буенча гарәп телендәге кульязма китап язуының, эшләнешенең матурлыгы белән генә түгел, борынгы булуы белән дә игътибарны җәлеп итә. Үзендә төгәл язылу вакыты күрсәтелмәсә дә, кәгазе һәм язу үзенчәлекләренә нигезләнеп аның XVII гасыр ахырында язылганлыгы һәм төшкән битләре 1815–1820 елларда тулыландырып, реставрацияләнгәнен әйтергә мөмкин.

Тантана вакытында Балтач мәдәният сараенда Милли китапханә фондларында саклана торган борынгы кульязма һәм басма китаплардан, гасыр башында чыккан татар телендәге газета-журналлардан торган күргәзмә оештырылды. Шулай ук Балтачның үзендә һәм районлагы төрле авыллардагы шәхси тупланмалардан алынган китаплар күргәзмәсе дә бай иде. Анда куелган китапларның кайберләре фәнни кыйммәткә дә ия. Түнтәр авылыннан китапханәче Гөлнур ханым Закирова алып килгән китапларның берсен сорап Казанга алып кайттык. Әлеге кечкенә күләмле, XVII гасыр ахырларында язылган җыентыкта мәшһүр төрки шагыйрьләрдән Сөләйман Бакырганый әсәрләре, төрле хикәятләр һ.б. теркәлгән. Шундагы бер шигъри әсәр игътибарыбызны үзенә тартты. Ул моңарчы әдәбият тарихында авторы билгесез, кызыклы гына шигъри әсәр. Һәрхәлдә, ул әле ныклап тикшерүне, өйрәнүне таләп итә. Ә хәзергә аның турында XVI–XVII гасырларда Идел буе татар шагыйрьләренең берсе тарафыннан иҗат ителгән дигән фаразны гына әйтергә мөмкин. Кызганыч ки, бу кульязма җыентыкның шактый битләре җитмәү сәбәпле, кем тарафыннан, кайчан һәм кайда күчерелүе мәгълүм түгел. Җитмәгән битләрен табып булмасмы дип, башка кульязма материаллар юнәтүне дә өмет итеп, озак та тормыйча, 14 февральдә, Түнтәр авылына махсус сәфәр кылдык.

Югарыда телгә алынган җыентык битләрен табу насыйп булмаса да, авылның кызыклы гына кешеләре белән танышып, башка кульязмаларга баеп кайттык. Бу сәфәрдә барлыгы 20 берәмлек кульязма материал һәм ундүрт иске басма китап тупланды. Иң күп кульязма материал тапшыручылар арасыннан Түнтәр авылының Йосыпов Тәлгатьләр гаиләсен, Мөбарәкшин Равил абыйларны һәм Мифтахова Бибинур апаларның исемнәрен атыйсы килә. Шулай ук барлык эшләрен читкә куеп, безгә бик зур ярдәм күрсәткән Түнтәр

авылы китапханәчесе Гөлнур ханым һәм мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе Лилия туташ Гайнетдинованы әйтеп үтәргә кирәк.

Түнтәрдән табып алынган борынгы материалларның күпчелеге шәригать мәсьәләләренә багышланган кулъязма китаплар. Гарәп теле грамматикасы буенча кулъязмалар, дини риваятьләр, хикәятләр, шәкерт дәфтәрләре, шигъри әсәрләр дә бар. Йосыпов Тәлгатьләрдән алынган «Гавамил» (гарәп теле дәреслеге) китабы Хәсән Габделмән улы Түнтәри кулы белән 1789 елда күчереп язылган. Ә XVIII гасыр ахырында күчерелгән фарсы телендәге шәригать китабы Хәлил улы Ибраһим Түнтәри тарафыннан язылган. Мөбарәкшин Равил абыйларда сакланган, XIX йөзнең соңгы чирегендә күчерелгән «Шәрхе викайә» китабы Мозаффар улы Мөхәммәтҗан кулы белән остазы Әбүннәкыйп Түнтәри өчен язылган. Түнтәр авылыннан табылган борынгы китапларның бер өлешен авыл китапханәсендә калдырдык, кызыксынучылар анда барып та таныша алалар.

Балтачта Китап бәйрәме вакытында тагын бер кызыклы фикер ишетеп сөенештек. Ул – Балтачта Китап музее оештыру турындагы хәбәр иде. Афәрин! Балтач районында милли-мәдәни чараларның, шулар белән беррәттән музейларның да, җиренә җиткереп, башкаларга үрнәк булырлык дәрәҗәдә оештырылганлыгы күптән мәгълүм. Моның шулай икәнлеген Китап музее җөмһүриятебез калаларының берсендә дә булмаган чорда, балтачлыларның шундый фикер күтәреп чыгулары тагын бер кат раслый. Үз тарафыбыздан бу матур башлангычны без дә хуплыйбыз һәм ярдәмләшергә әзерлегебезне белдерәбез.

Балтач районына оештырылган кечкенә генә сәфәрләребездә дә фәнни кыйммәткә ия булган 56 кулъязма берәмлек һәм 27 басма китап табылды. Әлеге материалларны барлауда һәм Татарстан Милли китапханәсенә алдыртуга ярдәм иткән барлык милләттәшләребезгә дә рәхмәтләребезне җиткерәбез. Ходай ярдәменнән ташламасын, алга таба да бергәләп хезмәттәшлек итеп яшәргә насыйп итсен, дигән теләктә калабыз. Дөньялар имин булып, киләчәктә дә Балтач районы авылларына археографик сәфәрләр оештыруны дәвам итәрбез дип уйлыйбыз.

*1996 ел, февраль.*

## ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН...

1996 елның февраль аенда Казан каласында чыгып килә торган «Иман» газетасы битләрендә Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге эшчәнлегенә багышланган махсус язма басылып чыкты. Анда халкыбыз тарихының иң кыйммәтле истәлекләре булган борынгы кулъязма китапларның фәнни әһәмияте, бүлек хезмәткәрләре тарафыннан аларны туплау һәм өйрәнү турында әңгәмә корылган иде.

Күп тә үтмәде, безнең бүлеккә борынгы кулъязмалар турында хәбәр иткән хатлар килә башлады. «Иман» газетасын Татарстаннан читтә яшәүче милләттәш һәм диндәшләребез дә алдырып укыйлар, шуңа күрә хатлар төрле төбәкләрдән килә тора. Андый хатларның берсен Самара өлкәсенең Камышлы районы Иске Ярмәк авылы имам-хатыйбы Габдулла Кәрим язып җибәргән. Ул үз хатында Иске Ярмәк авылы мәчетендә борынгы кулъязма китапларның күп булуын һәм аларны безнең китапханәгә – борынгы язмаларны фәнни өйрәнеп халыкка җиткерүче, пропагандалаучы, кадерләп саклаучы махсус оешмага тапшырырга карар кылганлыкларын белдергән иде.

Габдулла хәзрәт чакыруы буенча 9 апрельдә Иске Ярмәккә барып җиттек. Күрешкәч-танышкач, озын-озакка сузмыйча, мәчеттәге кулъязмаларны карарга бардык. Әйе, китаплар, чынлап та, күп иде. Ниләр генә юк: дин сабаклары, гарәп теле буенча язылган калын кулъязма китаплар, Кандалый шигырьләренең күчермәләре, бәетләр, җырлар һ.б. Аннан соң, караңгы төшеп, кич булуына карамастан, Камышлыга (район үзәгенә) юл алдык. Чөнки Габдулла Кәрим андагы имамнар белән дә сөйләшеп куйган һәм без килүгә Камышлы мәчетендәгеләр бу эштән хәбәрдар иделәр. Мәчет чормасындагы иске, таркалган, тузган байтак кына тарихи ядкәрләрнең гасырлар тузанын каккалап, берничә капчыкка тутырып алдык. Безне китаплардагы тузаннар, аларның кимерүче хәшәрәтләр тарафыннан теткәләнгән булуы, бите-биткә аерылып беткәнлекләре – һич берсе куркытмый, чөнки бу саргайган иске китап битләре Казанга кайткач һәрберсе тузаннан чистартылып, аерым папкаларга салынып, Алла боерса, озак елларга, кадерләп саклауга куелачак.

Гарәп язуындагы һәр борынгы китап битендә бабаларыбызның изге сүзләре һәм фикерләре, изге рухлары сакланган. Шуңа күрә һәр борынгы язма китап, хәтта аерым бер бите генә дә, безнең өчен газиз, кадерле. Без шул тарихи ядкәрләрнең лаеклы варислары булырга тиешбез һәм өлкәннәр сүзен, бабалар рухын җуймаска, өйрәнергә, саклап калырга, киләчәк буыннарга җиткерергә бурычлыбыз.

Икенче көнне Габдулла хәзрәт белем алган Гали авылына барып, анда эшләп килүче мәдрәсә белән таныштык. Бу якларга бер килгәч, күңелдә калмасын дип, Казанга кайту юлындагы башка татар авылларына, аерым алганда Байтуган, Яңа Усман, Иске Усман, шулай ук Оренбург өлкәсенә керә торган Тургай һәм Бакай авылларына да кереп чыктык. Ул авылларның имамнары белән танышып, мәчетләрендә булдык. Бу авылларда да борынгы кулъязма истәлекләрне бик теләп тапшырдылар.

Монда Оренбург өлкәсенең Северный районына керә торган Бакай һәм Тургай авыллары турында да язуыма газета укучылар гаҗәпләнмәсләр дип уйлыйм. Чөнки, беренчедән, безне мәкерле сәясәт балтасы бүлгәләп, төрле административ өлкә-республикаларга аерса да, без бер диндәге, бай тарихы уртак булган, бер үк татар милләте балалары. Безнең асылыбыз, язмышларыбыз, мәдәниятебез, фикеребез, үткәнебез һәм киләчәгебезне, ният һәм максатларыбызны беркем дә административ һәм бүтән чикләр белән генә түгел, ут һәм кылыч белән дә бүлгәли алмады. Инша Аллаһ, алмаслар да! Икенчедән, Оренбург өлкәсенең бу авыллары (ә элек алар Самара өлкәсенә кергәннәр дип ишеттек) Камышлы районының татар авыллары белән электән тыгыз элемтәдә аралашып, ярдәмләшеп, йөрешеп, бергә көн күрәләр.

Тупланган табышларга аерым тукталганчы, сәфәрдән алган тәэсирләребез белән дә уртаклашасы килә. Тәэсирләр, әлбәттә, куанычлы. Бу якларда беренче мәртәбә булганлыктан, безгә мондагы табигать бик ошады. Тагын да шушы матур табигать эчендә электән үк авыллар корып, көр һәм таза тормышта яшәп ятучы үз халкыбыз булуы куандырды. Безгә монда яшәүче милләттәшләребезнең аеруча бердәмлекләре, диндарлыклары, читтән килүчеләргә җылы мөнәсәбәтләре бик сөендерде. Кайбер авылларда Татарстан

телевидениесе тапшыруларын карый алуларын белгәч тагын да шатландык. Сәфәребезнең сәбәпчесе булган хатның авторы Габдулла Кәримнең без уйлаганнан күпкә яшьрәк һәм бик ихлас күңелле, милли рухлы татар егете икәнлегенә шатланып бетә алмадык. Яшьлегенә (фәкать 20 яшьтә булуына) карамастан, без булган барлык авылларда да аның абруе зур, аны беләләр һәм хөрмәт итәләр. Бу якларда дингә ихтирам көчле, һәр авылда мәчет бар. Борынгыдан эшләп килә торган мәчетләр барлыгына ничек сөенмисең?! Гали авылының бер мәчете 1909 нчы елда төзелгән, ә Бакай авылыныкы хәтта 1887 елгы икән. Болар үзләре үк татар архитектурасы истәлекләре бит. Өстәвенә, сәфәребезнең дә бик уңышлы булып, капчык-капчык борынгы китаплар туплый алуыбыз күңелләребезгә җан рәхәтләре бирде.

Кәефне җибәрә торган күңелсез хәбәрләр дә ишетергә туры килде. Мәсәлән, 1969 елда Иске Ярмәк авылының әүвәлге мәчете янгын чыгып харап булган. Ә анда нәкъ без кызыксына торган, исраф булып бетмәсеннәр иде дип, милләтебезнең киләчәге файдасына саклап калу өчен бөртекләп туплый торган борынгы кулъязмалар бихисап булган. Мәчет тә, китаплар да янып мәңгегә юкка чыккан. Ә икенче бер авыл мәчетендә тупланган шундый борынгы язмаларны, имеш, танып укый белүче юклыктан күптән түгел генә яндырганнар дип ишеттек. Бу хәбәр дөрес булса, бик кызганыч. Үз тарихыбызны яндырабыз бит, җәмәгать! Дөрес, борынгы кулъязманы танып уку өчен гарәп язуын белү генә җитми, махсус хәзерлек, тәҗрибә дә таләп ителә. Һәрхәлдә, Татарстан башкаласы Казан шәһәрендә бу эш белән шөгыльләнүче фәнни оешмалар бар бит. Дәһшәтләр аша исән калып, безнең көннәргә кадәр килеп ирешкән рухи мирасыбызны югалтмаска, саклап калырга иде. Моңа һәркем җитди карарга бурычлы. Чөнки тарихи ядкәрләр балаларыбыз, оныкларыбыз, милләтебезнең бәхетле, ирекле яшәеше өчен кирәк. Бәрәңге ашап кына тулы бәхет-сәгадәткә ирешеп булмый. Тәгам тән үстерә, китап күңел үстерә, дигәннәр борынгылар.

Табышларның сыйфат җәһәтенә күз салыйк. Борынгы кулъязма истәлекләр туплау буенча оештырылган археографик сәфәребез нәтиҗәсендә барлыгы 160 кулъязма берәмлек тупланды. Бу, әлбәттә, бик зур фәнни табыш. Шунысын искәртик, аерым бер зур китап

яки бер кульязма бит тә мөстәкыйль кульязма берәмлек дип санала. 160 берәмлекнең туксан өче Камышлы мәчетеннән, утыз алтысы Ярмәк, егерме дүртесе Бакай, җидесе Яңа Усман авылларыннан.

Тулаем алганда һәр кульязма истәлек аерым игътибарга лаек. Тик шулай да, аеруча кызыклыларыниләр соң?

Иң кызыклы фәнни табыш – Камышлыда алынган XIX гасыр башында Сибгатулла Фәхретдин улы тарафыннан күчерелгән кульязма җыентык. Бу җыентыкта моңарчы фәндә берничә генә күчермәсе мәгълүм булган, XV–XVI гасырларда иҗат ителгән «Түләк һәм Сусылу» дастанының яңа күчермәсе теркәлгән. Татар әдәбияты тарихы өчен бу дастанның яңа кульязма күчермәсе табылу бик әһәмиятле.

Камышлы мәчетеннән алынган язмалар арасында күренекле татар философы Габденнасыйр Курсавыйның гарәп телендәге «Шәрхе гакаиден- Нәсәфи» әсәренең ике күчермәсе бар иде. Дини эчтәлектәге һәм гарәп теле грамматикасы буенча кайбер кульязма китаплар 1880 нче елларда Камышлыда Гыйззәтулла Һидәятулла улы мәдрәсәсендә күчерелгәннәр.

Китап-язмалар, нигездә, XIX гасыр ядкәрләре. Иң борынгысы 1791 елда Норма (хәзерге Татарстан Җөмһүриятенең Балтач районында) мәдрәсәсендә күчереп язылган «Исагуҗи» китабы. Шулай ук шигъри әсәрләр, Габделҗәббар Кандалый шигырьләре теркәлгән кульязмалар, сабак дәфтәрләре, хикәятләр һ.б. бар.

Аеруча кызыклы табышларга һәр авылда диярлек юлыктык. Иске Ярмәк авылыннан шундый табыш – мәшһүр татар тарихчысы, дин галиме, заманында Диния нәзарәтендә казый һәм мөфтилек вазифаларын башкарган Ризаэтдин Фәхретдиннең шәкерт вакытында үз кулы белән язган җыентыгы булды. Бу җыентык 1874–1881 елларда Габделфәттах Габделкаюм улы әл-Шәлчәли мәдрәсәсендә язылган. Анда Ризаэтдин Фәхретдин кулы белән ишаннар шәҗәрәсе һәм гарәп телендәге шигъри әсәрләр теркәлгән. Бу кульязма җыентыкка шул ук мәдрәсәдә белем алган Ярмәк авылының Мөхәммәтгәрәй Әһлиулла улы тарафыннан дин сабаклары буенча язмалар да теркәлгән. Әлеге җыентыкның Иске Ярмәк авылына барып чыгып, анда сакланып калуына нәкь менә шул Мөхәммәтгәрәй Әһлиулла улы сәбәпче дип уйларга кирәк. Иске Ярмәктә XVII гасыр-

да матур итеп язылган, кечкенә форматтагы Коръәни Кәримнең аерым бер өлеше дә сакланып калган. 1867 елда Казанда Шиһабетдин Мәрҗани мәдрәсәсендә күчерелгән гарәп телендәге дини эчтәлекле китап та бик оста кул белән матур итеп язылган. Җарәхмәт Габделкадыйр улы әл-Ярмәки тарафыннан 1876 елда язылган кечкенә бер җыентыкта исә танылган татар шагыйрьләре Габделҗәббар Кандалый һәм Һибәтулла Каргалый шигырьләре тупланган.

Яңа Усман авылы мәчетеннән алынган кульязмалар арасында дәфтәр рәвешендәге берсе аеруча игътибарны җәлеп итә. Тулы бер дәфтәрдә хат язылган. Иркутск шәһәреннән Балыклы авылындагы туганнарына Шәйхетдин исемле кеше юллаган хат ул. Хаттан укып хатыны Бибимәсрүрә, уллары Гатаэтдин икәнен дә беләбез. Үзендә төгәл датасы куелмаса да, хатның 1904 елда язылганлыгын билгеләргә мөмкин. Чөнки, хатта япон сугышы турында да сүзләр бар. Эчтәлегеннән аңлашылганча, әле ул сугышның башы гына булса кирәк. Хат авторының ни сәбәпледер сөрелүче икәнлеге дә аңлашыла. Хатында исә туган якка кайтырга рөхсәт алуын һәм туган җире белән күрешү минутларын зарыгып көтүен бәйнә-бәйнә язган ул. Хат туган төбәккә мәхәббәт хисләре белән сугарылган, урыны-урыны белән шигырьләп та язылган.

Бакай авылы кульязмаларының иң борынгысы 1792 елда Бәшәр Габдеррәшид угылы тарафыннан язылган. Ул мәшһүр төрки шагыйрь Аллаһыяр Суфыйның бер әсәрен күчергән. Бу кульязма, борынгылыгы белән беррәттән, күчерелгән урыны белән дә шактый кызыклы. Китапның ахырында Кронштадт кальгасендә күчерелүе хакында язып куелган. Шушы ук авылдан сирәк очрый торган «Аксак Тимер дастаны»ның XIX йөз башына караган күчермәсе, Габдеррәхим Утыз Имәни һ.б. татар шагыйрьләренең әсәрләре язылган җыентыклар бар иде.

Әлбәттә, бер мәкаләдә генә барлык табышларны да тасвирлап үтү мөмкин хәл түгел. Хәзергә иң әһәмиятлесе – фән өчен кыйммәтле тарихи язмаларның ышанычлы саклау урынына алдырылуы. Киләчәктә аларны галимнәр тәфсилләп өйрәнәчәк дип ышанырга кирәк. Үзем дә, инша Аллаһ, кайбер әһәмиятле табышларны өйрәнеп, алар турында Татарстан матбугатына аерым мәкаләләр хәзерләрмен дип ниятләп торам.

Язмамның ахырында Иске Ярмәк имам-хатыйбы Габдулла Кәримгә, шулай ук Камышлы мәчете идарәсенә, Яңа Усман авылы мулласы Миңнегали абзыйга, Бакай авылы имамы Хәлиулла хәзрәткә шәхсән үземнән һәм Татарстан Милли китапханәсе җитәкчелеге исеменнән чиксез рәхмәтләр белдерәсе килә.

Без бу юлы мәчетләрдә сакланган кулъязма истәлекләр белән генә таныштык. Әле халыкта сакланганнары да бик күп бит. Авыл имамнарына андыйларын да барлап куярга үтендек. Шулай ук кайбер кызыклы ядкәрләрнең шәхси кулларда саклануларын белеп тә, күрә алмыйча кайтып китәргә туры килде. Аллаһ боерса, бу төбәккә көз айларында тагын бер мәртәбә барып чыгарга ниятләп торабыз. Юлларыбыз уңышлы булып, тагын да әһәмиятле ачышларга юлыгырга насыйп итсен дигән теләктә калабыз.

*1996 ел, 29 апрель.*

## КИТАПЛЫ ХАЛЫК – ТАРИХЛЫ ХАЛЫК

Җөмһүриятебезнең Үзәк Китап йорты – Татарстан Милли китапханәсенең борынгы китаплар фонды көннән-көн байый бара. Матбугатта укучыларны яңа табышлар, кызыклы китаплар белән даими таныштырып киләбез. Газетада мондый язма-хәбәрләр биреп бару изге максатлардан эшләнә. Татарстан Милли китапханәсе киң җәмәгатьчелеккә хезмәт иткәнлектән, халык анда тупланган китап хәзинәсеннән хәбәрдар булырга тиеш.

Борынгы китапларның саклануы, һичшиксез, аерым шәхесләрнең игътибарына, фидакярлегенә бәйле. Ә татар китабының сикәлтәле тарих борылышларында күпме җәбер кичергәнлеген исәпкә алганда, аерым шәхесләрнең роле тагын да зуррак булуы көн кебек ачык. Бу язмабызда укучыларны соңгы сәфәрләребездән берсенең нәтиҗәләре белән таныштырабыз.

Удмуртия башкаласы Ижауда Ниязи ага һәм аның җәмәгате Бибигабидә апаны белмәгән татар юктыр. Өлкән яшьтә булуларына карамастан, шәһәрдә үткәрелә торган һәрбер дини һәм милли чараларда алар алгы сафта. Алар моннан биш ел ярым элек Удмуртия Иҗтимагый үзәген оештыруда да башлап йөрүчеләрдән. 1989 ел-

дан, башта дүрт ел Тимерьюлчылар Мәдәният йортында, аннан Ижау мәчете каршында урта һәм өлкән яшьтәгеләр өчен гарәп язуын һәм дин нигезләрен өйрәтү буенча дәресләр алып баралар, икесе дә киң күңелле, төгәл һәм сабыр, диянәтле, гыйлемле һәм тиешле микъдарда кырыс табигатьле, ачык йөзле, тапкыр сүзлеләр. Кыскасы, менә дигән, соклангыч, үрнәк татар гаиләсе.

Ниязи ага Насретдинов белән без 1991 елның язында Ижау каласында Габдулла Тукайга багышлап уздырылган әдәби кичәдә танышкан идек. Ниязи агай да, Бибигабидә апа да тумышлары белән Башкортстанның Яңавыл районыннан. Икесе дә, укымышлы хаҗи нәселләреннән. Бибигабидә апа 1921 елда туган, математика укытучысы булып эшләгән. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтик. Узган елгы археографик экспедиция вакытында Бибигабидә апаның Яңавылда яшәүче энесе – Халит абыйдан да күп кенә кызыклы китаплар алган идек. Ә Ниязи ага 1916 елгы, 1930 нчы елларда Казанда алдынгы трамвай йөртүче, электромеханик буларак танылган.

Ул 1938 елда трамвай идарәсенә килгән чакыру буенча, тәҗрибәле белгеч буларак, Ижау шәһәренә җибәрелгән. Чөнки ул вакытта Ижауда булган барлык өч трамвай да сафтан чыккан була. Өч тәүлек эчендә барлык трамвайлар да төзекләндерелеп юлга чыгарыла. Шуннан соң Ниязи ага хәрби хезмәткә алына, япон сугышында катнаша, сугыштан соң заводта механик-элемтәче булып эшли.

Мондый картлар белән гәпләшеп утыру үзе бер гомер, үзе бер тарих дәресе. Дәһшәтле утызынчы елларда гарәп язуындагы китапларны юк итү, укымышлы затларны, муллаларны жәберләү кебек хәлләрне өлкән буыннан гына сорашып белергә мөмкин. Ниязи ага сөйләгән аерым авыл мисалы гына да иситкеч бер фаҗига. Ә шундый кара вакыйгаларның һәр татар авылында, татарлар яшәгән һәр шәһәр бистәсендә булганлыгын исәпләсәң, һәлакәтнең никадәр коточкыч, мәгънәсез һәм рәхимсезлегеннән чәчләр үрә торырлык.

1917 елга кадәр чыккан абруйлы «Шура» журналында шигырьләре һәм мәкаләләре басылган Мөхәммәтсәлах Ждановның бай китапханәсе булган. Китапларга каршы көрәш мәхшәре башлангач, Мөхәммәтсәлах хәзрәт йөзләгән борынгы кульязма китапларын Җәнәй авылында коега салып күмдергән, ә басма китапларын ике

ат чанасына төяп Яңавылга алып китеп яндырганнар. М.Жданов-ның бай китапханәсеннән кечкенә бер өлеше Ниязи агада сакланып калган. Шулай ук анда Ижауда озак еллар имам булып торган Галимҗан Мөхәммәтҗан улының да китаплары сакланган. Шул рәвешчә, Ниязи агада бик бай китапханә хасил булган. Заманында гарәп теле белгече Зәйнәп Максудова да Ниязи агайдан аеруча кызыклы кульязма китаплар алып киткән. 1994 елда ул Татарстан Милли китапханәсенә дә җиде кульязма һәм 29 борынгы басма китап бүләк итеп биргән иде. Быел май аенда янәдән күп кенә китаплар алырга насыйп булды. Төгәлрәге 62 берәмлек кульязма һәм 47 иске басма китап, календарьлар, «Шура», «Сөембикә», «Икътисад»... барлыгы сигез исемдәге журнал һәм газеталар. Боларның бер өлеше югарыда исеме аталган Мөхәммәтсәлах Жданов китапханәсеннән. Арадагы кайбер китапларда аның имза-автографлары да бар. Басма китаплар арасында күренекле шәхесләрдән Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин, Муса Бигиев, Газиз Гобәйдуллин, шулай ук Һади Атласиның «Казан ханлыгы», Морад Рәмзинең «Тәлфикыль-әхбар…» әсәрләре бар. Кульязмаларның күпчелеге башта Сарапул, аннан Ижауда имамлык вазифасын башкарган Галимҗан хәзрәткә нисбәтле. Аның бер җыентыгында 1943 елда үзендә булган иске басма китапларының исемлеге теркәлгән. Барлыгы 744 (!) данә китап һәм аерым журналлар. Шәригать китаплары, тәфсирләр, әдәби, гыйльми әсәрләр..., Мәрҗани, Насыйри, Тукай, Исхакый, Ризаэтдин Фәхретдин... тагын әллә кемнәрнең әллә ничә төрле китаплары... Аңа бу кадәр китапны утызынчы еллар давылында саклап калу, әлбәттә, җиңел булмагандыр.

Ижауга барган саен борынгы китаплар, аларны саклаучылар белән күбрәк танышырга туры килә. Китаплардан гайре башка кызыклы шәхесләр дә очрый. Андыйларның тормышлары, кылган гамәлләре үзе бер китап. 90 яшен тутырып килүенә карамастан, уникаль хәтерле, Ижау татарларының тарихын энәсеннән-җебенәчә өйрәнгән олуг шәхес Мөхәммәтгата Котдусов кебек затлар үзләре бер хикмәт иясе. Аның шәхси архивында Ижау татарларының үткәне буенча искиткеч бай мәгълүмат тупланган. Яшь әдип һәм галимнәребез Мөхәммәтгата аганың үзе турында бер матур әсәр

иҗат итәрләр һәм ул туплаган материаллар нигезендә Ижау татарлары тарихын да язарлар дип ышанасы килә.

Ижау дигәннән, гомумән, бу шәһәрдә яшәүче татарлар милләтебезнең кызыклы бер төркемен тәшкил итә, минемчә. Андагы татарларның күпчелеге электән үк сәүдә өлкәсендә эшлиләр. Кайсы гына кибеткә керсәң дә, һәммә җирдә татарлар, хәтта Үзәк базарда да милләттәшләребез шау-гөр килеп сәүдә итәләр. Бөтен нәсел-нәсәпләре белән шул даирәдә эшләүчеләрне күп очратырга туры килде. Башка төбәкләр белән чагыштырганда, Ижауда татар милли-мәдәни чаралары да бик оешкан төстә, бердәмрәк һәм күңеллерәк итеп үткәрелә. Андагы милләттәшләребез ике-өч кешелек фиркаләр оештырып үзара талашу, бер-беренә пычрак атып яту чиреннән азат. Киресенчә, бердәмлектә көч икәнен тирәнтен аңлаган хәлдә, уртак максатка тугрылыклы хезмәт итәләр. Монда Удмуртия Татар иҗтимагый үзәге җитәкчесе Мәсгуть ага Гаратуевның да роле зур булуын таныырга кирәк.

Күпме афәт-дәһшәтләр, җәбер-золымнар кичергән татар халкында олы җанлы шәхесләр дә, борынгы язма истәлекләр дә бар әле, күп әле. Фәкать шуларны барлыйсы, күз карасыдай саклыйсы һәм тиешенчә кадерлисе иде.

*1996 ел, 30 июнь.*

## ЯЗМЫШ ЯРАСЫ

Борынгы язма мирасыбызны барлау һәм туплау максаты белән миңа Татарстан авылларыннан тыш, милләттәшләребез яши торган күп кенә күрше республикаларда, ерак һәм якындагы өлкәләрдә дә булырга туры килә.

Археограф, кулыннан меңләгән борынгы китаплар узган кебек, шул кадәр үк язмышлар белән дә очраша. Хәтта, ирексездән, күпләрнең күңел яраларын кузгатуга да сәбәпче була. Чөнки татар китабының тарихы, халкыбыз язмышыдай, хәсрәт дәрьясын хәтерләтә. Яраларны кузгату дигәннән, бер хатирә әле дә күңелне тырнап тора.

Бервакыт Актаныш районының Чуракай авылында 20 елдан артык муллалык вазыйфасын үтәп килүче Әмирҗан бабай Хуҗиәхмәтев белән очрашкан идем. Борынгы китаплар турында сүз чыккач, 89 яшьлек карт: «Һи, яшь чакта үзебез җыеп йөрдек без аларны», – дип моңсу гына елмаеп куйды. Мин аптырашта калдым.

Берникадәр тын торгач, ул авырлык белән генә түбәндәгеләрне сөйләде. 1920 нче еллар ахыры. Комсомолларның котырынган чагы. Дингә каршы рәхимсез көрәш бара, гарәп язуындагы барлык китапларны җыялар, юк итәләр. Динне эттән алып эткә салалар, дөнья яратылышы, җәмгыять, яшәеш турында бөтенләй башкача сөйлиләр. Ә Әмирҗан абзый, мулла әтисе өйрәткәнчә, шәригать сүзләрен тәкрарлый. Шуны ошатмыйча, комсомол активы тота да, «Моны кызык итик әле» дип, аңа гарәп язулы китапларны җыю буенча авылда җаваплы башкаручы вазыйфасын йөкли.

Бабайның сөйләвенә караганда, район үзәгеннән килгән кораллы ике милиционер белән 1928 елның кышында атналар буе йөкйөк китап җыялар. Бикләнеп, китапларны бирергә теләмәүчеләрне йә куркытып ачтыралар, йә ишекләрен каерып-ватып керәләр. «Җыелган китапларны ни эшләттеләр соң?» – дип соравыма карт ачык кына җавап бирмәде. «Кәнсәләргә җыйдырттылар шунда. Ни эшләткәннәрдер, белмим», – дип, сүзен тәмамларга ашыкты.

Аның белгәнлеген аңласам да, болай да гариплэндерелгән язмышының яраларын тирәнәйтмәс өчен, артык йөдәтергә җөрьәт итмәдем.

*1996 ел, декабрь.*

## ТАРИХИ ЯЗМАЛАР

Элекке язмаларыбызда Кукмара районы авылларында яңа табылган борынгы язма истәлекләр белән укучыларны газета сәхифәләре аша таныштырып барырга вәгъдә биргән идек. «Вәгъдә – иман» дигән борынгылар.

Борынгы кульъязмалар туплау максаты белән без, Татарстан Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәрләре, узган ел җәй башында янәдән Кукмара районы авылларында булдык.

Сәфәребез шактый уңышлы үтте. Күп кенә авылларда йөреп, барлыгы 62 кулъязма истәлек һәм күп кенә иске басма китаплар тупладык. Бу сәфәребездә дә ышанычлы танышларыбыз (без алар белән 1995 елгы археографик сәфәрдә танышкан идек), Төркәш авылыннан Үзбәк абый Нуриев, Хаҗиб әфәнде Гыйльманов, Рәфыйк әфәнде Заһидуллиннар зур ярдәм күрсәтте.

1996 елгы археографик сәфәрдә без Нырты совхозында, Әсән-Елга, Өлге, Шепшеңәр, Кукчә, Түбән Арбаш, Ятмас Дусай авылларында булдык. Нәтиҗәдә, кызыклы гына кулъязмалар тупланды һәм басма китаплар җыйналды.

Аеруча игътибарга лаек табышларның кайберләренә тукталыйк. Әсән-Елга авылында Мөхәммәтзакирова Таифә ападан алган аерым-аерым шыксыз гына язулы дүрт кәгазь битендә бик тә мөһим мәгълүматлар теркәлгән. Бу битләр Әсән-Елга авылының тарихы, шәҗәрәсеннән калганнар. Башка битләре сакланмавы бик тә кызганыч, билгеле. Тик шулай да, бу битләрдән, саран булса да, кыйммәтле мәгълүмат алырга мөмкин. Аларда, нигездә, нәсел-ыру язмалары теркәлгән. Ә бер биттә исә авылның аталышына, тарихына бәйле мондый юллар бар: «...Габделкаюм, аның атасы Шаһимәрдан, аның атасы Мөхәммәди, аның атасы Гайнан, аның атасы Йосыф, аның атасы Гобәйдулла, аның атасы Госман, аның атасы Биктимер, аның атасы Бикбау, аның атасы Әмачи. Әмачинең чын исеме Әхмәтҗан булган. Әхмәтҗан бабайлары-аталары Изел буеннан монда – яңа җиргә күчеп килгәннәр. Әхмәтҗанның аталары Казан тирәсендә Әйшә дигән авылдан күчеп Пүләнкәдән түбән Изел буенда утырган булганнар, урыс авылына. Урыслар күбәйгәч дүрт баба шушында килеп утырганнар. Бу урман булган. Болар утырган җир чишмә буйлары, болыны да янган җир булган. Шуңар Көек дип исем биргәннәр. Әсән-Елга диюләре югары чишмә башында Әсән исемле чирмеш утырган булган. Бу чирмеш тау астына күчкән болар килгәнче. Шуның берлән Әсән-Елга диеп язылып йөридер кенәгәләрдә».

Әсән-Елга авылында яшәүче Җәлалиев Камил абыйлар да күп кенә кулъязма материаллар тапшырдылар. Аларда XIX гасыр башында язылган астрономия гыйлеме буенча аерым битләр, шулай ук Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» әсәре дә сак-

ланган. Камил абыйлардан алынган иң борынгы кулъязма истәлек 1797 елга карый. Шулай ук Әсән-Елгадан Әхмәтталипов Нәҗметдин абыйлар да кызыклы китаплар белән куандырды.

Шепшеңәр авылының Фәрзәнә апа Фәизова биргән язма материаллар арасында Габделҗәббар Кандалый шигырьләре теркәлгән дәфтәр аеруча игътибарга лаек. Кандалый шигырьләре язылган башка кулъязма җыентыкларны Ятмас Дусай авылында Кәримова Мәликә апа, Нырты совхозыннан Рәфыйк Заһидуллиннар да биргән иде. Фәрзәнә ападан алынган иң иске кулъязмада 1795 ел дигән дата теркәлгән. Моннан башка да XVIII йөз ахырында язылган нөсхәләр бар иде. Шул ук авылдан Һәдия апа Дәүләтшинадан күп кулъязмалар алынды. Иң кызыклыларыннан бәетләр тупланган дәфтәрне әйтеп үтәргә мөмкин. Ул бәетләр арасында татар солдатлары легендар кавказлы Шамилгә багышлап чыгарган сирәк очрый торган «Шамил бәете» тексты да урын алган.

Түбән Арбаш авылында Рәисә апа Бигашевада XVIII гасырның икенче яртысында язылган татарча дини риваятьләр һәм Коръән тәфсире дә борынгылыклары белән игътибарны җәлеп итәләр.

Өлге авылының Ибраһимов Фәрһад абыйлардан күп кулъязмалар алдык.

Әлбәттә, һәр табыш, һәр кулъязманың лаеклы үз кыйммәте бар. Аларның һәрберсенә киңәеп, тәфсилләп туктау мөмкин түгел. Борынгы язма истәлекләребезне, халкыбызның изге мирасын кадерләп саклаган Кукмара төбәгендә яшәүче милләттәшләребезгә олуг рәхмәтебезне җиткерәбез.

Аллаһ боерса, киләчәктә дә Кукмара якларында борынгы язмалар эзләп еш булырга туры килер. Әле зиратларда безнең тарафтан күрелмәгән, тикшерелмәгән борынгы кабер ташлары да бихисап. Өлге һәм Әсән-Елга авыллары зиратларында да борынгы ташлар күргән идек. Әмма иркенләп, якыннан танышырга форсат булмады. Кукмара ягы, әлхәмделиллаһи, бай тарихлы төбәк. Насыйп булса, танышып өйрәнәсе, тикшерәсе истәлекләр күп әле.

*1996 ел, декабрь.*

## УН ЕЛЛЫК АРХЕОГРАФИК ХЕЗМӘТ

Моннан ун ел элек, 1992 елның гыйнвар аенда Татарстан Милли китапханәсендә яңа бүлек – Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге оештырылган иде. Әлбәттә, ул буш урында пәйда булмады, аңарчы китапханәдә эшләп килгән Сирәк китаплар секторы нигезендә үстерелде. Яңа бүлекнең оешуына китапханәгә борынгы төрки-татар һәм Шәрык телләрендәге кулъязма истәлекләрнең туплана башлавы этәргеч булды. Шулай ук әлеге бүлекнең хезмәт даирәсе дә киңәйде. 1917 елга кадәр нәшер ителгән татар басма китабының академик Әбрар ага Кәримуллин җитәкчелегендә тулы каталогын төзү буенча фундаменталь хезмәт тә шушы бүлек хезмәткәрләре тарафыннан планлы рәвештә башланды.

Хәзерге вакытта бүлек ике мөстәкыйль сектордан – «Татар һәм Шәрык әдәбияты», «Рус һәм Көнбатыш әдәбияты» секторларыннан гыйбарәт. Бу мәкаләдә бүлекнең ун ел дәвамындагы киң эшчәнлеген яктыртуны максат итеп куймыйча, бары тик аның аерым бер тармагы – кулъязмачылык өлкәсенә гомуми күзәтү ясарга омтылдык.

Китапханәдә оештырылган яңа бүлекнең исемендә үк «Кулъязмалар...» төшенчәсе бар. Бу гыйбарә, һичшиксез, җисемнең исемгә туры килүен таләп итә торган зур җаваплылык йөкли. Әле бүлек оешып кына килгән бер мәлдә төрле гыйльми даирәләрдә Татарстан Милли китапханәсенә кулъязма истәлекләр туплау эшенә карата икеләнүчән һәм шикчел, сагаюлы фикерләр йөргәләсә дә, китапханә җитәкчелеге – ул вакыттагы директоры Разил Вәлиев – тәвәккәллек күрсәтте.

Әлеге тәвәккәллек үзен акладымы? Акласа, ни дәрәҗәдә? Республикабызның үзәк китапханәсендәге яңа бүлек тернәкләнеп киттеме? Аз булса да, эш күрсәтә алдымы? Язмабызда әлеге сорауларга киңрәк җавап бирергә тырышырбыз.

1990-1991 елларда китапханәгә берничә дистә борынгы кулъязма алынган иде һәм аларның саны көннән-көн ишәя барды. Ә 1992 елдан, яңа бүлек оештырылу белән, халкыбызның кулъязма мирасын туплау һәм өйрәнү эше Татарстан Милли китапханәсендә төп максатларның берсе итеп куелды. Кулъязма истәлекләрне туплау

өчен китапханә идарәсе матди җәһәтне, ә бүлек хезмәткәрләре көчләрен кызганмадылар.

Кулъязма истәлекләрне туплау максатында 1992 елның җәеннән Казан дәүләт университеты белән берләштерелгән археографик экспедицияләр оештырыла башлады. Экспедиция ел саен дәвам итеп, узган җәйдә унынчы эш нәүбәтен башкарып кайтты. Ун ел эчендә экспедиция Түбән Новгород, Пенза, Самара, Оренбург, Пермь өлкәләрендә һәм Башкортстанның милләттәшләребез яши торган төбәкләрендә эшләде. Моннан тыш, бүлек тарафыннан һәр елда ике-өч мәртәбә республикабыз районнарына, шулай ук күрше республика һәм өлкәләргә дә берәр атналык археографик сәфәрләр оештырыла. Шул рәвешчә, күп кенә кала һәм авылларда сакланып калган кулъязма истәлекләр Татарстан Милли китапханәсенә алып кайтылды. Казан шәһәренең үзендә дә археографик эзләнүләр уңышлы алып барыла. Башкалабыздагы күп кенә мәчет идарәләре, мөрәҗәгатьләребезгә җавап итеп, үзләрендә тупланган, фәнни әһәмияткә ия борынгы язмаларны китапханәбезгә тапшырды. Казандагы «Ноталар» китап кибетенең букинист бүлегеннән дә гарәп язуындагы борынгы китаплар даими төстә китапханәгә алына. Матбугат, радио һәм телевидение чаралары аша халыкка мөрәҗәгать итүләр дә уңай нәтиҗә бирде. Күп кенә милләттәшләребез почта аша һәм үзләре китереп кызыклы гына материаллар тапшырдылар һәм бу хәзер дә дәвам итә килә.

Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәрләренең ун еллык археографик эзләнүләре, кулъязма истәлекләрне сатып һәм бүләк буларак алу, алмашу кебек чаралар нәтиҗәсендә Татарстан Милли китапханәсе фондларына хәзерге вакытка барлыгы 3070 берәмлек кулъязма тупланды. Елларга бүленештә караганда, 1992 елда – 251, 1993 елда – 366, 1994 елда – 98, 1995 елда – 326, 1996 елда – 973, 1998 елда – 194, 1999 елда – 195, 2000 елда – 191 һәм 2001 елда – 268 берәмлек кулъязма истәлек тупланган. Шулардан 1116 төрки-татар кулъязмалары, гарәп телендәге 315, фарсы телендәге 62 (барысы 1493) берәмлек кулъязма эшкәртелеп, махсус теркәлде. Ә калган 1577 кулъязма истәлек әлегә эшкәртү һәм өйрәнү, теркәү халәтендә. Ун ел өчен бу сан аз түгел.

Сан ягы шулай, ә җыелган кулъязма байлыкның сыйфат ягы нинди соң? Мәсьәләнең ул ягы ничегрәк тора?

Гомумән, һәр кулъязма китап һәм дәфтәр үзенчәлекле, кызыклы һәм кабатланмас хасиятләргә ия. Әйтик, Кол Гали иҗат иткән мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасының кулъязма нөсхәләре археограф галимнәр тарафыннан әледән-әле табылып тора. Татарстан Милли китапханәсендә милли әдәбиятыбызның чишмә башы исәпләнгән «Кыйссаи Йосыф» әсәренең хәзерге вакытта егерме сигез нөсхә кулъязма күчермәсе бар. Бу, әлбәттә, аз түгел. Шулардан өчесендә әсәрнең текстлары тулаем сакланган, алтысының берничә битләре генә җуелган, бишесе 10–30 кәгазьдән, калганнары берничә яки берәр битле фрагментлардан гыйбарәт. Ике фрагментар кулъязма XVII йөз ахырына, берсе исә XVIII гасыр башына, өчесе XVIII йөзнең икенче яртысына, калганнары XIX гасырның башы яисә беренче яртысына нисбәтлеләр. XVII йөз ахырында күчерелгәннәре башкаларыннан палеографик үзенчәлекләре белән аерылып тора. Алар 1993 елда Казан шәһәренең «Болгар» мәчетеннән алынган иде.

Китапханәбездә саклана торган «Кыйссаи Йосыф» күчермәләренең табылу географиясе дә шактый киң. Шулардан тугызы Казан шәһәрендә, янә тугызы археографик экспедицияләр вакытында Пенза, Пермь өлкәләреннән һәм Башкортстаннан; Татарстанның Апас районыннан – бер, Арча районыннан – ике, Әгерҗе районыннан – ике, Теләче районыннан – бер, Ютазы районыннан – бер, Самара өлкәсенең Динис авылыннан – бер, Уфадан – бер, Тобольск каласыннан – бер кулъязма табылган.

Шагыйрь Мөхәммәт Садрый «Кыйссаи Йосыф» әсәренең XIX йөз башы, шагыйрә һәм җәмәгать эшлеклесе Заһидә Бурнашеваның туганнары 1841 елгы күчермәләрен китапханәгә бүләк иткәннәр иде. Шулай ук поэманың 1852 елгы басмасының җуелган битләрен XIX йөз татар шагыйре Гали Чокрый үз кулы белән язып тулыландырган нөсхә дә бар.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы халык арасында шул дәрәҗәдә популярлашкан булган ки, төрле чорларда бу әсәрнең шигъри калыбы һәм үлчәмендә күп санлы бәетләр һәм җырлар да иҗат ителгән. Андыйларның кайберләре безнең китапханәдә дә саклана. Ни хикмәттер, күзәтүләребез буенча, аларның күпчелеге

пародия, сатира өслүбендә язылганнар. Мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф» сюжетына пародия рәвешендә иҗат ителгән бер әсәрнең XIX йөз башы кулъязма фрагментында мондый юллар бар:

«Йосыф әйтер: «Ходавәндә, ходавәндә,
Сәнең хөкемең кәлтерде бәне монда».
Зөләйха әйтер: «Не куручи, будет пулна!
За шту кручить напрасна?» – диер имди*».

Шул ук әсәр үлчәмендәге, XIX гасыр уртасына караган янә бер шигъри әсәр «Миһман килсә, куеңны багламагыл...» дип башлана. [...]

«Кыйссаи Авык» әсәренең дә шигъри калыбы «Кыйссаи Йосыф»ныкыча. Габделҗәббар Кандалыйның да бу шигъри калыпта еш кына үз шигырьләрен иҗат иткәнлеге мәгълүм. Китапханәдә андыйлар да бар. Бөек әсәрнең шигъри үлчәменә ияреп соңрак чорда Шакир Мөхәммәдев, Мәҗит Гафури, Габдулла Тукай һ.б. иҗат иткәннәр.

XIX йөз ахыры һәм XX йөз башында «Кыйссаи Йосыф» үлчәмендә иҗат ителгән төрле шигырь-бәетләр бездә тупланган язмалар арасында дистәдән артык төрдә. Мәсәлән, «Күркә-әтәч бәете», «Ташаяк ярминкәсе бәете», «Ранный солдат бәете» Йосыф кыйссасы калыбында язылганнар. Болар бар да бөек әсәрнең халык арасындагы шөһрәтен күрсәтә торган дәлилләрдән.

Болгар дәвере галиме Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәреннән күчерелеп аерым өзекләр теркәлгән XVIII йөз ахыры (Казаннан табылды) һәм XIX йөз башы (Теләче районының Иске Җөри авылыннан табылды) кулъязмалары да кызыклы. Соңгысында «остазым Габдессәлам бине Уразайдан ишеткән сүзләрем» дип язылган юллар да бар. Монда XVIII гасырда яшәп иҗат иткән татар шагыйре Габдессәлам күздә тотыла.

Татарстан Милли китапханәсендә төрки-татар әдәбияты тарихында мәгълүм башка шигъри кыйссаларның кулъязма нөсхәләре дә саклана. Мәсәлән, Хөсам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» поэмасының XIX йөз урталарына нисбәтле төрле күләмдәге өч күчермәсе шундыйлардан. «Авык кыйссасы»ның XVIII йөз ахыры һәм XIX йөзгә караган сигез кулъязмасы бар. Шулай ук «Кисекбаш» кита-

---

* Ходавәндә – *Хода;* кәлтерде – *китерде;* не куручи – *«не кричи», кычкырма;* будет пулна – «*полно», җитәр;* за шту кручить напрасна – *юкка ник кычкырырга.*

бы, «Кыйссаи Салсал», «Кыйссаи Әхтәм», «Таһир-Зөһрә кыйссасы» һ.б. кыйссаларның нөсхәләре тупланган.

Иҗат ителү вакыты белән XIII–XV йөзләргә нисбәт ителгән «Түләк-Сусылу» дастанының моңарчы фәндә берничә кулъязмасы мәгълүм иде. Ягъни, 1) Нәкый Исәнбәт архивындагы нөсхә, иҗат ителү вакыты билгесез; 2) Миркасыйм Госманов тарафыннан 1969 елда Кама Тамагы районының Олы Кариле авылында табылган (XIX йөзнең икенче яртысында күчерелгән) нөсхә; 3) 1985 елда Казанда Марсель Әхмәтҗанов тапкан, 1877 елда күчерелгән нөсхә һәм 4) 1994 елда Әтнә районының Олы Мәңгәр авылында шулай ук М.Әхмәтҗанов тапкан, XVIII йөзнең икенче яртысына караган фрагмент. Икесенең (2 һәм 3 саннар белән күрсәтелгәннәренең) текстлары басылып чыкты*.

Әлеге нөсхәләргә соңгы елларда «Түләк-Сусылу» дастанының янә бер нөсхәсе өстәлде. 1996 елның апрель аенда Самара өлкәсенең Камышлы районы Иске Ярмәк авылының имамы Габдулла хәзрәт Кәрим чакыруы буенча ул төбәккә археографик сәфәр оештырган идек. Табылган 160 берәмлек кызыклы кулъязма истәлекләр арасында әһәмиятле фәнни хәзинә – Камышлы авылы мәчетеннән алынган «Түләк-Сусылу» дастанының яңа күчермәсе булды. Бу хакта Самара өлкәсендә нәшер ителә торган «Бердәмлек» газетасында үз вакытында хәбәр иткән идек**. Дастан XIX йөзнең беренче яртысында күчерелгән җыентыкның 4–14 нче кәгазьләренә теркәлгән. Җыентыкта «Түләк-Сусылу» дастаныннан тыш, төрки телдәге шигъри бер әсәрнең ахыргы өлеше, Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» әсәре, төрле догалар һәм дини эчтәлекле язмалар урын алган. Кулъязманың кайбер битләре дефектлы. Бер битендәге язмадан бу җыентыкны Сибгатулла бине Фәхретдин исемле кеше күчергәнлеге аңлашыла. Кулъязма кәгазендә су билгесе белән 1832 ел билгеләнгән. Димәк, дастанның язма тексты моңарчы матбугатта басылган вариантлардан әүвәлгерәк.

---

* Госманов М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. – Тулыландырылган икенче басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 1994. – Б.225–300; Әхмәтҗанов М. Түләк белән Сусылу // Әдәби мирас (Дүртенче китап). – Казан: Татар. китап нәшр., 1977. – Б.14–33.

** Мәрдан Р. Якутлар табыладыр вакыт белән... // Бердәмлек. – 1996. – 2–8 июль.

Яңа табылган дастан текстына килгәндә, аның язуы тәртипсезрәк, хаталы, кайбер сүзләрне ялгыш язулар, кирәксезгә кабатлаулар чагыла. Әсәрнең башындагы бер бит чамасы өлеше юк. Ике-өч биттән соң тагын бер кәгазе төшеп югалган. Ахырдарак 5-6 җөмлә күчерелмичә, буш урын калдырылган. Әсәрнең ахыры кыскартылган, гадиләштерелгән вариантта.

Яңа текст моңарчы билгелеләре белән, нигездә, тәңгәл килә, зур аермалар юк. Ләкин шигъри строфаларда, сирәк булса да, үзгәлекләр күренә. Әлеге кульязмада төшеп калган строфалар булган кебек, яңалары да бар. Шулай ук, яңа кульязмадагы кушагъларның (җыр, такмак) ахыргы строфалары икешәр мәртәбә кабатлана һәм әсәрнең поэтик аһәңен көчәйтә вә бизи. Мәсәлән,

«Атың әйтче, Сусылу,
Атың нәдер, Сусылу!?»

«Түләк-Сусылу» дастанының яңа табылган Камышлы нөсхәсен текстологик тикшереп, тирәнтен өйрәнү, әлбәттә, киләчәктәге бурычлардан.

Әдәби мирасыбызның энҗе бөртегенә тиң кыйммәтле хәзинә – Казан ханлыгы дәвере әдибе, шагыйрь Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасының бер күчермәсе дә бар китапханәбездә. Ул Кукмара районының Уразай авылында Ибраһимов Имаметдин агаларда сакланган. 1999 елда аны китапханәгә студент кыз Гөлназ Гарипова тапшырды. Кульязма шактый ук дефектлы, күп кенә битләренең аскы итәкләре тетелгән һәм җуелган. Күп урыннарда язу карасы кәгазьне бозып, тишкәләгән. Кәгазенең су билгеләре аның 1701–1710 елларда Һолландиядә эшләнгәнлеген күрсәтә. Димәк, поэма XVIII йөздә күчерелгән. Кульязмада «Нуры содур» поэмасының баш өлеше сакланмаган, төп өлеше һәм ахыры бар. Текст кульязма җыентыкның 12–28 кәгазьләрендә урнашкан һәм бер биттә 16 юл булып язылган. «Нуры содур» поэмасының моңарчы фәнгә җиде күчермәсе билгеле иде. Татарстан Милли китапханәсендәге яңа табыш сигезенчесе булды.

Борынгылык җәһәтенә килгәндә, китапханәдәге иң әүвәлге кульязма XIV йөзгә карый. Җыентыкта ислам дине кануннары, фикъһ, астрономия буенча һәм башка язмалар белән беррәттән, гарәп тарихчысы Табарриның хезмәтеннән дә өзек бар. Кульязманы

күчерүченең исеме дә сакланган, ул – Дауд бине Мөхәммәд бине Хирыс (?) бине Мөхәммәд бине Җәгъфәр. Бу кулъязма истәлек китапханәбез өчен үзенең борынгы булуы белән һәм эчтәлеге ягыннан да әһәмиятле. Төркия җирлегендә XVII йөз ахыры – XVIII йөз башында күчерелгән тел гыйлеме һәм дини эчтәлекле язмалар, 1558 елда Мәхмүд бине Мостафа әл-Хәнәфи кулы белән күчереп язылган гарәп телендәге шигъри әсәр бергә тегелгәннәр.

Борынгы булуы белән дә, оригинальлеге белән дә әһәмиятле кулъязма истәлекләрнең берсе – төрек әдибе Зәгыйфи әсәрләре. Зәгыйфинең тулы исеме – Пир Мөхәммәд бине Әүрәнус бине Нуретдин бине Фарис. «Көллияте Зәгыйфи» исеме белән аталган кулъязма җыентыкта әдипнең биш әсәре туплап бирелгән. Беренчесе – «Китабе сәргезәшт» (15–32 кәгазьләр), әдипнең үз тәрҗемәи хәле һәм тормышын тасвирлаган төрки телдәге шигъри әсәр. Икенчесе – «Китабе сабрел-мәсаиб» (33–37 кәгазьләр), төрки телдәге чәчмә әсәр. Өченчесе – «Китабе рисаләи Җәүһәрия» – кыйммәтле ташлар: алмаз, йакут, энҗе, фирүзә, мәрҗән һ.б. турындагы «Җәүһәрнамә» исемле әсәрнең төрки телгә сайланма рәвештәге тәрҗемәсе; шунда ук авторның солтанга һәм башка шәхесләр исеменә язган хатларының текстлары теркәлгән. Дүртенчесе – «Китабе рисаләи имтихания» (58–68 кәгазьләр) исемле гарәп телендәге әсәр. Бишенчесе – «Диване Зәгыйфи» (69–123 кәгазьләр) исемле төрки телдәге шигъри әсәрләр тупламы.

Кулъязма җыентыкның аеруча әһәмиятле ягы шунда ки, аның текстлары тулаем авторның үз кулы белән каллиграфик нәфис итеп язылганнар. Һәр әсәрнең ахырында автор үз исемен күрсәтеп, бу кулъязманың үз кулы белән язылуын белдергән. Җыентыкның соңгы сәхифәләре һиҗри 964 елның 7 рабигыль-әүвәлендә (милади 1557 елның 8 гыйнварына туры килә) Кастантиния (Истанбул) шәһәрендә күчерелеп тәмамлануы белдерелгән. Кәгазьдәге су билгеләре дә бу датаны раслый, чөнки текст язылган кәгазьләр 1545–1554 елларда Европада эшләнгәннәр.

XVI йөздә Константиния шәһәрендә язылган әлеге автографик җыентык төрле кешеләр кулыннан үтеп (моны тышлыгындагы күпсанлы язмалар дәлилли), безнең якларга килеп җиткән. Хуҗаларының соңгы язмаларына караганда, Зәгыйфи җыентыгы 1970 елда

Кушлавыч авылы имамы Касыйм Мөхәммәдгали улы китапханәсеннән Казанда яшәүче Габдулла Фәйзрахман улына алынуы беленә.

Васфи Маһир Кужатүркнең «Төрек әдәбияты тарихы» (Әнкара, 1970 ел) китабында язылганнар буенча Зәгыйфи ләкабле ике төрек әдибе мәгълүм. Аларның берсе – XV йөзнең икенче яртысында яшәгәне «Солтан Морад хан» исемле бер әсәр язган. Икенчесенең бары тик исеме һәм 1552 елда вафат булуы билгеле, әсәрләре турында әйтелмәгән. Бу ике Зәгыйфи дә яшәгән дәверләре буенча бездәге «Көллияте Зәгыйфи» авторы булырга охшамаганнар. Шул ук Кужатүрк хезмәтендә XVI йөздә яшәгән Пир Мөхәммәд исемле (ләкабе күрсәтелмәгән) әдип турында языла, басылмаган әсәрләре бар диелә. Арадан Солтан Сөләйман Кануни дәверендә иҗат иткән «Шәфәгатьнамә» («Әрвахнамә») әсәренең исеме әйтелә. Яшәү һәм иҗат итү дәверенә караганда, соңгысы «Көллияте Зәгыйфи» китабының авторы белән бер үк кеше булуы ихтимал. Ләкин моны тәгаен тәфсыйльләп тикшерү таләп ителә.

Борынгы кульъязмалардан бездә шулай ук 1553, 1660, 1690, 1707, 1717, 1719 һәм башка елларга караган, күчерелү даталары тәгаен күрсәтелгән кульъязмалар бар. XVIII йөз һәм аннан соңгылары шактый. Кульъязма истәлекләр арасында күренекле шәхесләр һәм әдипләрдән Габдеррәхим Утыз Имәни, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Мирза Казембек, Ризаэтдин Фәхретдин, Гали Чокрый, Шәһид Әхмәдиев, Гариф Атаманов, Гадел Кутуй һ.б. үз куллары белән язылган хезмәтләре һәм әсәрләре дә булу – китапханәнең горурлыгы. Шулай ук укымышлы затлардан Ш.Мәрҗани, Габдулла Апанай, Р.Фәхретдин, Таиб һәм Гыйльман Яхиннар, Үзбәк Байчура, сәүдәгәрләрдән Үтәмешевләр, Госмановлар кебек танылган милләттәшләребезнең шәхси китапханәләрендә булган кульъязма китаплар фондларыбызда урын алды.

Борынгы әдәби тәрҗемә ядкярләреннән «Кәлилә вә Димнә» исеме белән танылган хикәяләр тупламының китапханәбездә өч кульъязмасы бар. Икесе – 1660–1670 нче еллар, ә берсе – XVIII йөз башы күчермәсе.

Халкыбызның әдәби мирасы хәзинәлегендә Һәмдәми исемле авторның фарсы шагыйре Фәридетдин Гаттар поэмасына нәзыйрә

сыйфатында иҗат ителгән «Нәсыйхәтнамә» исемле әсәре билгеле. Дөрес, бу әсәр әлегә аз өйрәнелгән. Әдәбият галиме Фәрит Яхин хәбәр итүенчә, әлеге әсәрнең моңарчы ике кулъязмасы фәнгә мәгълүм иде. Татарстан Милли китапханәсе хезмәткәрләре тарафыннан Һәмдәми поэмасының тагын ике күчермәсе табылды. Берсе – Тәтеш районының Келәш авылында сакланган. Баштагы һәм ахырындагы битләре җуелган бу күчермә безнең көннәргәчә 18 кәгазьдә килеп ирешкән. Су билгеләренә караганда, текст 1659–1660 елларда Европада эшләнгән кәгазьгә язылган. Икенчесен 1844 елда Эстәрлетамакта Мөхәммәдшәриф Хәлил улы күчергән. Тексты 15 кәгазьдә, башлангыч өлеше юк, ахыры бар.

Ф.Яхин «Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология» дигән хезмәтендә (Казан: ТДГИ нәшр., 2000. – Б.224–239) «Нәсыйхәтнамә» әсәренең авторын һәм иҗат ителү вакытын билгеләгән. Фәрит Яхин бу әсәрнең авторын Ризаэтдин Фәхретдиннең «Асар» хезмәтендә телгә алынган Хуҗамшөкер бине Гаваз-байга нисбәт итеп, поэманың язылу елы 1703 ел дип белдерә. Ләкин «Нәсыйхәтнамә»нең Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган XVII йөз күчермәсе бу версиянең хаклыгын шик астына ала. Чөнки 1703 елда иҗат ителгән әсәрнең 1659–1660 еллардагы кәгазьгә языла алу ихтималы бик шикле.

Милли китапханәдәге археографик табышлар арасында чын ачыш буларак бәяләнгәннәре дә бар. Мәсәлән, XVII йөз татар әдибе Мәүла Колыйның моңарчы әдәбият тарихында бөтенләй билгеле булмаган ике әсәре – «Береккәннәр сыйфаты» һәм «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» («Хәләл ризык теләүчеләр сыйфаты») поэмалары фондыбызда саклана. 1754 елда күчерелгән бу яңа табыш турында элегрәк язган идек. Шунда ук поэмаларның текстлары да дөнья күрде*. Поэма текстларының табылу мөһимлеге шунда ки, моңарчы аерым хикмәт-шигырьләр авторы буларак билгеле булган Мәүла Колыйның поэма жанрында да иҗат иткәнлеге ачыкланды.

Күренекле татар шагыйре һәм фикер иясе Габдеррәхим Утыз Имәни әсәрләренең күчермәләре дә китапханәбездә шактый тупланган. Арада иң кыйммәтлесе – 1804 елгы кулъязма китапның

* Мәрданов Р. «Гасый җафи Мәүла Колый сүзли, дуслар...» // Казан утлары. – 1996. – № 10. – Б. 160–171.

баштагы һәм ахыргы битләренә Габдеррәхим Утыз Имәнинең үз кулы белән язылган әсәрләре. Берсе – әдипнең «Гаварифез-заман» поэмасының «Фасл дәр табакате голәма» бүлеге. Текстның ахырында «тәммә галә йадил-мүәллиф мулла Габдеррәхим бине Госман әл-Болгари» дип язып, шигъри юлларның автор кулы белән теркәлгәнлеге белдерелгән. Икенчесе – «Нәзмы Габдеррәхим әл-Болгари» исеме астында «Анчә бидгать лязем...» дип башлана торган фарсыча дүрт юллы шигырь һәм аның татарчага сигезьюллык тәрҗемәсе («Ул нә бидгать лязем улды...»). Монысы да автор кулы белән язылган. Г.Утыз Имәнинең «Горбәтнамә» поэмасы моңа кадәр XIX йөзгә караган биш күчермәдә мәгълүм иде. Бездә исә аның шактый элгәреге, 1786 елга караган нөсхәсе бар.

Г.Утыз Имәнинең «Мөһиммәтез-заман» поэмасының моңарчы биш кулъязмасы һәм басылып чыккан нөсхәсе дә билгеле иде. Милли китапханәдә аның тагын өч күчермәсе бар. Берсе – XIX йөз уртасында, икенчесе – 1859 елда, өченчесе – XIX йөзнең ахырында күчерелгәннәр. Моңарчы өч кулъязмасы билгеле булган «Мәрсияи Хәмидә зәүҗәте Габдеррәхим Болгари» һәм бер кулъязмасы билгеле булган «Мәрсияи Габденнасыйр вәләде Габдеррәхим» шигырьләренең безнең китапханәдә XIX йөз башына караган берәр күчермәләре саклана. Ике мәрсия дә бер кулъязмада теркәлгәннәр. Фәндә бер кулъязмасы мәгълүм «Нәзмы чәй вә каймак» шигыренең XIX йөз уртасына нисбәтле бездәге яңа бер кулъязмасы шулай ук шагыйрь мирасын баета.

Габдеррәхим Утыз Имәнинең «Мөнәҗәт» («Иляһи, эстәрем синнән...») шигыренең XIX йөзнең беренче яртысыннан алып 1905 елга кадәр төрле еллардагы унбер күчермәсе фондларыбызда урын алды. Г.Утыз Имәнинең соңгы җыентыгын басмага әзерләгән әдәбият галиме Әнвәр Шәрипов хәбәренчә, моңарчы бу шигырьнең фәнгә өч күчермәсе билгеле булган. Татарстан Милли китапханәсендә Г.Утыз Имәнинең шәригать буенча татар телендә язылган бер хезмәтенең XIX гасыр уртасында күчерелгән нөсхәсе дә саклана.

Татар иҗтимагый фикерендә тирән эз калдырган мәшһүр мөселман фикер иясе Габденнасыйр Курсавиның (1776–1812) дини-фәлсәфи хезмәтләре фәнгә мәгълүм. Әмма аның шигъри әсәрләр иҗат

иткәнлеге билгесез иде. Истанбулда авыруга дучар булган Габденнасыйр Курсави тарафыннан иҗат ителгән дип күрсәтелгән шигъри юллар теркәлгән кульязма да бар китапханәбездә. [...]

XIX йөзнең беренче яртысына карый торган ул кульязма китапханәбезгә Яшел Үзән шәһәрендә яшәгән галим-педагог Шәриф ага Сайкиннан 1994 елда алынган иде. Андагы шигъри юллар, кульязмада күрсәтелгәнчә, чынлап та Габденнасыйр Курсавиның үз каләменнән чыккан яисә башка берәү тарафыннан язылып, Курсавига нисбәт ителгән булырга да бик мөмкин. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, китапханәдә Габденнасыйр Курсавиның гарәп телендәге «Шәрхе гакаиден-Нәсәфи» әсәренең күчермәләре дә бар.

Кульязмалар арасында Русиядә патша хөкүмәте дәверендәге рәхимсез тәртипләргә кискен ризасызлык белдергән эчтәлектәге шигъри әсәр дә бар. Ул Саба районындагы Ак Бигәнәй авылыннан 1996 елда табып алынган иде. Бу кульязма XVIII йөз ахырына караган кечкенә форматтагы дәфтәрдән гыйбарәт. Дәфтәрнең күп битләре җуелган һәм язуы да начар танылa. Дәфтәрнең сакланган өлешеннән күренгәнчә, бу шигъри әсәрнең күләмле булганлыгы күренә. Авторы мәгълүм түгел. Текстның бер өлешен монда күчерәбез.

«**Хикәят**

Дарел-хәраблек падишаһ императорның
рәгыйәтләренең хәлләренең бәйаны.

Питербурдыр бер кала – Руси шаһы тордыгы.
Һәрбер төрле хәлаикъның теләп килгән йирләре.
Шаһ ал[ад]ыр ясакны череп яткан үлекдин,
Бишектәге яшь баладин, сукыр, мескен, зәгыйфьдин.
Солдатлары хезмәт итәр карый булып үлгүнчә,
Йортындагы калганнары ясак түләр яңы ревиз булгунча.
Пушлинәләр аладыр тегермәндәге ташлардин,
Янә өч сум пушлинә дәгъвалашкан кешедин...
Тозлары Хак яратты, ашарга бик ярасы,
Кабул булды Ибраһим Хәлиулла догасы.
Ул тозлары эзләп алып, хәзинәгә саладыр
Хакыны кыйрәт сатып, файдасын күп аладыр.

[Пулклары] китереп, сугып, өзеп, үлтереп.
[Булган малын] дуңгызларга сатып алып йидереп...
Ярлыкаш бирер бу малдин үлгән сенаторларга,
Архәригә, монахларга, озын сачлы попларга.
Сенаторлар киеп йөрер алтын-көмеш туннарын.
Чабата ясап ясак түләр күзсез, аксаклар...[*]»

XIX йөзнең күренекле татар шагыйре Габделҗәббар Кандалый әсәрләре дә кульязмалар туплаганда очрап тора. Китапханәдә әдипнең «Мәгъшукнамә» поэмасының ике күчермәсе (берсе тулы диярлек, икенчесе аерым өзек), «Сахибҗәмал» поэмасының 1841 елгы язма фрагменты, «Рисаләи-л-иршад» поэмасының аерым өлешләреннән күчермәләр, шулай ук төрле шигырьләре теркәлгән дәфтәрләр бар.

Китапханәбездә язма мирас җәүһәрләреннән әдәби, бигрәк тә, шигъри әсәрләр күп тупланган. Гомумән, Шәрык әдәбияты классиклары, төрки шигърияте җәүһәрләре һәм татар әдипләреннән Хафиз, Зөһәйер, Сәгъди, Руми, Мирза Бедил, Җами, Фирдәүси, Нәсими, Нәваи, Фөзули, Мәшрәб, Ясәви, Гаттар, Аллаһыяр Суфый, Бакырганый, Кол Гали, Кол Гобәйди, Кол Шәриф, Өмми Кәмал, Һәмдәми, Мәүла Колый, Габдеррәхим Утыз Имәни, Рәхимкол Әбүбәкер угылы, Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Каргалый, Габделҗәббар Кандалый, Акмулла, Гали Чокрый һ.б. аерым шигъри җыентыклары яисә әсәрләре теркәлгән кульязмалар әнә шундыйлардан.

Тарихка бәйле кульязмалардан Пугачёв хәрәкәте турында мәгълүмат теркәлгән XVIII йөз ахыры язмасы да әһәмияткә ия. Бу хакта «Гасырлар авазы» журналында хәбәр басылган иде[**].

Татар халкында тарихи хезмәтләр буларак укылган әсәрләрдән Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» кульязмасының алты күчермәсе Татарстан Милли китапханәсендә саклана. Арада 1853 ел күчермәсе тулы текстны тәшкил итә. Шулай ук Таҗетдин

---

[*] дарел-хәраблек – *сугышчан, җимерек ил*; рәгыйәт – *халык*; хәлаикъ – *халыклар*; карый – *карт*; үлгүнчә – *үлгәнче*; кыйрәт – *карат, кыйммәтле ташларны үлчәү берәмлеге*; йидереп – *ашатып*; архәри – *архиерей*.

[**] Мөстәкыймов И., Мәрданов Р. Пугачёв күтәрелеше тарихыннан бер чыганак // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 1998. – № 3/4. – Б.220–224.

Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» («Тәварихы Болгария») хезмәтенең дә XVIII–XIX йөзләргә нисбәтле өч күчермәсе бар. Бу ике авторның тарихны тасвирлаудагы примитив алымнары һәм күпсанлы ялгыш-хаталары соңгырак дәвер татар тарихчылары тарафыннан тәнкыйтьләнсәләр дә, үз чорына күрә Мөслими һәм Ялчыгол китапларының халык арасында таралыш табуы – татар халкында тарихка карата кызыксыну булганлыгын күрсәтә торган бер дәлил икәнлеген инкяр итә алмыйбыз.

«Дәфтәри Чыңгызнамә» исеме белән мәгълүм дастаннар җыентыгыннан китапханәбездә «Аксак Тимер дастаны»ның ике кулъязмасы, «Гайсә угылы Амәт» дастанының бер битле күчермәсе, «Дастане фит-тарих»ның дүрт кулъязмасы бар. Алар барысы да XVIII йөз ахыры-XIX йөз башында күчерелгәннәр.

Фәндә татар сәяхәтнамәләре жанрындагы мәгълүм язма истәлекләрдән «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе» белән «Мөхәммәтәмин сәяхәтнамәсе» – иң мәшһүрләрдән. Беренчесенең XIX йөзгә нисбәтле бер, ә икенчесенең ике кулъязмасы фондларыбызда урын алды. Шулай ук игътибарга лаеклы башка сәяхәтнамәләр дә бар. Мәсәлән, хәрби хезмәттәге татар кешесе тарафыннан 1756 елда теркәлгән кулъязма шулар рәтеннән. Язмада хәрби поход, мишәр гаскәре, казаклар, Дон казаклары һ.б. турында тарихи мәгълүмат бирелү белән бергә, авторның башкача кызыклы шәхси күзәтүләре дә сәяхәтнамә жанрына хас стильдә чагылган. Соңгырак дәвер сәяхәтнамәләреннән Кукмара районы Төркәш авылының Гобәйдулла Рәхмәтулла улының 1938 елда Кырымга сәяхәте игътибарга лаек. 70 яшьлек автор, сәяхәтнамә жанрындагыча төгәллек белән, күргән-белгәннәрен, анда яшәгән Кырым татарлары, караимнәр, немецлар, болгарлар, греклар, яһүдләр һ.б. турында язып калдырган. Ул чордагы кырымтатар авыллары турындагы мәгълүматлар кызыклы. Кырымтатар халкының ачы язмышы һәммәбезгә мәгълүм. Сәяхәтнамәдә телгә алынган Солтансарай, Булгак, Азамат, Салтыбай, Орчык, Мәүлет, Тайган, Кортлык, Җимерек, Сәй һ.б. авылларның хәзерге вакытта күпчелегенең урыннары гына түгел, исемнәре дә җир йөзеннән юкка чыккандыр.

Мәшһүр татар тарихчысы һәм дини эшлекле Шиһабетдин Мәрҗани шәхси китапханәсенең язмышы шактый катлаулы һәм бутал-

чык. Галимнең вафатыннан соң бу бай китапханәнең бер өлеше юкка чыккан, варислары кулында сакланган өлешенең беркадәресе гыйльми оешмаларга – Казан университетының фәнни китапханәсенә, Татарстан Фәннәр академиясенең Мирасханәсенә сакланышка тапшырылган. Тик шулай да Мәрҗаниләр нәселен дәвам итүче варисларында Шиһабетдин хәзрәт китапханәсендә булган кыйммәтле язмалар әле дә сакланып килә.

Шиһабетдин Мәрҗанинең улы Борһанетдиннең оныгы Даниял абый Әмирханов (Казанда яши) 1998 елда Татарстан Милли китапханәсенә үзләренең гаилә архивларында сакланган кыйммәтле кульязмалар тапшырды. Моңарчы фән даирәсенә билгесез булган язма материаллар арасында Шиһабетдин Мәрҗанинең үз кульязмалары, аңа адресланган хатлар һәм бүтән язмалар бар. Арада аеруча игътибарга лаеклысы – Мәрҗани китапханәсенең китаплар исемлеге теркәлгән дәфтәр. Анда 430 нөсхә кульязма һәм басма китап теркәлгән. Әлбәттә, бу бай китапханәнең бер өлеше генә. Бу табышлар турында безнең тарафтан хәбәр бирелгән иде*. Ләкин анда Д.Әмирхановлар тапшырган янә бер дәфтәр турында әйтелмәде. Ул дәфтәр исә, чын-чынлап, милли тарихыбыз өчен гаҗәеп мөһим табыш һәм ачыш дип бәяләнергә хаклы.

1866 елда яшьли дөнья белән хушлашкан шәкерте Хөсәеннең гыйльми язмаларын Ш.Мәрҗани соратып алдырганлыгы фәндә мәгълүм иде. Фәезхановның гыйльми мирасыннан ике кульязманы «Рисалә» һәм «Ислахе мәдарис» хезмәтләрен Мәрҗани оныкларыннан Наҗия ханым Ильясова һәм Даниял әфәнде Әмирханов 1986 елда тарихчы-галим Миркасыйм Госмановка тапшыралар. Соңгы еллардагы эзләнүләр нәтиҗәсендә, шул ук Д.Әмирхановлардан Х.Фәезхановның тагын бер автографик кульязмасы табылды.

Утыз кәгазьдән торган (60 битле), 18х22 см зурлыгындагы гадәти генә дәфтәргә Хөсәен Фәезханов кулы белән «Касимский ханлыгы» (1а–8б кәгазьләрдә), «Казан ханлыгы» (9а–20а кәгазьләрдә) хезмәтләре һәм Болгар дәвере кабер ташлары текстларын тасвирлаган язмалар (21а–30а кәгазьләрдә) теркәлгән. Төзәтмәләр һәм өстәмәләр, текстларның бөтен булмавы ишарә итүенчә, бу язмалар га-

* Мәрданов Р. Шиһабетдин Мәрҗани мирасына бәйле кайбер яңа табышлар // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 2000. – № 3/4. – Б. 184–185.

лим тарафыннан ниятләнгән зур һәм гаять җитди хезмәтләрнең караламалары булуы аңлашыла. Бер урында исә Фәезханов Болгар дәүләте турында да хезмәт язганлыгын белдереп үтә. Хезмәтләренең теле Ш.Мәрҗани китаплары белән чагыштырганда күпкә җиңел. Әлеге тарихи хезмәтләрендә галим тарихи чыганакларның төрләренә һәм әһәмиятләренә киң тукталган. Аерым алганда, Казан тарихы буенча язма чыганаклар уңаеннан Х.Фәезханов «...Фаразан, андый тарих бер вакыт язылган булса да, ул заманда басма санагате булмаганнан, нөсхәләре таралмый калып, Казан мәмләкәтенең башына килгән бәлаләр вә бөлеклекләр арасында югалган булса кирәк... Русиялеләр үз тарихларын язганда Казан әхвален вә әхбарен дә язгалаганнар. Әмма ...бусы да бар: рус халкы ул заманда җаһил булганнар вә язган хәбәрләрен инсаф белән вә гыйльме тарих өчен язмаганнар, вә тәфтиш вә тәхкыйк итмәй (тикшермичә – Р.М.), гавам авызыннан ишеткәнчә вә үз политикаларына килешкәнчә язганнар... Бу сәбәптән рус тарихларына һәм тәмам ышанып җитеп булмайдыр. Шулай булса, ата-бабаларының әхвален вә Казан ханнарының тарихын белергә сусаган ватандашларымыз вә газиз мөселман карендәшләремезне кандырырдай бер дә чишмә юкмы вә бу хосуста өмид өзеп, карап тораекмы?» – дип, бу мәсьәләне мөселман һәм рус чыганаклары нигезендә өйрәнүгә керешүен белдерә.

Галим үз хезмәтендә Казан атамасы, Казан шәһәренең нигезләнүе, ханлыкның оешуы, халкы һәм сәясәте, әдәбияты, ташъязма истәлекләре һ.б. турында бәйан итә. Шулай ук Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария» хезмәте яртысыннан күп өлеше хаталар белән тулы булуын белдерә. Казан арты һәм Тау ягы авылларының атамалары турындагы фикерләре белән уртаклаша. Тау ягы авылларында Иван Грозный тарафыннан бирелгән грамоталар саклануын да искәртә. Бу хакта аның үз вакытында Ш.Мәрҗанигә дә хәбәр биргәнлеге билгеле. Болгар дәверендә мөселман булып, руслар кулына төшкәч чуашлыкларына (мәҗүсилеккә) кайткан һәм соңрак христианга әверелгән чуашлар һ.б. турында да яза.

Хезмәтләренең эпиграфикага багышланган өлешендә Тау ягындагы Әтрәч, Аксу, Байтирәк, Олы Яльчик авылларындагы Болгар чоры кабер ташлары текстлары тәфсыйльләп тасвирланган. Фәез-

ханов мондый ташларның ел саен бетә баруларын искәртә. Ул Әтрәч авылы янындагы зиратта сакланган 21 борынгы ташның текстларын күчереп алган. Шунда ук Әтрәч зиратындагы башка 20-30 ташның соңгы дәвердә генә алып кителеп, чиркәү нигезенә түшәлүләрен әрнеп язган. Хөсәен Фәезхановның эпиграфика буенча язмасы, тәгаен күрсәтелмәсә дә, 1862 елда теркәлгәнлеге аңлашыла.

Хөсәен Фәезханов гыйльми мирасының саллы бер өлешен тәшкил иткән бу табышларны галимнең башка хезмәтләре белән бергә туплап нәшер итү – нәүбәттәге бурычларыбызның берсе.

Даниял Әмирхановлардан Фәезханов дәфтәрләре белән бергә алынган тагын бер кызыклы дәфтәр турында әйтергә кирәк. Монысы Фәезханов кулы белән язылмаган. Үзендә авторы да күрсәтелмәгән. Язу-почеркы Каюм Насыйриның бертуган энесе Габделганинең кулына бик тә охшаш, шулай ук К.Насыйриның бертуган агасы Габделфәт кулына да охшаган. Әлбәттә, киләчәктә бу ачыкланыр. Ләкин Каюм Насыйриның агасы да, энесе дә мондый яки моңа охшаш эчтәлектәге хезмәт язганлыклары мәгълүм түгел. Ә алар кемнеңдер хезмәтен күчереп алган булулары бик мөмкин. Эчтәлеге исә кыскача татар тарихын бәйан итә. Хезмәтнең башында автор «ата-бабаларымның йорты – Казан мәмләкәтенең» үткән хәлләре турында кыскача булса да бер тарих китабы булмаганлыктан «үртәлеп, Казан татарлары телендә тәварих язмага тәвәккәл кылдым» дип белдергән. Уртача зурлыктагы дәфтәрнең 14 кәгазендә якынча 1860 елларда теркәлгән бу – «тәварих»та, нигездә, рус чыганакларына таянып, Болгар, Алтын Урда һәм Казан ханнары дәверендәге тарихи вакыйгалар турында кыскача мәгълүмат бирелә. Ахыргы битләре сакланмаганлыктан, бу тарихи кульъязма Хәлил хан дәверен (1462–1467 еллар) хикәя иткән урынында өзелеп калган.

Фондларыбызга тарихи-документаль, хроникаль язмалардан төрле мәсьәләләргә караган хосусый актлар, сату-алу кәгазьләре, метрикәләр кебек материаллар да тупланып килә. Андыйлардан сәүдә эшләре буенча 1765–1767 елларда теркәлгән хосусый актлар, Ижевск шәһәре мәчетендә язып барылган метрикә дәфтәрләре һ.б. бар.

Төбәк һәм авыл тарихлары, шәҗәрәләре, аерым нәсел шәҗәрәләре дә китапханәгә уңышлы гына җыйнала. Аерым алганда, Саба районының Мамалай, Арча районының Оры (Ясаклы Оры), Кукмара районының Төркәш һәм Әсән-Елга, Чирмешән районының Югары Чагадай һәм Туймәт, Ютазы районының Бәйрәкә, Киров өлкәсенең Таң авылы, Самара өлкәсенең Камышлы районындагы Камышлы, Иске Ярмәк, Иске Усман, Похвистнево районының Гали авылы тарихлары буенча материаллар һәм шәҗәрәләр бар. Болардан тыш, тарихыбызда мәгълүм шәхесләрдән Шиһабетдин Мәрҗани, Казаковлар һ.б. мәшһүр нәселләрнең шәҗәрәләре саклана. Аерым кулъязма җыентыкларны күчерүчеләр үзләренең унар буынга кадәр ата-бабаларының исемнәрен дә күрсәтеп язганнар. Болар да шәҗәрәләр исәбенә керергә лаеклы.

Шәҗәрә рәвешендәге силсилә-династияләр теркәлгән кулъязма истәлекләрнең кайберләре Адәм галәйһиссәламнән башланып, мөселман дөньясындагы суфыйлар һәм татар ишаннарын санап, 1950 нче еллардагы безнең җирлеккә килеп тоташа. Берсендә исә борынгы чордан алып гарәп һәм госманлы хөкемдарлары, солтаннарының династиясе сызылган, шәхесләргә карата тарихи хронологик искәрмәләр дә бирелгән.

Мәшһүр төрки-татар тарихчысы, дин галиме, җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм әдип Ризаэтдин Фәхретдингә бәйле берничә кулъязма да бар фондларыбызда. Аның берсе – Ризаэтдин Фәхретдин Шәлчәле (Чыршылы) мәдрәсәсендә шәкерт вакытында күчереп язган кулъязма җыентык. Җыентыкта 1874–1880 елларда аның кулы белән язылган «ишаннар силсиләсе», тәҗвид дәресләре, хәдисләр, гарәп телендәге шигъри әсәрләр. Бу кыйммәтле кулъязма Самара өлкәсенең Камышлы районы Иске Ярмәк авылында 1996 елның язында табып алынды. Икенчесен – шул ук Чыршылы мәдрәсәсендә 1887–1888 елларда язылган кулъязманы – китапханәгә Әбрар ага Кәримуллин 1995 елда тапшырган иде. Аңа исә китапны Иске Шөгер авылы укытучысы Сәгыйть Хәбиров биргән булган.

Мөхәммәтсадыйк Иманколый (1870–1932) – XX йөз башы татар иҗтимагый тормышында мәгълүм исемнәрдән. Дөрес, аның тормыш юлы һәм әдәби иҗаты әлегәчә тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Бу шәхескә махсус мәкалә багышлаган әдәбият галиме Мәс-

гуть ага Гайнетдинов та моны искәрткән иде*. Мөхәммәтсадыйк хәзрәт XIX йөз ахырында Бохарада белем алып, Казанга кайтып имам булган, дини һәм шигъри әсәрләр дә иҗат иткән каләм әһеле. Китапханәбездә М. Иманколыйның Бохарадагы вакытында үз кулы белән язган шигъри мәҗмугасе саклана. Бу җыентык 1891–1892 елларда язылган. Кульязмасына һәм үзе ясаган бизәк-нәкышьләргә караганда, М.Иманколый гаҗәеп матур язучы оста каллиграф-хаттат һәм рәссам да булган. Җыентыкта аның тарафыннан ясалган Мәккә, Мәдинә күренешләре, Нух пәйгамбәр көймәсе, планеталар хәрәкәтен тасвирлаган (астрономия буенча) рәсемнәр, үз кулы белән сызылган һәм төсле буяулар белән буялган Азия кыйтгасының картасы һ.б. бар.

Җыентыкның эчтәлегенә килгәндә, ул, нигездә, фарсы, гарәп һәм төрки телләрдәге Җами, Сәгъди, Хафиз, Мирза Бедил, Нәваи, Фирдәүси, Фөзули һ.б. Шәрык әдәбияты классикларының шигъри әсәрләре, робагыйлары белән тулы. Сүз һәм каләм осталарының бөек шигърият мирасы тәэсирендә иҗат иткән Мөхәммәтсадыйк Иманколыйның үз шигъри әсәрләре дә шул ук җыентыкта теркәлгән. Иҗатына өстән генә күз ташлаганда да, М.Иманколыйның шигъри мирасы борынгы классик Шәрык мәктәбен дәвам итүе белән әһәмиятле. Гомумән, бу җыентык әдипнең мирасын өйрәнү өчен менә дигән материал булып тора.

Игътибарга лаеклы кульязмалардан билгесез автор тарафыннан 1845 елда иҗат ителгән, фәлсәфи трактат характерындагы «Мәгарифе кальбият» исемле күләмле шигъри әсәр күчермәсе дә бар. Моңа хәтле бу әсәрнең Петербургта саклана торган бердәнбер кульязмасы билгеле иде. 1856–1860 нчы еллар тирәсендә күчерелгән нөсхәсен Милли китапханәгә 1994 елда Казан университеты доценты Җәүдәт әфәнде Сөләйманов тапшырды.

Кульязма хәзинәләр арасында борынгы җыр текстлары теркәлгәннәре дә бар. Мәсәлән, XVII йөзнең икенче яртысында язылган бер җыентыкта кызыклы гына бер җыр тексты сакланган. Аерым алганда, анда мондый юллар бар:

«...Ханнарның ханы, җаннарның җаны,
Галим йегетләр солтаны, бакча-сарайлар»;

---

* Гайнетдинов М. Юл чатында асылташ // Мәдәни җомга. – 2000. – 22 сентябрь.

«...Ушалдыр* хәлем, корбандыр җаным,
Мәмләкәт-малым бакча-сарайда»;
«...Барырым кырга, шоңкарым кулда,
Чөярем кызга бакча-сарайда».

Сөләйман Бакырганый хикмәтләре, «Кәлилә вә Димнә» хикәятләре һ.б. язылган бу кызыклы кульязма 1996 елда Балтач районының Түнтәр авылында табылган иде.

Борынгы җырлардан «Хан кызы» җырының да берничә күчермәсе барлыгын әйтеп китәргә кирәк.

Кульязмаларда фольклор әсәрләре күп очрый. Борынгы дәвергә нисбәтле, әле өйрәнәсе-тикшерәсе кызыклы әкият текстлары да бар.

Китапханәбездә төрле төбәкләрдән (бигрәк тә Татарстанның Тау ягы һәм Казан арты төбәкләреннән) тупланган шәкерт дәфтәрләрендәге бәетләрнең репертуары үзенең киңлеге белән таң калдырырлык. Ул дәфтәрләрдә язылган бәетләрнең исәбе-саны юк. Аерым дәфтәрләрдә теркәлгән бәетләрнең саны кайвакытта 20–25 тән артып китә, хәтта 34 төрле бәет теркәлгән дәфтәр дә бар. «Сак-Сок», «Нәүрүз», «Шәһри Болгар», «Сөембикә манарасы», сугыш бәетләре (төрек, япон, герман), «Солдат», «Шамил», «Перепись», «Шәкерт», «Ташаяк ярминкәсе», «Урыска сатып кияүгә бирелгән кыз», «Фәлше акча сугучылар», «Башмак», «Самавыр», «Тавык» бәетләре, шәхси фаҗига бәетләре һ.б. 1917–1919 еллардагы милли рух күтәрелеше дәверендә иҗат ителгән шигырьләр һәм җырлар, милли гаскәр маршлары теркәлгән дәфтәрләр дә күп кенә.

Кульязма истәлекләр арасында хатлар да күп очрый. Тарихи шәхесләргә бәйле хатлар да бар. Мәсәлән, Шиһабетдин Мәрҗанигә Сәлимгәрәй мөфтидән, энесе Садретдиннән, башка шәхесләрдән юлланган хатлар игътибарга лаеклы. Мәрҗанинең «Мөстәфаделәхбар...» хезмәтендә телгә алынган Хәсән бине Хәмит исеменә язылган дистәләгән хатлар, татар хаҗилары һәм сәүдәгәрләре, күп санлы имамнар, шәкертләр һ.б. хатлары гаять кызыклы. Казакъ балаларын укытучы шәкерт улына әтисенең үгет-нәсихәт биреп язган 1877 ел хаты кебек хатлар да бар.

---

* ушал – *шушы, шулай.*

Дини эчтәлекле хезмәтләр һәм әсәрләр китапханәдә тупланган кульязма мирасның зур бер өлешен тәшкил итә. Андыйлар арасында традицион китаплар булу белән беррәттән, сирәк хезмәтләр дә очрый. Мәсәлән, ислам-христиан, җәдитчелек мәсьәләләренә багышланганнардан «Миссионер Саблуковның Манзарател-җаваб исемендә Коръәнгә игътиразына рәддия», «Инҗил» һәм Гайсә өйрәтмәләре турындагы, Мөхәммәд Габдөһ карашларын бәйан иткән кульязмалар, Иж-Бубый мәдрәсәсе шәкертенең төрле дәресләрне язып барган конспектлары һ.б.

Дәвачылык һәм халык медицинасына караган кызыклы кульязмалар әледән-әле табылып тора. Китапханәдә дистәдән артык тыйбби эчтәлекле кульязмалар бар. Алар арасында Әбүгалисинаның «Канун фит-тыйбб» хезмәтеннән күчермәләр һәм «Гаййәтилбәйан фи тәдбири бәдәнил-инсан» исемле (1758 елда күчерелгән) китаплар да бар.

Табышларга юлыгуда да гаҗәп кызыклы мисаллар булгалый. Мәсәлән, 1999 елгы археографик экспедиция вакытында Оренбург өлкәсендә табылган кульязманың төшеп җуелган битләре 2000 елгы экспедициядә Пермь өлкәсендә табылды. Бу – ышанмаслык кебек тоелса да, факт! Әлеге кульязма – нәфис нәкышьле, XIX йөздә фарсы һәм гарәп телләрендә каллиграфик язылган Иран миниатюрасы. Аны хаҗга баручы милләттәшләребез татар җирлегенә алып кайткан булса кирәк. Ә бер кульязманың икегә аерылып, ике төбәктә табылуына килгәндә, бу гайре табигый хәл түгел. Китаплар да, халкыбыз кебек үк, элек-электән хәрәкәттә булган, кулдан-кулга күчеп йөргәннәр. М.Госмановның «Каурый каләм эзеннән» исемле хезмәтендә андый сәяхәтче китапларга махсус бүлек багышланган. Кульязма миниатюралар дигәннән, XX йөз башында Казанда «Исмәгыйль доктор» дип танылган күренекле табибның кызы Зөлфә ханым Госманова 1995 елда китапханәбезгә гаҗәеп бер кульязма Коръән бүләк иткән иде. Зурлыгы нибары 7х9 см булган 428 кәгазьле миниатюр Коръән китабы нәфис итеп язылган, сүрә исемнәре һәм һәр битендәге рамкалар алтын кара белән эшләнгән, һәр битендә текст 3х5 мәйданда урнашкан бу хикмәтле китап XVII йөздә Шәрык илләренең берсендә язылган.

1964 нче елда ук Казан университеты китапханәсенә «Мәрҗани» мәчетеннән алынган кулъязма истәлекләр арасында белорус татарлары тарафыннан язылган дини эчтәлекле китап булуы мәгълүм. Университет китапханәсендә аңарчы да гарәп язулы белорус телендәге ике кулъязма сакланган. Галим А.Антоновичның белорус телендә гарәп язулы истәлекләрне өйрәнүгә багышланган махсус хезмәте бар*.

1996 елның мартында «Мәрҗани» мәчетеннән Татарстан Милли китапханәсенә алдырылган борынгы язмалар арасында гарәп хәрефләре белән татарча һәм, нигездә, белорусча XIX йөз урталарында язылган китапның бер өлеше (43 кәгазьдә) табылды. Эчтәлеге буенча анда намаз тәртипләре һәм төрле догалар күчерелгән. Баштарак 1964 елда университет китапханәсенә алынган белорус телендәге кулъязманың бер өлеше түгелме дигән шигебез булса да, тикшереп карагач, мөстәкыйль кулъязма икәнлеге ачыкланды.

Рус теленең йогынтысы татар кулъязмаларында да ара-тирә чагылыш тапкан. Алдарак «Кыйссаи Йосыф» поэмасына пародия рәвешендә язылган бер әсәрнең өзеге китерелгән иде. XIX йөз башына караган ул кулъязмада Зөләйха, ни гаҗәп, «не куручи...» дип русча сөйләшә. Рус сүзләрен, бигрәк тә, татарча документларда, төрле хосусый актларда һәм фольклор әсәрләрендә күп кулланганнар. Татар телендәге гарәп язулы кулъязмалар өчен ятрак булган рус сүзләре беренче карашка аптыраштa да калдыра. Чөнки рус сүзләре шактый ук үзгәреш кичереп, татарчалаштырылган. Әйтик, XIX йөз урталарына караган бер дәфтәрдә «Иртәсен дә, кичен дә Зәйнәп ашый бәлинҗә...» диелгән, такмактагы «бәлинҗә» сүзе «варенье»ны белдерә. Ә инде XIX йөзнең ахыры һәм XX йөз башындагы татар шәкерт дәфтәрләрендә гарәп хәрефләре белән теркәлгән русча шигырьләр һәм җырлар күбрәк очрый. Ул чорда рус телен өйрәнгән татар шәкертләре язып куйган «Петушок», «Коровушка», «Зайчик» һ.б. шигырьләр инде алай ук сәер тоелмый.

Бүлеккә татар әдипләренең һәм галимнәренең шәхси архивлары да туплана. Хәзерге вакытта Шиһабетдин Мәрҗани, Гаяз Исхакый, Вафа Бәхтияров, Үзбәк Байчура, Шиһаб Рамазанов, Гыйбад Алпа-

---

* Антонович А.К. Белорусские тексты, написанные арабским письмом и их графико-орфографическая система. – Вильнюс, 1968.

ров, Хәсән Туфан, Бәян Гыйззәт, Шәриф Сайкин, Рашат Гайнанов, Альберт Фәтхи, Әбрар Кәримуллин архив материалларының аерым өлешләре монда саклана. Фотоматериаллар коллекциясе дә яхшы гына тупланып килә. Фондта Габдулла Тукай, Фатыйх Әмирхан, Гаяз Исхакый, Камил Мотыйгый, Заһидә Бурнашева, Хәсән Туфан һ.б. күренекле затларның төп нөсхә фоторәсемнәре бар.

Совет дәвере золымнарын, 1920–1930 нчы елларның кара сәхифәләрен чагылдырган мемуар һәм шигъри әсәрләр, документаль материаллар да аз түгел. 1921 елда сәнәкчеләр күтәрелешендә катнашуда гаепләнеп кулга алынган һәм большевиклар лагеренда җәфа чиккән Мөхәммәтгали Шәриповның башыннан кичкәннәрен теркәп барган көндәлеге «Мирас» журналында 1996 елда дөнья күргән иде. Шулай ук 1931 елда кулак дип гаиләсе белән Магнитогорскига сөрелгән Сабирҗан Шаһимәрданов бәет-мөнәҗәтенең текстын да матбугатка әзерләп бастырган идек*.

Мөһаҗирлектәге милли тарихыбызның бер истәлеге – 1934–1936 елларда Шанхай төрки-татар җәмгыяте идарәсе җыелышларының язмалары теркәлгән дәфтәр дә – китапханәбездәге кадерле истәлекләрдән. Аны 1993 елда китапханәгә АКШның Калифорния штаты Татар җәмгыяте президенты Равил Салиәхмәт тапшырган иде.

Китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге татар китабы мирасын пропагандалау эшен дә алып бара. Мәсәлән, беренче татар басма китабының 270 еллыгы уңаеннан Казанда 1992 елның 21–22 декабрендә Татарстан Милли китапханәсе тарафыннан «Татар китабының үткәне һәм бүгенгесе» исемле Халыкара фәнни-гамәли конференция оештырылды. Шулай ук, 1995 елның декабрендә Татарстан Милли китапханәсенә 130 ел тулуга багышланган «Кулъязма һәм борынгы басма китапларны туплау, саклау һәм өйрәнү мәсьәләләре» дип аталган фәнни-гамәли конференция уздырылды. Бу ике зур конференцияне һәм махсус бай күргәзмәләрне оештыруның төп үзәге китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге булды. Әлеге күргәзмәләрдә Казан университеты

* Мәрданов Р. Бер меңдә тугыз йөзләрдә утыз беренче елларда... // Әдәби мирас. 2 китап. – Казан: Татар. китап нәшр., 1992. – Б. 69–74.

Фәнни китапханәсе, Татарстан Дәүләт музее, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты «Мирасханә»се хәзинәләре дә күрсәтелде. Болардан тыш, китапханәдә кулъязма истәлекләрдән төзелгән тематик күргәзмәләр дә әзерләнеп һәм оештырылып килә. Мисалга, күптән түгел, 2001 елның август-сентябрь айларында, Россия Милли китапханәсе (С.-Петербург) белән бергә оештырылган, Милли китапханәдә куелган «Татар халкының әдәби мирасы» исемле күргәзмә җәмәгатьчелектә зур кызыксыну тудырды.

Матбугат чараларында даими рәвештә экспедицияләр һәм археографик сәфәр табышлары турында мәгълүмат биреп барыла. Конференцияләрдә дә, матбугаттагы чыгышларда да кулъязма истәлекләрне барлау, саклау һәм өйрәнү буенча китапханә чикләрендәге һәм гомуми масштабтагы хәл ителәсе мәсьәләләр, проблемалар да искәртелә килә. Бигрәк тә борчыганы – кулъязма чыганаклар һәм архив материаллары белән тиешле дәрәҗәдә эшләрлек әзерлекле белгечләрнең җитешмәве. Югыйсә, кулъязмалар туплауны актив рәвештә дәвам итәргә дә, аларны эшкәртеп өйрәнергә дә, яхшы сакланышларын тәэмин итәргә дә, гыйльми тасвирламаларын хәзерләргә дә кирәк. Тупланган кыйммәтле материалларның сакланышы һәм аларны консервацияләү-реставрацияләү мәсьәләсенә мәкаләбездә киңәеп тукталмадык. Бу бик җитди һәм комплексы чаралар таләп итә. Аларның да уңай хәл ителәчәгенә шигебез юк. Чөнки Татарстан Милли китапханәсенең Химаячеләр шурасы рәисе Р.И.Вәлиев һәм китапханә директоры Н.Ә.Камбеев борынгы мирасыбызны туплау һәм саклау юнәлешендә моңарчы алып барылган актив эшчәнлекнең дәвамын тәэмин итүне белдерәләр.

Мәкаләбез башында берничә сорау куелган иде. Татарстан Милли китапханәсе Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең ун еллык эшчәнлегенә күзәтү рәвешендәге бу мәкаләдә ул сорауларга җавап бирергә тырыштык. Әйе, 1992 елда Татарстан Милли китапханәсендә бу яңа бүлекне оештыру, һичшиксез, үзен аклады һәм бүлек берникадәр эш күрсәтүгә иреште дип бәяләү хакыйкатькә хилаф булмас. Киләчәктә исә тагын да күбрәк һәм зуррак эшләр, ә алар белән бергә уңышлар көтә дип өметләнәбез.

Китапханәбездәге Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә кулъязма мирасны туплау һәм өйрәнү өлкәсендә моңарчы актив

катнашкан яшь белгечләребезнең исемнәрен дә әйтеп китәргә кирәк. Ирек Һадиев (хәзер китапханәнең директор урынбасары), Айрат Заһидуллин (хәзер Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире), Ильяс Мөстәкыймов, Рафаэль Яруллин һәм Алсу Нәҗипова халкыбызның кулъязма мирасын саклап калуда үзләренең лаеклы өлешләрен керттеләр. Алар белән берлектә язма мирасыбызның энҗе бөртекләрен эзләп йөзләгән авыллар йөрелде, шәһәрләрдә эш алып барылды, меңләгән капка-ишекләр ачылып, күпме милләттәшләребез белән танышып, әңгәмәләр корылды.

Сүзебез ахырында тарихыбыз өчен гыйльми әһәмияткә ия булган тиңдәшсез кыйммәтле кулъязма истәлекләрне саклап, Татарстан Милли китапханәсенә тапшырган барлык милләттәшләребезгә дә ихлас рәхмәтләребезне юллыйбыз.

*2001 ел, сентябрь-октябрь.*

## ТАРИХКА – ЙӨЗ БЕЛӘН*

**– Раиф әфәнде, әңгәмәбезне үзегез белән таныштырудан башлыйк әле.**

– Мин үзем Әгерҗе районыннан, Тәбәрле авылында туган кеше. Тарих белән кечкенәдән кызыксынам.

**– Татар әдәбияты, татар журналистикасы тарихына кереп китсәң дә эш бик күптер. Студент чакта үзем дә бераз кызыксынган идем.**

– Чыннан да, бу өлкәгә кереп китсәң, бер кешегә ике гомер бирелсә дә вакыт җитми калачак. Безнең халыкны гарәп графикасыннан аерганнар бит. Төп бәлаләрнең берсе шул. Менә бер генә мисал. Мин туган Тәбәрле авылыннан 4-5 чакрым ераклыкта гына Яңа Аккуҗа авылы бар. Шул авылда яшәүче Фазлый Гыймазов дигән бабайда сакланган иске китаплар һәм кулъязмалар арасыннан Мәүла Колыйның моңа кадәр әдәбият тарихында билгеле булмаган ике поэмасы килеп чыкты. Билгеле инде, поэмалар гарәп графикасында язылган.

* кыскартып алынды.

Миңа шулай ук татар галимнәре Шиһабетдин Мәрҗанигә бәйле язмалар, Хөсәен Фәезхановның да моңарчы билгеле булмаган тарихи хезмәтләрен табарга насыйп булды. Әйе, кызыксынсаң, эзләнсәң Мәрҗани, Мәүла Колый кебек башка шәхесләрне дә халкыбызга кайтарып була.

**– Галим булып танылуда каршылыкларга очрарга туры киләме?**

– Тормыш булгач барысы да буладыр инде. Менә бер мисал китереп үтим әле. Мәүла Колыйның ике поэмасы турында әйтеп киткән идем бит. Шуларны табу турында «Казан утлары»ның 1996 ел, 10 нчы санында язып чыктым, поэмаларның текстлары шул санда ук басылды. 2000 елда исә татар әдәбияты тарихына багышланган бер гыйльми хезмәт һәм М.Колыйның ике җыентыгы дөнья күрде. Ә аларда поэмаларның табылуы турында – ләм-мим...

Әңгәмәдәш – Харис Закиров.

*Мәгърифәт. – 2004. – 26 июнь.*

## ИСЕМНӘР КҮРСӘТКЕЧЕ

Адәм галәйһиссәлам – 69
Аксак Тимер – 34, 45, 65
Акмулла – 64
Акчуриннар – 10
Аллаһыяр Суфый – 33, 38, 45, 64
Аллямов Барый – 9
Алпаров Гыйбад – 73
Антонович А. – 73
Апанаев Габдулла – 29, 33
Апанаева Хауа – 29, 30, 34
Атаманов Гариф – 60
Атласи Һади – 48

Әбүгалисина – 72
Әмачи (Әхмәтҗан) – 51
Әмирхан Фатих – 13, 74
Әмирханов Даниял – 66, 68
Әсән – 30
Әхмәди Габдеррәхим улы – 28
Әхмәдиев Габдеррәүф – 34
Әхмәдиев Шәһид – 60
Әхмәтҗанов Әхмәтша – 31
Әхмәтҗанов Марсель – 57
Әхмәтталипов Нәҗметдин – 52

Байчура Үзбәк – 60, 73
Бакиров Марсель – 6, 7, 12
Бакыев Галим – 32
Бакырганый Сөләйман – 39, 64, 71
Бариев Гали – 31
Баязитова Гафифә – 6
Бәхтияров Вафа – 13, 73
Бәшәр Габдеррәшид улы – 45
Бәшири Зариф – 11
Бибимәсрүрә – 45
Бибифатыйма Мөхәммәди кызы – 38
Бигашева Рәисә – 52
Бигиев Муса – 48
Бигичев Хәйдәр – 8
Бикбау – 51
Биктимер – 51

Болгари Мәхмүд – 56
әл-Бөрсети Фәхретдин Садыйк улы – 25
Бурнашева Заһидә – 55, 74

Ваһапов Рәшит – 8
Вәлиев Разил – 18, 53, 75
Вәли Равил – 16

Габдрахман хәзрәт – 24
Габделгаффар Җармөхәммәд улы – 28
Габделкаюм – 51
Габденнасыйр вәләде Габдеррәхим – 61
Габдессәлам бине Уразай – 56
Габдөһ Мөхәммәд – 72
Габдулла Фәйзрахман улы – 60
Габдулла хәзрәт – 27
Гайнан – 51
Гайнанов Рашат – 74
Гайнетдинов Мәсгуть – 70
Гайнетдинова Лилия – 40
Гайсә – 65, 72
Галиев Рөстәм – 26
Галимҗан Мөхәммәтҗан улы – 48
Гаратуев Мәсгут – 20, 49
Гарипова Гөлназ – 58
Гариповлар – 19, 32
Гатауллин Мохтарулла – 32
Гатауллина Һаҗәр – 26
Гатаэтдин Шәйхетдин улы – 45
Гаттар Фәридетдин – 38, 60, 64
Гафури Мәҗит – 56
Гәрәев Равил – 25
Гәрәева Энҗе – 22
Гобәйдулла – 51
Гобәйдулла Рәхмәтулла улы – 32, 65
Гобәйдуллин Газиз – 25, 48
Госман – 51
Госманов Исмәгыйль – 72
Госманова Зөлфә – 72
Госманов Миркасыйм – 8, 21, 57, 60, 66, 72
Госмановлар – 60
Гыйбадуллин Гамил – 37
Гыйззәт Бәян – 74

Гыйззәтулла Һидәятулла улы – 44
Гыйззәтуллин Муллагаян – 26
Гыйльманов Хаҗиб – 32, 51
Гыймазов Фазлый – 76

Дауд бине Мөхәммәд бине Хирыс (?) бине Мөхәммәд бине Җәгъфәр – 59
Даутов Халит – 47
Даутова Бибигабидә – 46, 47
Дәүләтшина Һәдия – 51

Җами – 64, 70
Жданов-Җәнәй Мөхәммәтсәлах – 47
Җәлалиев Камил – 51
Җәлил Муса – 12

Закиров Харис – 77
Закиров Хатыйп – 23
Закирова Гөлнур – 39
Заһидуллин Айрат – 76
Заһидуллин Вакыйф – 6
Заһидуллин Рәфыйк – 51, 52
Зәгыйфи (Пир Мөхәммәд бине Әүрәнус бине Нуретдин бине Фарис) – 59, 60
Зәйнуллин Вакыйф – 33
Зөфәр абый – 31
Зөһәйер – 64
Зыятдинов Фариз – 21

Ибраһим пәйгамбәр – 63
Ибраһимов Галимҗан – 6, 11, 18, 25, 75
Ибраһимов Илгизәр – 34
Ибраһимов Имаметдин – 58
Ибраһимов Фәрһад – 52
Иван Грозный (Явыз Иван) – 11, 12, 67
Ильясова Нажия – 66
Иманколый Мөхәммәтсадыйк – 70
Исәнбәт Нәкый – 57
Исмәгыйль Бикмөхәммәт улы – 30, 65
Исмәгыйлевләр – 25
Исмәгыйлев Равил – 25, 26
Исхакый Гаяз – 10, 48, 73, 74

Йосыпов Тәлгать – 39, 40
Йосыф – 5, 11, 20, 51, 55, 56, 72

Кавиев Рәкыйп – 34
Казаковлар – 69
Казембек Мирза – 60
Камали Зыяэтдин – 36
Камбеев Наил – 75
Кандалый Габделҗәббар – 9, 20, 23, 28, 41, 44, 45, 52, 56, 64
Кануни Солтан Сөләйман – 60
Каргалый Әбелмәних – 19, 32, 64
Касыйм Габделкави улы – 32
Касыйм Мөхәммәдгали улы – 60
Кәрим Габдулла – 41–43, 46, 57
Кәримев Зөһди – 10
Кәрими Фатих – 11, 25
Кәримова Мәликә – 52
Кәримуллин Әбрар – 18, 30, 33, 34, 53, 69, 74
Кол Гали – 9, 20, 23, 55, 64
Кол Гобәйди – 64
Кол Шәриф – 23, 64
Котдусов Мөхәммәтгата – 48
Кужатүрк Васфи Маһир – 60
Курамшин Рамил – 8
Курсави Габденнасыйр – 23, 37, 44, 61, 62
Курсави Габделхаликъ – 38
Кутуй Гадел – 60

Ленин В.И. – 12, 17

Максудова Зәйнәп – 7, 48
Маркс Карл – 12
әл-Мәгарри Әбүл-Галә – 25
әл-Мәмсәви әл-Бөрбаши Сәидев Мөхәммәтгариф Мөхәммәди улы – 38
Мәрданов Раиф – 3, 5, 6, 17, 61, 64, 66, 74
Мәрҗани Борһанетдин Шиһабетдин улы – 66
Мәрҗани Садретдин – 71
Мәрҗани Шиһабетдин – 29, 30, 33, 34, 38, 45, 48, 60, 65–67, 69, 71, 73, 77
Мәүла Колый – 3, 5, 21, 61, 64, 76, 77
Мәһдиев Рөстәм – 6
Мәшрәб – 64
Миңнебаева Римма – 26
Миңнегали абзый – 46
Миңнуллин Җәүдәт – 6
Мирза Бедил – 64, 70
Мифтахова Бибинур – 39

Мифтахова Фәния – 30
әл-Морзавый Ибраһим Сәлимҗан улы – 25
Мостафин Мәхмүт – 29
Мостафина Суфия – 29
Мотыйгый Камил – 13, 74
Мөбарәкшин Равил – 39, 40
әл-Мөслими Хәсән бине Хәмит – 38,
Мөслими Хисаметдин – 51, 57, 64, 65, 67
Мөстәкыймов Ильяс – 64, 76
Мөхәммәдев Шакир – 56
Мөхәммәди – 51
Мөхәммәдьяр – 58
Мөхәммәтәмин Гомәр улы – 65
Мөхәммәтгәрәй Әһлиулла улы – 44
Мөхәммәтҗан Мозаффар улы – 40
Мөхәммәтзакирова Таифә – 51
Мөхәммәдшәриф Хәлил улы – 61

Насретдинов Ниязи – 47
Насыйри Габделгани – 68
Насыйри Габделфәт – 68
Насыйри Каюм – 11, 48, 68
Нәбиева Әнисә – 14, 16, 20
Нәваи – 64, 70
Нәҗми Кави – 8
Нәҗипова Алсу – 76
Нәсими – 64
Нургалиев Марат – 26
Нуретдинова Бибимәрфуга – 26
Нуриев Әюп – 3 2
Нуриев Үзбәк – 32
Нух пәйгамбәр – 70

Өмми Кәмал – 64
Пугачёв Е. – 64

Рамазанов Шиһаб – 48
Рәкыйпов Әмирхан – 32
Рәмзи Морад – 48
Рәмиевләр – 64
Рәхимкол Әбүбәкер улы – 38
Рәхимова Закирә – 6
Руми Җәлалетдин – 38, 64

Сабиров Сәйяр – 9
Сабитов Илһам – 6
Саблуков – 72
Сайкин Шәриф – 21, 63, 74
Садрый Мөхәммәт – 55
Сафин Фаяз – 37
Сәгъди – 64, 70
Сәлиәхмәт Равил – 74
Салихов-Каргалый Һибәтулла – 19, 20, 32, 45, 64
Сәлимгәрәй мөфти – 71
Сибгатулла Фәхретдин улы – 44, 57
Сибгатуллин-Бубый Габдулла – 20
Сираҗиева Рәисә – 26
Солтан Морад хан – 60
Солтанова Рокыя – 26
Сөләйманов Җәүдәт – 70
Сөнгатулла Яхъя улы – 25

Табарри – 58
Таҗетдинов Габдулла – 34
Талипов Хәбибулла – 32
Тукай Габдулла – 10, 11, 13, 25, 47, 48, 56, 74
Туфан Хәсән – 74
Түнтәри Әбүннәкыйп – 40
Түнтәри Ибраһим Хәлил улы – 40
Түнтәри Хәсән Габделмән улы – 40

Утыз Имәни Габдеррәхим – 9, 23, 45, 60–62, 64

Үтәмешевләр – 33, 34, 60
Үтәмешев Муса бине Габдулла – 33
Үтәмешев Хәсән бине Мостафа – 33

Фазлыев Җәлил – 37, 38
Фәезханов Хөсәен – 5, 8, 60, 66–68, 77
Фәизова Фәрзәнә – 52
Фәтхи Альберт – 8, 13, 74
Фәхретдин Ризаэтдин – 10, 11, 25, 44, 48, 57, 60, 61, 69
Фирдәүси – 64, 70
Фөзули – 64, 70

Хаҗиева Мәймүнә – 31
Хатыйпова Рәшидә – 24
Хафиз – 64, 70
Хәбибрахман Габдулла улы – 33, 34

Хәбибрахманова Фәүзия – 33
Хәбибулла Нигъмәтулла улы – 28, 32
Хәбиров Сәгыйть – 69
Хәлил хан – 68
Хәлиулла хәзрәт – 46
Хәмидә – 62
әл-Хәнәфи Мәхмүд бине Мостафа – 59
Хөсам Кятиб – 32, 56
Хәсәнова Әминә – 6
Хуҗамшөкер бине Гаваз-бай – 61
Хуҗиәхмәтев Әмирҗан – 50

Һадиев Ирек – 22, 31, 76
Һәмдәми – 60, 61, 64

Чәләби Мөхәммәт – 24
Чокрый Гали – 28, 55, 60, 64

Шакиров Шамил – 37
Шакирова Гөлнур – 54
Шамил – 21, 37, 52, 71
Шаһимәрдан – 51
Шаһимәрданов Сабирҗан – 74
Шәйхетдин – 45
әл-Шәлчәли Габделфәттах Габделкаюм улы – 44, 69
Шәмсетдинова Гөлчирә – 30
Шәрипов Әнвәр – 62
Шәрипов Мөхәммәтгали – 14–16, 74
Шәрифуллина Хәләмгөл – 34

Энгельс Фридрих – 12

Якубова Л. – 15
Ялчыгол Таҗетдин – 65
Яппарова Рабига – 32
әл-Ярмәки Җарәхмәт Габделкадыйр улы – 45
Яруллин Рафаэль – 76
Ясәви – 64
Яхин Әнвәр – 6, 7
Яхин Илдар – 26
Яхин Гыйльман – 60
Яхин Таиб – 38, 60
Яхин Фәрит – 6

## ГЕОГРАФИК АТАМАЛАР КҮРСӘТКЕЧЕ*


Адай авылы – 28
Азамат авылы – 65
Азия – 70
Ак Бигәнәй авылы – 63
Аккүз авылы – 28
Аксу авылы – 67
Актаныш районы – 50
Акъяр авылы – 28
Алабуга өязе – 28
Алтын Урда – 23, 68
Америка – 17, 20
Англия – 17
Апас районы – 21, 55
Архангельск – 15
Арча районы – 55, 69
Аю-Көйдергән авылы – 21

Әгерҗе районы (авылы, шәһәре) – 3, 20, 28, 55, 76
Әйшә авылы – 51
Әсән-Елга авылы – 51, 52, 69
Әстерхан – 23
Әтнә районы – 57
Әтрәч авылы – 67, 68

Байлар Сабасы – 24–26
Байсар авылы – 28
Байтирәк авылы – 67
Байтуган авылы – 42
Бакай авылы – 42–46
Балтач районы – 3, 37–40, 44, 71
Балыклы авылы – 45
Башкортстан – 3, 14, 15, 47, 54, 55
Бәйрәкә авылы – 67, 69
Биклән авылы – 28
Болгар – 21, 24, 31, 58, 65–68, 71
Болгария – 9, 51, 57, 64, 65, 67
Бохара шәһәре – 28, 50
Бөрбаш авылы – 37, 38


* Казан һәм Татарстан атамалары һәр бит саен диярлек булганга, алар бу күрсәткечтә аерым күрсәтелмәделәр.

Бөре өязе – 14
Булгак авылы – 65

Вятка губернасы – 29
Вятка елгасы – 57
Вятские Поляны – 51

Гали авылы – 69
Горький өлкәсе – 3, 8

Динис авылы – 55
Дон елгасы – 65

Европа – 59, 61
Екатеринбург шәһәре (өлкәсе) – 6, 14

Җимерек авылы – 65
Җөри юлы – 25, 26

Зөя өязе – 29
Зур Сәрдек авылы – 31

Ижау шәһәре – 20, 27–29, 46–49
Иж-Бубый авылы – 20, 72
Изел – кара: Вятка елгасы
Илеш районы – 14
Иран – 72
Иркутск шәһәре – 45
Иске Җөри авылы – 56
Иске Икшермә авылы – 24
Иске Мичән авылы – 24
Иске Усман авылы – 42, 69
Иске Шөгер авылы – 69
Иске Ярмәк авылы – 41–43, 44, 46, 57, 69
Истанбул – 9, 36, 59, 63
Ишавыл авылы – 11

Йонлы авылы – 14, 15

Казан арты – 31, 67, 71
Казан губернасы (өязе) – 29
Казанчы Бигәнәй авылы – 26
Калифорния штаты – 43
Кама Тамагы районы – 57
Каменск-Уральск шәһәре – 14
Камчатка – 6
Камышлы авылы (районы) – 41–46, 57, 58, 69

Канада – 17
Каргалы авылы – 28
Касыйм шәһәре – 66
Кәчемир авылы – 31, 34
Келәш авылы – 61
Кече Сөн авылы – 25
Киндеркүл авылы – 31, 34
Киров өлкәсе – 19, 69
Константиния шәһәре – 59
Кортлык авылы – 66
Кочки-Пожарки авылы – 11
Көчек авылы – 28
Кронштадт – 45
Кукмара посёлогы (районы) – 3, 19, 31, 33–36, 50, 52, 58, 65, 69
Курса авылы – 38
Кушлавыч авылы – 60
Куян авылы – 28
Күкчә авылы – 51
Кырым – 23, 65
Кырынды авылы – 2
Кытай – 20

Лаеш өязе – 29

Магнитогорск шәһәре – 74
Маклаково авылы – 11
Малтабар авылы – 28
Малмыж шәһәре (өязе) – 29, 33
Мамадыш өязе – 29
Мамалай авылы – 69
Манзарас авылы – 31, 34
Мәдинә шәһәре – 70
Мәккә шәһәре – 70
Мәмәшир авылы – 19, 31
Мәскәү – 11, 12, 37
Мәүлет авылы – 66
Мәчкәрә авылы – 31, 33, 34
Минзәлә өязе – 28
Мисыр – 25, 29, 36

Нажар авылы – 28
Норма авылы – 44
Нырты совхозы – 51, 52

Оренбург өлкәсе – 6, 42, 54, 72
Олы Кариле авылы – 57
Олы Мәңгәр авылы – 57
Олы Яльчик авылы – 67
Оры (Ясаклы Оры) авылы – 67
Орчык авылы – 65

Өлге авылы – 51, 52

Пенза өлкәсе – 54, 55
Пермь өлкәсе – 54, 55, 72
Петербург шәһәре – 70, 75
Петряксы авылы – 9
Похвистнево районы – 69
Пучы авылы – 28
Пүләнкә –кара: Вятские Поляны

Россия (Русия) – 2, 16, 23, 37, 63, 67, 75

Саба районы – 3, 23, 24, 27, 63, 69
Сабабаш авылы – 24, 25
Салагыш авылы – 28
Салтыбай авылы – 65
Самара өлкәсе – 3, 41, 42, 54, 55, 57, 69
Сарапул шәһәре (өязе) – 28, 48
Сасна авылы – 37
Сатыш авылы – 24
Сафаҗай авылы – 9
Сәй авылы – 65
Свердловск өлкәсе – 20
Себер – 23, 24
Северный районы – 42
Сергач районы – 8–21
Сокман авылы – 28
Солтансарай авылы – 65

Тайган авылы – 66
Таң авылы – 69
Татар Икшермәсе авылы – 24, 26
Тау ягы – 21, 67, 71
Тәбәрле авылы – 76
Тәтеш өязе (районы) – 29, 61
Teләче районы – 55, 56
Тирсә авылы – 28
Тобольск шәһәре – 55

Төркия – 9, 17, 25, 59
Төрдәле авылы – 28
Төркәш авылы – 31, 32, 65, 59
Туймазы – 6
Туймәт авылы – 69
Тукай авылы – 10
Тургай авылы – 42
Түбән Арбаш авылы – 51, 52
Түбән Новгород өлкәсе – 8, 11, 13, 54
Түнтәр авылы – 39, 41, 74
Тырново шәһәре – 9

Удмуртия – 3, 46, 49
Ульяновск өлкәсе – 3, 6, 12, 13
Уразай авылы – 56, 58
Уфа шәһәре (губернасы) – 14–17, 55

Һиндстан – 29
Һолландия – 58

Шанхай – 74
Шепшеңәр авылы – 51, 52
Шыгай авылы – 28

Чабаксар өязе – 28
Чиләбе өлкәсе – 6
Чирмешән районы – 69
Чистай өязе – 28
Чуракай авылы – 50
Чүмбәли авылы – 10
Чыршылы авылы – 69

Эстәрлетамак авылы – 61

Югары Шытсу авылы – 24, 26
Югары Чагадай авылы – 69
Ютазы районы – 5, 69

Яңавыл районы – 47, 48
Яңа Аккуҗа авылы – 76
Яңа Усман авылы – 42, 44, 46
Яңа Чәбия авылы – 31, 34
Ятмас Дусай авылы – 51, 52
Яшел Үзән шәһәре – 21, 63

## Резюме

Татарская рукописная и печатная книга – зеркало истории и культуры татарского народа, его образованности и просвещения.

Пятый выпуск серии «Татарская археография» представляет собой сборник статей об археографических изысканиях и исследованиях, проведённых сотрудниками Национальной библиотеки Республики Татарстан. Статьи отражают результаты археографических экспедиций, проведённых в городах и сёлах Республики Татарстан, Республики Башкортостан, Удмуртии, а также в Горьковской, Кировской, Самарской и Свердловской областях. Одна из статей посвящена итогам археографической экспедиции Казанского государственного университета 1986–1992 годов, участником которых являлся сам автор.

Книга содержит обзор некоторых коллекций арабографичных рукописей, сведения о дарителях отдельных рукописей, а также выдержки из родословных, колофонов рукописных книг, исторических документов.

Статьи, представленные в сборнике, были написаны в 1991–2004 годы и опубликованы в периодических изданиях города Казани, районных газетах республики (Агрызском, Балтасинском, Кукморском, Сабинском), а также в периодической печати других республик (Удмуртии, Башкортостана, Чувашии) и областей (Горьковской, Самарской, Ульяновской и др.). Однако тексты статей сборника не полностью соответствуют вариантам статей, опубликованных в печати. Подвергнутые редакционной обработке многие статьи автора, к сожалению, были напечатаны в периодических изданиях в сокращенном варианте. В настоящем издании статьи представлены в их первоначальном виде. В то же время отдельные статьи изначально приведены в сокращенном варианте, прежде всего это относится к материалам, не полностью соответствующим тематике серии.

Статьи Р.Ф.Марданова, посвященные археографическим исследованиям и опубликованные ранее в серии «Татарская археография», в данный сборник не вошли.

**Эчтәлек**

Кереш ........................................................................................ 3

Китапларда милләт язмышлары.............................................................. 6
Рухи җәүһәрләр эзеннән ....................................................................... 8
Татарстан Милли китапханәсендә татар кулъязма һәм
басма китапларын эзләү, туплау һәм өйрәнү эшенең торышы ........... 12
«Контрреволюционер» мулла язмалары ................................................ 14
Серле китап, кулъязмалар.................................................................... 17
Гасырлар сагышы сарылган... .............................................................. 23
Ижау мәчетендәге тарихи материаллар ................................................ 27
Сирәк кулъязмалар ишәя ...................................................................... 29
Кукмара төбәге тарихыннан кайбер сәхифәләр ..................................... 31
Күмелгән китаплар .............................................................................. 35
Борынгы язмалар ни сөйли? ................................................................ 37
Якутлар табыладыр вакыт белән... ....................................................... 41
Китаплы халык – тарихлы халык ......................................................... 46
Язмыш ярасы ...................................................................................... 49
Тарихи язмалар .................................................................................... 50
Ун еллык археографик хезмәт.............................................................. 53
Тарихка – йөз белән ............................................................................. 76

Исемнәр күрсәткече .............................................................................. 78
Географик атамалар күрсәткече............................................................ 85
Резюме ................................................................................................ 90

Марданов Раиф Фатхулович

**В ПОИСКАХ ЖЕМЧУЖИН
ПИСЬМЕННОГО НАСЛЕДИЯ**
(на татарском языке)

Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Шамиль Насыров
Корректор: Миляуша Шакирова

Басарга кул куелды 15. 01. 2010. Форматы 60х84 1/16.
Тиражы 300 данә. Заказ № 262.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420111, Казан шәһәре, Кремль ур., 33.

Подписано к печати 15. 01. 2010. Формат 60х84 1/16.
Тираж 300 экз. Заказ № 262.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.

Отпечатано в секторе множительной техники редакционно-издательского отдела
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.